
فيض الله



Равил Фәйзуллин

# МӘХӘББӘТНАМӘ



МӘХӘББӘТ ШИГЫРЬЛӘРЕ

*(1961–2003)*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)−5
Ф91

**Фәйзуллин Равил**

Ф91 Мәхәббәтнамә: Мәхәббәт шигырьләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 399 бит.

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Равил Фәйзуллинның бу китабы аның кырык елдан артык вакыт дәвамында иҗат иткән мәхәббәт шигырьләрен эченә ала.

ISBN 5-298-01-343-0 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

## Яңа Мәхәббәтнамә

*«Мәхәббәт китабы... Мәхәббәтнамә, имеш. Тәвәккәллегеңме бу, әллә тилелегеңме? Мәхәббәт кадәр Мәхәббәт турында бит! Кешелек яратылганнан бирле исәбе-саны булмаган бихисап адәмнәр кичергән илаһи сөю тарихына, гыйшык утында януларын җанына-тәненә сыйдыра алмаган күпме нечкә күңелләрнең Сүздә, Авазда, Төстә, Ташта иҗат итеп калдырган бөек хәзинәсенә ни генә өсти алырсың икән, бичара!» дияр кемдер. Алай уйлаучы да, шиксез, минем кебек үк, хаклыдыр. Моннан кырык еллап элек язганмын: «Яздым Мәхәббәт турында, янып-көеп мин дә бер. Җир өчен миллиардтан бер, минем өчен — бердәнбер. Дөньяның чын кадерен тик сөйгәндә беләсең. Яздым Мәхәббәт турында, — яшим әле күрәмсең!» Әйе, һәркем үзенчә хаклы.*

*Мәхәббәтнең мәгънәсен бүтәннәргә аңлатырга тырышу мәгънәсезлек үк булмаса да, ихтимал, бик үк акыллы гамәл дә түгелдер. Бу җәһәттән әйтик, Данте мондыйрак сүз әйткән: «Мәхәббәт йөртә Кояшны, яктырта йолдызларны!». Ай-һай, алай үк микән?! Әмма ничәмә гасыр буе ничәмә буыннар яратып, теләп тәкрарлый бит шушы тәгъбирне. Димәк, ышанасылары килә шуңа! Шәрыкнең икенче бер мәшһүре Мәхәббәттән исереп, «бер миңенә алыштырам Сәмәрканд, Бохараны!» дигәнме әле? Бу диванасы бигрәк тә юмарт булып чыга түгелме соң? Ә айлы*

*төннәрдә куктән йолдызлар чуплэп, сөйгәннәре алдына сибүчеләр, аларны учларына өеп салучыларның исәбе-чуты юк... Курәсез, бик серле һәм хәтәр нәрсә икән бит бу Мәхәббәт дигәннәре! Серлеме, сихриме, илаһимы — монысы бер хәл, ә менә көче, кодрәте — монысы инде бәхәссез! Мәхәббәттә янган кеше могҗизалар тудыра, бөек эшләр башкара. Кем белә, бу якты дөньяга без, бәлки, шушы Бөек Мәхәббәт хисен тояр өчен генә киләбездер әле!*

*Мәхәббәт ул үзе шулкадәр абстракт төшенчә, әмма шул ук вакытта ут конкрет, утә индивидуаль, интим нәрсә дә. Шарламадагы тамчылар агышы бер-берсен кабатламаган шикелле, Мәхәббәт тә кабатлана алмый. Ләйлә белән Мәҗнун, Ромео белән Джульетта, Таһир белән Зөһрә, Галиябану белән Хәлилләрнең язмышларында уртаклыклар куренсә дә, гыйшкый янулары гел бердәй булгандыр дип уйламыйм мин. Безнең заманга да кагыла бу. Мисалга, бугенге яшьләрнең мәхәббәттәге уй-кичерешләре, хис-тойгылары төп гомерләрен уткән гасырда кичкән безнең буынныкыннан шактый узгәрәк бугай. Без — сугыш чоры, сугыштан соң формалашкан буын, нигездә, хыял һәм китап балалары. Усмер чактагы хыялның иң бөеге, әлбәттә, Мәхәббәт булды. Порнография, секс, эротика, наркотик кебек төшенчәләрнең исемен дә белмәгән бәхетле чак! «Тыелган җимеш» татлы инстинктта гына. Мөгаен, бәхетебездер — без Мәхәббәтнең табигый асылына табигый юл белән, озын-озак хыялый урау юл белән килдек (һәм соңармадык та шикелле!). Һай, ул малай чактагы «ис керә» башлаган айлы кичләр, сәгадәтле сәгать-*

*ләр! Күз алдына китерегез: кыш, кич, буран... ә син күрше урамдагы «сөйгән яр»ның тәрәз каршына батачума килеп, пыяладагы бозны эретәсең, борыннан акса ага, әмма Аны (шәүләсен!) янә бер күреп кайтасың. Сагынылган, көндез мәктәптә күреп туелмаган икән!.. Әй, ул кесәсенә салып җибәргән хат-хәбәргә җавап көтүләр! Әй, ул кинода күргән яки китапта укыган хәлләрне күз алдына китереп, хыялда аларга үзеңне дә катнаштырып саташулар!.. Хәзер шуларны көлемсерәп искә төшерәсең дә, татлы хатирәләр җанга бәлзәм булып иңә.*

*Ә Мәхәббәттәге уртак яклар? Алары да җитәрлек. Йөзләребез буйлап тәгәрәгән күз яшьләребез һәммәбезнеке бертөсле — төссез, каннарыбыз — кызыл, көлүләребезнең аһәңе бердәй, илереп елауларыбыз һәммәбезнеке дә әрнүле. Бәхетлеләр — охшаш, бәхетсезләр генә төрлетөрле була, дисәләр дә, Мәхәббәтнең фаҗигаи өлешендә уртаклыклар безнең күбрәктер дә әле. Мәхәббәт илаһи гармониянең гаранты булырга тиеш кебек булса да, ул гел генә дә бәхет-сәгадәт, шатлык-сөенечләр генә китерми икән шул! Мәхәббәт белән Нәфрәт һәрчак янәшәдә. Бөеклек белән Түбәнлек арасы пычак йөзе кадәр генә. Аллаһы Тәгалә Адәм белән Һауваны җәннәттән сөргән. Сәбәбе булган, диләр. Бүлешенмәгән Мәхәббәт аркасында тарихта калырлык зур-зур сугышлар чыккан. Көндәлек тормышта бәет чыгарырлык хәлләр дә бихисап. Үзара аңлашуда чәчәк, хушбуй, тәм-том кебек хаҗәт әйберләр урынына пычак, элмәк, агу кебек гайре табигый нәрсәләр килеп керә. Аннан инде китә судлар, мәхкәмәләр... Зиндандагыларның (хәер, аларның гына түгел) татуировка-*

*ларына игътибар итегез, һәрберсендә диярлек сөйгәннәренең исемнәре яки Мәхәббәткә бәйләнешле берәр сүз сырланган була.*

*Гомумән, Мәхәббәт турында тирәнрәк уйланган саен, каршылыклы хисләр күбәя генә бара. Ә бер уйласаң сере бик гади: бөек табигый инстинкт буенча Адәм баласы дәвам-нәсел калдырырга, үрчергә омтыла. Русча әйткәндә, охота к умножению. Ә Мәхәббәт дигәннәре моның прелюдиясе түгелме соң? Әмма нинди прелюдия! Бәлки, җәннәткә керер алдыннан (насыйп булса!) шундый хис кичерәләрдер?*

*Чу! Мин әйтәсе төп уемнан читкәрәк киттем түгелме? Мәхәббәттә дә бит сөйләнүдән бигрәк, гамәл үзе тансык. Сүз бит Мәхәббәтнамәнең, минем «Мәхәббәтнамә»нең бүтәннәргә хаҗәте турында иде. Күңелем сизенә, хәтта ышанам: кемнәргәдер кирәге булачак бу китапның! Кем белә, кайбер уй-хисләр кемнәрдер өчен гыйбрәт-сабак та булыр әле... Биредә мин берни яшермичә күңелемне түктем, бер шигырем юлларындагыча, «хөкем гадел булыр, беләм. Мин үзем ирешкән кадәр дөресен яздым, чын күңелдән». Дөрес, ихласлык әле ул аргумент үк түгел. Ихласлыктан тыш, кайбер фикерләр, күзәтүләр, «аңлатып булмаган» нәрсәне үземчә аңлаулар да бар бит әле бу шигырьләрдә. Кешеләр бу тормышта бер-беренә иптәш, иш, фикердәш эзли. Мин дә үземә гомер буе җандаш эзләдем. Икенче төрле әйткәндә, җан ашы — җанаш эзләдем. Таптыммы-юкмы — икенче нәрсә, әмма мәгълүм бер мәзәктәге шикелле, «процесс үзе кызык һәм матур» булды. Матурлык булган икән, бар икән, нигә аны кеше-*

*ләр белән уртаклашмаска! Мәхәббәт Аллаһның серле-могҗизалы бүләге ул. Шул ук вакытта Бөек Сер дә! Ә Сернең бөтен хикмәте кем беләндер бүлешәсе килүдә бит!*

*Әйе, моннан утыз еллар элек мин бер «Мәхәббәтнамә» чыгарган идем инде. 1976 елда Казанда басылган «Шигырьләр һәм поэмалар» мәҗмугасы эчендә аерым бер китапчык-бүлек рәвешендә (әлеге җыентык 1978 елны Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды). Үзенчә бер төзек композицияле, күңел-кальбемнең шул чордагы үзенчә бер кардиограммасы иде ул. «Ирек», «Сафлык», «Сагыну», «Син», «Бәйрәм», «Гөнаһ», «Өзгәләнү», «Каршылык», «Хушлашулар», «Төшләр», «Хатирәләр», «Юану» дигән бүлекләр бар иде анда. Ә хәзер менә «Мәхәббәтнамә»нең яңасы, тулырагы тәкъдим ителә. Беренчесендә — 30 яшькә кадәр язылган шигырьләр иде, бусына исә соңгы 30 елда язылганнар да өстәлде. Вакыт байтак узган. Теләсә-теләмәсә дә, Адәм баласының үзгәрми чарасы юк. Үзгәреш гелән шәхес һәм шигърият файдасына гына булмаска да мөмкин; ни дисәң дә, еллар узган саен, күзләр уңа төшә, гаҗәпләнү хисе кими, дәрт-ялкын сүрелә... Әмма шунысы бар: яши-яши акыл утыра, тәҗрибә арта, реаль тоем көчәя... Чая яшьлекнең кайнар яратуы янына олпат олылыкка хас хөрмәт дигән бөек хис өстәлә.*

*«Мәхәббәтнамә»нең бусын, теләсәм дә, аерым бүлек — «оя»ларга утыртып чыга алмам. Мәхәббәт агачының төп үзәге янына яңа үсентеләр чыккан, алар зурайган, тармакланган, ябалдашлары, бер-берсенә керешеп, уралып беткән... Шуңа күрә, үсмер чактагыдан бүгенгәчә, шигырь-*

*ләр кайчан, ничек язылган булса, шулай урнаштырырга карар кылдым. Һәр шигырь, һәр строфа, һәр юл конкрет шәхесләр, конкрет язмышлар белән бәйләнгән. Аңлаганнар аңларлар. Кемнәрнеңдер күңел тибрәнешләре — өзгәләнү-сагышлары, ярсу-янулары, өмет-хыяллары минеке белән күпмедер тәңгәл килә алса, аңлашуга, ягъни фикердәш, күңелдәш булуларына ышаныч бар. Шулай булыр дим: чөнки һәммәбез шушы Кояш астында Бәхеткә дәгъва кылып туабыз, яшибез, олыгаябыз бит. Фәлсәфирәк итеп әйтсәк, ихтыярсыз туабыз, гаҗәпләнеп яшибез, сагыш белән үләбез... Шатлык һәм Бәхет һәркемгә тансык. Бер җырда әйтелгәнчә, «җирдә күпме җаннар йөри, иясез шатлык булып!..» Бу шигырьләр кемгәдер ияле шатлык булырга булыша алса икән дигән теләктә калам.*

*Равил Фәйзуллин*
*июнь, 2003*

# ҮСМЕРЧАК ДӘФТӘРЕННӘН

*Кер чайкыйлар кызлар.*
*Тезләрендә — Кояш!*
*Күзләрендә — Яз!*
*Ярым ачык күкрәкләре*
*оялган күк бераз...*

## Онытылмас бер кыш бураны...

Ундүрт яшьме аңа, унбишме икән?
Малаймы ул, әллә егетме?
Дәрестән соң, мәктәп чатында ул
беренче кат бүген кыз үпте!

Кыз кызарды, сулышына кабып,
әй йөгерде өе ягына!
Ә шулай да борылып әйтә алды:
«Буран тынгач, кое янында...»

...Икенче көн инде буран тынмый.
Кызый чыгып күккә карый да,
өзгәләнә: «Монда — мәхшәр! Бәлки,
басылгандыр кое янында?..»

Егет каргый буран бабаларын:
«Ник ярсыйсың безнең авылда?!
Минем юлда котыр, сыртлап көрт өй,
тик туктап тор кое янында!..»

Ә буранның туктар исәбе юк,
котыра гына!..

*Казан*
*ноябрь, 1961*

* * *

Аста — дулкын, өстә — Кояш!
Идел буе чирәмлек!
Авыл шаулап туй үткәрә,
гөрли бөтен тирәлек!

Халык уйный, халык җырлый,
халык бии яр тулып!
Яшь киленнең ак күлмәге
үрли ак ялкын булып!

Авыл рәхәттән исерек,
туктармы туй өч көндә?
...Көймәгә капланып елый
бер кыз Идел өстендә.

*Казан*
*июль, 1963*

* * *

Ай вакланган дулкыннарда,
ватылган бәхет сыман...
Ә Синең тын күзләреңә
Ай тулы килеш сыйган.

Йөзә ул киң диңгездәге
ялгыз ак җилкән кебек, —
керфекләрең офыгына
бер кереп китәр кебек.

Аннан кабат чыгар төсле
чисталык диңгезенә.
Якынлашыр да Ай-җилкән
мине дә алыр менә...

*Казан*
*март, 1964*

* * *

«Аһ, кулларың, — дидең, — нинди кайнар!»
Чынында алар
неон кебек хиссез, җансыз иде.

«Син шат, елмаясың», — дидең.
Ә мин бу мәл
күптән булган чын көлүнең
тик төсмерен искә төшердем.

Ярый,
сау бул!
Бәхетле бул!
Киттем...
Мәхәббәткә Җир шар түгел, —
Магеллан күк бу ноктага
бүтән кайтмам.

Кузгалганда, соңгы тапкыр
сиңа түгел,
Кабанга карадым мин.

Тойдым,
сиздем,
күзләрең ялварды,
соңгы кат карачы миңа, дип,
иреннәр — миңа, дип!
иңнәрең — миңа, дип!..

Кабанга карадым мин.
Күзләреңнән артыграк
аңа ышандым.

Казанның моңлы бер күзе
күбрәк аңлар кебек иде...

Мин синнән киттем.
Таң белән
Төн булып киттем мин синнән.

Иртәләрен
Кабанга карасаң,
пар түгел,
аннан
минем сагыш күтәрелер...

*Казан*
*июль, 1964*

* * *

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!

Уйларны да, керләр кебек,
ак иткәнче, пакь иткәнче,
ах, чайкарга иде!

Сагышларны ике куллап,
кысып-кысып, кысып-кысып
сыгарга иде!

Шатлыкларны иң өстенә
сыйган кадәр, сыйган кадәр
өяргә иде!

Чын җырларны, — җилфердәргә —
биеккәрәк, биеккәрәк
эләргә иде!

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!
Күзләрендә — Яз!
Ярым ачык күкрәкләре
оялган күк бераз...

*Казан*
*сентябрь, 1964*

## Яшьлек дәфтәренә моңсу юллар

Кайда ул Мәхәббәт Гөле?
Күңелдә шыткан иде!
Икәүләп саклый алмагач,
юкка да чыккан инде...

Син дә инде бәргәләнмә,
көндез шәмнәр кабызып.
Мин дә күним. Икебезгә дә
тигән өлеш — Ялгызлык.

*Казан*
*1964*

## Ишемә кулларың орынгач

Буран котырган төндә,
кечкенә бүлмәмдә,
уйда изрәп утырганда,
иңнәремә минем
әллә апрель,
әллә май кагылды?

Тәнем буйлап кинәт
зәңгәр гөрләвекләр йөгерде,
ләйсән яңгыр исе
яңагымны сыйпап узды,
күзләремә тулган зур шатлыктан
керфекләрем ябылалмый калды.
Көндәлдә булган инсафсыз сүзләр,
иреннән тәгәрәп,
идән ярыгына төшеп югалдылар...
Өстәлдәге агач ручка яфрак ярды,
урындык аяклары сөенешеп үзара
пышылдаштылар
(такмак язучы шагыйрьдән акыллырак булып
күренделәр алар бу минутта),
язу машинкасындагы хәрефләр
иң игелекле сүзләр язарга хәзерләнделәр...
Туңган тәрәзәдә бөгелгән кулларың чагылышы
салават күпере ясады;
урамнан — шул күпер өстеннән —
безнең тәрәзәгә елмаеп,
изге күңелле кешеләр узды...

Котсыз суык көнне,
шыксыз бүлмәмә Син яз китердең.

Әгәр һәр кергән бүлмәгә яз ясасаң,
миңа күңелле булмас...

Тик шулай да бүлмәләргә,
кемнекенә генә булса да,
көз китермә, яме!

*Казан*
*10 май, 1965*

# Кит!

Бар кит инде, сеңелем!
Күзләреңне тутырырлык
иң гүзәл сүзләрне
әйтәсем бар.

Кит!
Күңелемә сурәтең ясыйсым бар,
Төсләр эзлисем бар:
Кояштан,
чәчәкләр таҗыннан...

Кит!
Син барда мин һәрчак дулкынланам.
Яңгырлар белән юньләп сөйләшә алмыйм.
Җилләргә җавап биргәндә тотлыгам...

Кит!
Син киткәч,
күңелдәгесе белән
иркенләп,
ачыктан-ачык
сөйләшәсем бар.

Кит!
Тик беразга гына,
бик азга гына...

*Казан*
*июнь, 1965*

* * *

«Ашыгыч ярдәм» машинасы бездән киткәч,
Урамыбыз сөремләнеп калган иде...
Бүген бөтенләй башка!
Җитәкләшеп кайтып киләбез:
шифаханә артта көлды.
атлаган саен дару исе кими бара.
Җылы кофтаңа,
кулымдагы пальтоңа кешеләрнең күзе төшә.
Бу эсседә..!
Җил ярамаганын сиңа
каян белсеннәр соң!

Ә мин — Мәҗнүн!
Үз-үземне белештермичәме,
әллә сөенүдән каушапмы,
әле уң ягыңа чыгам, әле сул ягыңа:
бу ягыннан тотсам, аңа җиңелрәк булыр,
бу ягыннан тотсам, җиңелрәк булыр...

Кайтып җиткәч,
баскычтан күтәрелгәндә,
башларыбыз күккә тиеп-тиеп алды,
аяз күк — зәңгәр шатлык! — үзе безне үбеп алды.
Кеше сөенүенә
мәрхәмәтле күк битараф буламы соң!

Сине йортта беренче булып
балкондагы яран чәчәк күреп алды.
Елмаюыңнан тәрәзәбез яктырып китте,
урамыбыз яктырып китте, шәһәребез...

«Рецептларны ерак яшердем: көн чыраен күрә алмаслар,
боеклыгым озакка югалды, аңа тиз генә юлыкмассың...» —
диден дә хәлсез кулларыңны маңгаема куйдың.
Мин бу мәлдә оныттылдым.
Терелүең шатлыгыннан
оныттым вакытны.
(Еллар, көннәр, секундлар, кичерегез мине!)

Әллә нинди бүген көне!
Ул безнең йорттагы җылылык,
ул безнең йорттагы яктылык —
глобустагы Арктикага да Кояш төшкән!

Әллә нинди бүген көне!
Күк тулы карлыгачлар,
чәчәкләрдә төклетура, бал кортлары...
Бакчага чыккач,
күкрәгеңә куярмын дип,
чәчәккә үрелдем. Кая өзү!
Тиз генә чәчәкләр янына үзеңне чакырдым!

Әллә нинди бүген көне!
Төнлә, күзләремне йомгач та,
әллә нинди төшләр керде.
Хәлеңне белергә дип синең янга йолдызлар төште.
(Ләхет кебек түбәләр юк,
өстә туфраклы түшәмнәр юк,
гел пыяла-вираж өстә!)
Аннан, сөенешеп, янә менеп киттеләр.
Таң атканчы шулай булды...

*Казан*
*июль, 1965*

* * *

Урман караучы кызының
такыясы ландыштан!

*Малайчак дәфтәреннән*

Сине күптән күргәнем юк,
бик еракта торасыңдыр,
Урман кызы түгелдерсең,
инде Ана булгансыңдыр:
тормышның авыр, җиңелен
тәнеңдә тоясыңдыр...

Кайчак бик күрәсем килә,
бик-бик сөйләшәсем килә...
Тик куркам, кыен булыр күк
син такыясыз булсаң,
каршымда Ханым булып,
сын кебек басып торсаң.
Юк,
яхшысы, күренмә син,
Мин иярләндем бугай,
үткәннәргә кайтмак булсам,
исемә төшереп шулай,
сиңа аталган сүзләремне
кабатлыйм яңабаштан:

«Урман караучы кызының
такыясы ландыштан!
Урман караучы кызының
такыясы ландыштан!»

*Казан*
*1965*

## Күзләр

Күккә баккан күзләреңне үптем.
Иреннәрем белән гүя күккә орынып,
болытларны,
тургайларны үптем...

Алар барысы
күзләреңә сыйган иде.

Җиргә баккан күзләреңне үптем.
Туфракны,
чәчәкләрне,
шулар белән
үземне үптем...

Алар барысы
күзләреңә сыйган иде.

Күзләреңне үптем.
Синең кайгың,
шатлыгыңны кушып,
мин дөньяны үптем!

Бүген миңа күңелсез.
Янымда Син юк,
күзләрең юк...

*Казан*
*1965*

# Рәсем

Күкне бизәкләп карлыгач,
Җирне ямьләтә ярым.
Карлыгач, оч-оч югары,
Син, ярым, елмай тагын.

Карлыгачта — җәя канат,
Ярымның — матур миңе.
Карлыгач, иркәлә күкне,
Син, ярым, назла мине.

Карлыгач, ярым миңенә
Күләгәчек төшереп ал.
Син, ярым, Күк һәм Җир өчен
бер елмаеп көлеп ал.

*Казан*
*16 гыйнвар, 1966*

* * *

Ал поездлар юллыйм мин Сиңа.
Каршыла!

Кайчан сиңа килеп төшәр?
Бураннарда балкып төшәр кебек,
Ләйсәннәрдә...

Ал поездлар юллыйм мин Сиңа.
Кешеләр юк,
тавышлар юк,
көпчәкләр юк, —
фәкать сагыш
вагон-вагон...
Сагыш, сагыш...

Ал поездлар юллыйм мин сиңа,
Иртәгә килерләрме,
бер айданмы...
Тик каршыла!
Тик каршыла!!

*Казан*
*февраль, 1966*

* * *

Күз кичәге, караш бүтән,
сүз кичәге, мәгънә бүтән...
Горурлыгым уяу чакта
юл бир миңа, китәм!

Ялварасың: «Алгысындым...
Кичәгегә кайтсак икән!..»
Үткәннәргә хәтер кайтыр,
мин тере әле — китәм!

*Казан*
*28–29 май, 1966*

* * *

Мин сине ничек яраттым!
Мәктәп юллары белә.
Синең эзне аера идем
мең эздән, карау белән.

Мин сине ничек яраттым!
Искә төшерәм дә, тынам.
Орыну түгел, күз атсам да
рәнҗетер идем сыман.

Мин сине ничек яраттым!
Киттең читкә. Көтмәдең.
.....................................
Хәбәрең бар: «Нигә шулчак
үзеңнеке итмәдең?!»
Каян белим дә мин ул чак
кавышу-кушылулар барын.
Сине яраттым. Яраттым.
Яраттым... Менә шул бары.

*Казан*
*2 июль, 1966*

* * *

Кыз бала йөгереп үткән.
Тезенә бәрелгәч, башактан
орлыклар чәчрәп киткән...

Инде күптән җәй икән!
Кай арада яз үткән!
Кайчандыр учымда йөрткән
кыз үсеп буйга җиткән.

Инде күптән җәй икән!
Җанда моң әле ниткән...

Өлгергән бодай кырыннан
кыз бала йөгереп үткән, —
йомрыланган тезләреннән
орлыклар чәчрәп киткән...

*Чуаш Кичуе*
*13 июль, 1966*

* * *

Үпкәлим.
Һәр җай саен:
сәбәптән дә,
бер дә юктан да...

Беләм:
шундук юатырга ашыгасың, —
җанга ятыш сүз әйтәсең.
(Миңа шул кирәк тә!)
Иркәләргә тотынасың:
сыйпыйсың, үбәсең
чәчемне,
күземне...

Ә мин
отыры күбрәк үпкәлим.
Мин, имеш, гел кимсетеләм,
һаман саен рәнҗетеләм...

Сабый бала анасыдай —
Син ничек тә көйлим, дисең:
Хет көлеп,
хет елап,
хет биләп...

«Үчтеки» итмәк буласың,
Көчең генә җитми!
Алдыңа алмак буласың,
кулың гына җитми!
Күбрәк иркә өмет итеп,

мин тагын үпкәлим, —
отыры күбрәк...

Ә Син үзең
бер дә юкка бүген
ничек газапладың!
Күңелеңне табар өчен
ни кылмадым!
Үтендем,
ялвардым,
табындым...

Аның саен
боек торгач —
коелып төштем,
йөземнән нур качты,
өнем бетте.

Бары кичен —
елмайгач кына син —
үземә кайттым,
терелә алдым.

Мин бит
юри генә үпкәлим гел,
Ә Син
әллә чынлап инде?..

*Казан*
*9 август, 1966*

* * *

Матурлар күп.
Тик алар
кереп югалалар тыкрыкларга,
күмеләләр куаклар артында,
калалар тукталышларда,
утырып китәләр йә...

Ә Син минем
гел янымда! —
Һәрчак үзем белән!
Матурлар күп,
Ә Син —
матурларның иң матуры.

*Сембер*
*27 сентябрь, 1966*

# СОЛДАТ ДӘФТӘРЕННӘН

Ай нурында, һай, ялтырай
каешым аелы!
Сағышымны Сиҙә илтер
диңгеҙҙән ай юлы!..

* * *

Ярлар күчәр, дулкын бәрсә.
Тик… торсыннар безнекеләр!
Тимәгез җанкайларга!

Ут өстенә ут өрмәгез!
Болай да ялкында без…
Тимәгез җанкайларга!

Исән булып, бер кайтырбыз,
ничек тә бер юатырбыз…
Тимәгез җанкайларга!

*Казан*
*6 декабрь, 1966*

## Әйтте кыз казарма янында…

Погоныңа черки кунган —
ку, солдат! Ку, солдат!
Кулларыңа таплар тигән —
ю, солдат! Ю, солдат!

Сукмагыма каршы төшмә,
кит, солдат! Кит, солдат!
Кайтып, ярыңны бәхетле
ит, солдат! Ит, солдат!

*Казан*
*9 декабрь, 1966*

* * *

Син — гүя бер күчмә шәһәр.
Һәм мин яшим шунда, —
бер бәләкәй почмагында.

Син — чибәрсең. Шуны раслап
гел йөрисең гизеп,
биеп, көлеп,
төнге матур бистәләрең буйлап...

Онытылмакчысың.
Ничектер акланмакчысың.
Күрми дисең?
Тоймый дисең?
Мөмкин булса —
йөгереп, яшьнәп,
элеккегегә кайтмакчысың!..

«Аһ!» дигән сүз
нигә бик еш
сагыш булып тибрәнә
бу Шәһәрнең өсләрендә?

Синдә яшим мин.
Бер бәләкәй почмагында.
Уңай булсын димим,
җиңел булсын димим,
бәргәләнмим, сүз дә дәшмим,
мин бит бары —
бәйсез куыш
(дөрес, кемнәргәдер мин дә шәһәр).
Син — Шәһәрнең
иң газиз бер почмагында...

*Казан*
*13 декабрь, 1966*

* * *

Телем оер,
каным кибәр,
күзәнәкләр катар
торараштай... –
сөюеңнән мәхрүм итсәң.

Тик күзләрем калыр
элеккечә,
Өмет белән
чагылырсың, бәлки...

*Казан*
*14 декабрь, 1966*

* * *

Җир җимермәк идек!
Күкне ватмак идек!
Мәңгелеккә балкыр
утлар якмак идек!

...Күзгә сагыш иңгән,
исәп башны игән.
Балкыр чыра сүнгән
тамчы яңгыр белән...

*Казан*
*декабрь, 1966*

* * *

Булчы, зинһар, зәңгәре Син
салават күпереnең!
(Нишләве бу зәңгәр күзнең,
яндыру-өтүеме?
Бу хисем — үсүемме соң,
әллә дә бетүемме?)

...Иң яхшысы, бул зәңгәре
салават күпереnең!
Зәңгәрлегең ялкынында
тилермәс, янмас идем.
Күккә төбәлер идем дә
күземне алмас идем.

*Казан*
*1966*

* * *

Күкне иңдереп,
башымны идең.
Мин бит — тургай!

Төннәремне кудың.
Яктыртучы бөҗәк мин!
Җырларымны будың.
Мин бит — аваз!

Миннән барсын алдың.
Мародерның күзе төшмәгән
Мәет кулындагы сәгать кебек,
ялгыз мин калдым...

*Казан*
*1966*

* * *

Көн шыксыз, дип карадым,
юл котсыз, дип карадым.
Казармага кадәр, диден,
барам дигәч, барамын!
Килеп җиткәч, күзгә карап,
бераз керми тор, диден.
Күк зилзиләсенә ымлап,
үзәк өзгеч җыр, диден.
Хәрбиләрчә, коры гына,
бу җыр түгел — кар, дидем.
Үзем җибәрмәскә кочкан,
үзем: кайтчы бар, дидем.
Кердем. Киттем. Син урамда
калдың буран эчендә...
.........................................
Хәзер май. Җирдә яшеллек, —
карның беткән исе дә.
Ә ул көннең ул бураны
бөртегенчә исемдә.
Карап ятам казармадан
майның аяз кичендә.
Күз алдымда син торасың
яшел буран эчендә.

*Самара*
*8—9 гыйнвар, 1967*

* * *

Мәңгегә яратам димим.
Чөнки беләм, —
бер көн китәчәкмен үзем...
Тизме, соңмы?
(Бик соң түгел, уйлап баксаң.)

«Мәңгелегем!», — дисең, еш кына
чын яратып, чын күңелдән.

Шул мәл карыйм да Сиңа,
моңсу гына көлемсерим...

*Казан*
*апрель, 1967*

* * *

Шулай туры килә,
читләргә кителә:
әле уң якка, әле сул якка,
әле төньягыңа Синең,
әле көньягыңа...

Һәр якның үзгә бер сагышы,
һәрераклыкның
үзгә бер ашкыну газабы...

Шулай да
рәхәт Сине сагыну!

Көнбагыш чәчәкләре!
Көнбагыш чәчәкләре!
Очрыйлар һәркайда.
Син — үзәге аның,
сары чуклар —
юлым минем.

*Самара*
*май, 1967*

* * *

Кемгә хаҗәт шатлык-кайгың!
Янма-көймә — барыбер чит син.
Хәтта матурлыгы үрти:
«Син кем кадерлесе монда!..»

Кеше сабыр. Түзә. Күнә.
Иләләшә күз дә, тел дә.
Ә җан тынмый, үрсәләнә —
«Син кем кадерлесе анда?..»

*Самара*
*май, 1967*

* * *

Куркытмый мине
безнең арадагы
ун чакрымнар,
йөз чакрымнар, мең чакрымнар...
Кисә бүтәне —
көннәр, төннәр...
Алар — күбәү.
Алар — калын урман.
Миңа — аларны кисеп чыгарга!
Аударырга Вакыт-кылыч белән
берсен уңнан,
берсен сулдан... —
әкияттәге пәһлевандай!
Вокзал, йортлар,
юллар, чатлар,
диңгез, һава юллары...
Алар — нәрсә!
Шахмат тактасына төшкән
бөҗәк кебек
кичәм шакмакларны:
әле карасын, әле агын.
Берсен үтәм,
янә алда икенчесен...
Шулай да
якынаям!
Якынаям!
Сиңа!

*Самара*
*октябрь, 1967*

* * *

Диңгездә Ай юлы.
Бер безме аерым?..

Ай нурында, һай, ялтырый
каешым аелы!
Сагышымны сиңа илтер, —
диңгездә Ай юлы.

Бер аерылсаң, ай, озак үтә, —
озак үтә, ай, елы…
Ай нурында, ай, ялтырый
каешым аелы.

*Таллин*
*ноябрь, 1967*

* * *

Яктыга төшә күз, акка...
Күңел һаман — алгысына
матурлыкның алгысына.

Сөю хисе меңәү икән,
ә мин үзем берәү икән.
Акыл моны белә кебек,
ә соң йөрәк белә микән?
Ә соң үзем беләм микән?

Яктыга төшә күз, акка...
Күңел һаман — алгысына
матурлыкның алгысына.
Ә Син, иркәм, барсын узып,
чык иң алга һәм... көт мине!

*Самара*
*ноябрь, 1967*

* * *

> Солдаттан әйләнеп кайттым,
> Әмәт тавында Ай
> тамчы да үзгәрмәгән.

Бераз үзгә, бераз бүтән, —
әллә ябыккан инде?
Йөзендә буйлы күләгә, —
әллә яулыктан инде?

Күзендә сабырлы сагыш, —
газаплы көткәннәнме?
Керфекләреңне аралап
күп көннәр үткәннәнме?

Җир ич! Язлар, гөрләвекләр
үзенекен иткәннәрдер.
Безгә, ятимнәр юк сана дип,
сипкелләр сипкәннәрдер.

Сынапмы ятлар, болаймы,
күңлеңә чирткәннәрдер…

Шулай да татлы ашкыну,
сагыну, өмет ташкыны
сүнеп үк җитмәгәндер.
Калгандыр нәрсә дә булса
күңелең юшкынында.
Ахыр чиктә шатлыгыңнан
елаган кич турында.

Хәтереңдәдер, яшь һәм яңгыр
яңагың чылатканы,
мин Сине, ә син үземне
арганчы елатканны;
татулашкач, сабыйлар күк,
җитәкләшеп кайтканны...
Калгандыр нәрсә дә булса,
шулаймы? Әйт, яшермә!
Юк булса, — горур китәрмен, —
Күралмассың яшем дә!

*Казан*
*гыйнвар, 1968*

* * *

Гөлем идең, яктым.
Синең иң соңгы хатыңны
кырга чыгып яктым.

Соң нигә калтырый тәнем?
Ә төн җылы, тып-тын...
Пышылдаулар ишетелә:
«Әллә инде шаштың?..»

Күңелемдә караңгылык,
ә йөземдә — якты.
Уттан түгел, ул — кайчандыр
Син кабызган чаткы!

Хискә кысан булмасын дип,
кырга чыгып яктым...

*Казан*
*5 гыйнвар, 1968*

## Ул көннәрне инде даулап булмый...

Ул көннәрне инде даулап булмый...
Сагынып кына була!
...Сөю ни икәнен белми гомереӊ узса, —
каплан да бер ела.

Сүнгән еллар исәбенчә, тезеп,
кара шәмнәр кабыз.
Кешеләрне ку! Хет тынлыкта кал, —
син барыбер ялгыз...

Ул елларны инде даулап булмый...
Сагынып кына була!
Үткән бөеклеккә кайтып булмый, —
табынып кына була...

*Казан*
*4 февраль, 1968*

* * *

Сөю көчле иманнан!
Чорнаса мәхәббәт-ялкын —
котылуың юк аннан!
Әхлак кануннарын көйләп,
тукысалар да туганнан,
Яз һәм Яшьлеккә вәгазь ни? —
Сөю көчле иманнан!

Яшен-күкрәүләр тын кала,
Ярсу хис ташса җаннан.
Җилләр калтырап кабатлый:
Сөю көчле иманнан!

Кабынса мәхәббәт уты,
Котылуың юк аннан!

*Казан*
*11 март, 1968*

* * *

Яздым мәхәббәт турында
яныл-көеп мин дә бер:
«Җир өчен — миллиардтан бер,
минем өчен — бердәнбер».

Дөньяның чын кадерен
тик сөйгәндә беләсең.
Яздым мәхәббәт турында, —
яшим әле, күрәсең.

*Казан*
*9 июнь, 1968*

* * *

Р-га

Минеке түгел сылулыгың,
аклыгың.
Минеке түгел күз яшьләрең,
пакьлегең.

...Чәчләреңнең каралыгы
бер уңар.
Йөзләреңнең аксыллыгы
бер сулар.
Төсләр, Сине ташлап, күчәр
бүтәнгә...

Белмим, ул чак кем табыныр
бу тәнгә.

*Казан*
*9 июнь, 1968*

* * *

Мин, ахры, изгеләштерәм
бик гап-гади нәрсәләрне.

Ник дип ашыктың син шулкадәр?
Ник теләдең тилертергә,
ерагайган саен якынаеп?
Ул мәл сиңа
иң кирәк җир шул идеме?
(Әйтик, Суконныйның бер почмагы.)

Мин баскан җир ят идеме?
Һәйкәленнән Тукай, күреп,
безгә сөенеп тора иде...
Ә Син киттең,
үзеңнекен иттең...
Мин, ахры, изгеләштерәм
бик гап-гади нәрсәләрне,
катлауландырам, ахры.
Үз иркемнәнме,
ирексездәнме?

Утырдың да киттең,
ә мин калдым
зуп-зур шәһәр уртасында
япа-ялгыз...

*Болгар*
*9 июль, 1968*

* * *

Төн бастырып куйдымы сине
ак күлмәгең белән ак ярга?

Ак болытмы Син?
Әллә ак мизгел?
Әллә ак яра?..

Ә аста
әй шашты соң дулкын!
Әй шашты!
Колачлары — буш...
Әй шашты!
Үртәлеп бәрелде ярларга,
чигенде ярлардан
сыкрап, сулкылдап,
яңадан
тугланды, аунады...
Ул ярдан төшәр!
Төшәр!
Төшәр!
Ә син йолдызларга карап
Һаман тордың ярда.

Әллә ак болыт?
Әллә ак мизгел?
Әллә ак яра?..
Мин дулкында идем.
(Әллә дулкын үзем идем?)
Ярда тору кирәк булган
Синең белән
йә икебезгә дә
дулкын кочагында...

*Казан*
*8 июль, 1968*

* * *

Без, ахры, гыйбадәт кылдык:
тезләр тездә иде, күзләр — күздә...
Әллә егерменче гасыр,
әллә мәҗүсилек бездә?

Нинди табыну бу? Сүз юк,
өн-тавыш юк, хәрәкәт юк...
Җанда бөек иреклелек —
сыкрану юк, һәлакәт юк...

Күк!
Нигә пышылдыйсың бер үк сүзне:
«Сез бер-берегезгә түгел!
Сез бер-берегезгә түгел!»
Күк!
Күк ишетми...
Әйтче Күккә, күңел! «Без —
Кешеләр, җансыз маллар түгел...
Безгә рәхәт бу мизгелдә...»
Әй Вакыт!
Тамырларым буйлап йөгереп
тукыйсың:
«Белегез!
Белегез!
Бәхетле мизгелегез
үтә, үтә...»

Вакыт! Туктап тор аз гына!
Рәхәт табыну кешенең
гомерендә
нинди аз була!

Күк һаман пышылдый,
Вакыт һаман тукый.
Урман сагаеп тыңлап тора.
Җил шуышып арага керә...

Без, ахры, гыйбадәт кылдык.
Күңел тулы яшь, күздә — бер тамчы юк.
Мәхәббәт бар. Сафлык, сәгадәт бар...
...кавышу юк.

Бәхетебезне озатыр өченме
без гыйбадәт кылдык?..

*Казан*
*10 июль, 1968*

* * *

Нигә чыктың
һәлакәтле юлга?
Очрашачакны белә идең.
Мин-ялкынга нигә җил булдың?
Дөрләячәкне белә идең.

Нигә куркытмады сине вәхшилек,
Успен чиркәвенең кара рухы,
хәрабәләрнең өнсез каргышы,
чиркәү эчендәге шыксыз тәре,
әрвахларның сөякләре,
кызыл йөзле археологның зур пычагы,
исәннәрнең туклыгы һәм мәнсезлеге,
сөйләүләрдәге алдау, рыя,
синең янда йөргән бер шагыйрьнең
саркып торган җан ярасы?..

Нигә һәлакәтле юлга чыктың?
Син әллә батырмы, кыз бала?

*Казан*
*12 июль, 1968*

* * *

Чакырдың да,
үзең киткәнсең...

Синең тәрәз каршысында
басып торам.
Буп-буш урам.
Йә,
бу мизгелдә
син нишлисең анда?
Көнләшүгә охшаш бер хис җанда:
«Син нишлисең анда?
Син нишлисең анда?..»
Мине оялткан күзләреңдә ни чагылыш?
Яңагымны иркәләгән кулларыңда ни хәрәкәт?
Яшем тамган күкрәгеңдә нинди сулыш?
Күземне үпкән иреннәрдә нинди сүзләр?
Ни җан белән яшәргә кирәк
нindидер бер Борда!*

Монда бар да
яна Синсез:
гөлләр яна,
төбәк-илләр яна,
ташпулатлар яна,

* Казан янындагы Зеленый Бор күздә тотыла.

Идел, Кабан яна, —
бар да яна!

Басып торам
тавыш-тынсыз.
Эч тулы — яшь,
тик керфекләр генә дымсыз.

*Казан*
*июль, 1968*

* * *

Күргән һәр сылуга мин гашыйк.
Телим ешрак очрауларын!
Сихерле гүзәл йөз өчен
мин әзер сәҗдә кылырга.
Матурлык киммени изгедән!
Бәхеттән —
көннән-көн күбәя чибәрләр,
күркәм йөзлеләр,
үзәккә үтәрлек күзлеләр...

Гашыйк булган саен,
күңелемә нурлар тула,
тойгы-хисләрем нечкәрә,
ышанычым арта үз-үземә.
Мәңге яшәр кебек хис итәм дә,
тураямын. Күңелдә кояшлы ләйсән!
Күзләр йолдызлардан ары...
Һәм шул килеш кайтам сиңа —
сөеклем, бердәнберемә —
күпме аклык алып,
күпме пакьлек алып,
олыланып!
Әй, наз кояшым! Бу — мин!
Бик күпләргә гашыйк булып,
иңнәремә үскән канатларым белән
болытларны сыйпый-сыйпый,
кайтып киләм —
бар зурлыгың белән каршыла!

*София*
*июль, 1968*

# ӘЛМӘТ ДӘФТӘРЕННӘН

Син – теләп алган сагышым.
Син – теләп алган ярам...
Туеп кем дә китәр, ә син –
яратып китеп кара!

* * *

Ярсыгансың, янгансың...
Кемгәме ачулангансың?
Кемнәнме үчең аласың?
Җиде кат төн уртасында
ялгызың кая барасың?

Ярамый димә, ярасын,
киләә саклап барасым.
Кемгәдер газиз бала син!

*Әлмәт*
*октябрь, 1968*

* * *

Үсә алган һәрбер нәрсә
яна ала.
Ян син.
Мин каршы түгел.
Яндыр мине.
Мин каршы түгел.

...Күзләреңә карап әйтәм:
мин яратмыйм Сине!

Үсә алган һәрбер нәрсә яна ала.
Җаның тели икән —
Әйдә, ян!

*Әлмәт*
*25–26 октябрь, 1968*

* * *

«Булдыралмыйм! Хуш!..» — диде ул.
Кара яндың
һәм юандың:
«Үкенәчәксең!
Үкенәчәксең!»

Чыннан да, бер үкенде ул,
Тик... башка өчен.

Сөенмә!
Ул да, синең күк,
бер бәләкәй юаныч табар.

*Әлмәт*
*6 ноябрь, 1968*

* * *

«Сафлыкка өйрәнәм Сездән,
язганыгыз гел-гел пакь...»

Юлда йә өйдә кайчак
искә килә шушы юллар, —
күз алдымда синең хат.

Синең, ахры, иң рәхәт чак,
сагышсыз, тәүбәсез чак!
Сеңлем, Син үзең Сафлыктыр,
язган хатың бигрәк ак!

Кеше үткәнен сагына,
кайтмасын эзли күп чак,
Газиз югалтулар миндә
булганнар, бәлки, шуңа да
ярсына күңел-учак?
Бәлки, шуңадыр язганнарым
артык ак һәм артык пакь?

Өстәлемдә Синең хат.
Әллә син хак,
әллә мин хак?

*Әлмәт*
*1968*

* * *

«Зинһар, кит!» — дисең,
газап белән...
Беләм...

«Син — чит! Чит!» — дисең,
Нишлим соң?
Күзләрең: «Иң якын», — ди.

Шулай да мин китәм.
Әйдә,
үз-үзеңә карыш —
теләкләреңне бу,
хыялларыңны җимереп тор,
хисләреңә зынҗырлар сал —
үз-үзеңә сугыш ачып,
үз-үзеңне җиңеп кара!
Тик шулмы
кешелеклелек!..

*Әлмәт*
*1968*

# Очрашкач

Иреннәрең тетрәде...
Һәм яшь тәгәрәде.
Аңыңа кил!
Яле! Көл!
Яле!

Бик азга гына булса да
без бит
бергә әле!
Бар язганы белән алда
тулы
гомер әле!

Кадер генәм!
Риза булчы шатлыгыбызның
килгән кадәренә!
Акыллы бул!
Өстебездәге
тургай кадәр генә!
Акыллы бул!..

*Әлмәт*
*7 июнь, 1969*

* * *

Мин ашыккан, син соңарган…

Әгәр киресенчә булса да —
соңаручы мин фәкыйрь —
өмет тергезер идем,
һаман күңелдәге «Сине»
мең кат хисләр арасыннан
өскә менгезер идем
һәм чабар идем шашып!

Ах, соңаручысы шул Син…

*Әлмәт*
*12 июнь, 1969*

## Этюд. Идиллия

Кешеләр менгән Айга.
Ә без менә җайга
бу борынгы җирдә,
тамырланган илдә,
үзебез корган өйдә
тәрәз юабыз.

Шундый бездә йола:
язлар җиту белән,
халык өйләр юа.
Йөзләрдә — көләчлек,
табигатьтә — яшьлек!
Әле Кояш яна,
әле ләйсән яна!
Кызлар су ташыйлар
йөгерә-чаба.
Кыска итәкләргә
шук тамчылар тама...

Кем чыгарган йола?
Язлар житте исә,
халык өйләр юа.
Юа бар җирен дә, —
калдырмый җеген дә!

Кешеләр Айга менгән.
Ә без җирдә менә
тәрәз юабыз
синең белән бергә.
Тыштан мин су сибәм,
эчтән Син юасың.

Мин көлемсерим
ә Син елмаясың.
Гөрләвекләрмени
өлгеләр, рамнарда!
Күрәмсең, чистара!
Чистара! Тагын да
сафлана шикелле
икебезнең ара...

Җитсен киче генә,
йолдызлар балкышып
тезелгәч күгенә,
нәни улыбызны
уртабызга алып,
карарбыз тәрәзәдән
бу айга таң калып.

*Әлмәт*
*июль, 1969*

* * *

Күктә — яшен!
Дәһшәт, шом!
Ярда — Син —
алиһә сын.

Тузанга да
күрмәүме бу —
алла, күкрәве!

Син — зур зат, дип
тибрәнә әнә
алма күкрәге!

Күктә — яшен,
ярда — Син.
Кем сынамак
без — табигать
баласын?

Күкрәү. Тетрәү.
Ярлар ишелер!
...Илаһи, тын гына
сылу чишенә.

*Чуаш Кичүе*
*18 август, 1969*

* * *

Хиссият илендә икәү,
әйдә, гизиек әле!
Теләк бакчаларыбыздан
гөлләр өзиек әле!
Иш килгәннәрен аралап,
бергә тезиек әле!

Әйтсәләр әйтерләр инде:
«Ярамый! Тыела!» — дип.
Тик соңыннан әйтмәсеннәр:
«Их, әрәм!.. Коелган...» — дип.

Тартынмыйча хөр йөрик бер
бакчабызда, үз булып.
Назга сусаган бер гөл дә
калмасын мәэюс булып.
Рәнҗемәсә кешелегең,
фатиха булса җаннан, —
тыйма мәхәббәт ташкынын
сихерле тыелганнан!
Әйдә, урнашсын бер мәлгә
синдә шәхси үз әдәп.
Бәлки, мәҗнүни бу мизгел —
бүтән кайтмас сәгадәт?..
Онытылып, иркәләнеп,
әйдә, бер йөрик әле!
Серле, тансык гөлләр өзеп,
уйнап, көлиек әле!

*Әлмәт*
*5 сентябрь, 1969*

* * *

Артык бернәрсә дә өмет итмим;
хис — тыюлы, күңел — утырган.
Ә шулай да, үсмер чактагыдай,
бер тилереп алу ни тора!

Тик гадел бул, күрсен күңел күзең,
бу — хыянәт түгел, бу — яшәү!
Киткән яшьлегеңнең ерактан бер
миһербанлы булып дәшүе.

Ихтыярың: йә көл, йә ачулан,
аңлый алсаң әгәр — рәхмәтем.
Унҗидедә, белмим, тоярсыңмы
сагышның бар ачысын, рәхәтен...

Дөнья матур! — безнең бүгенге күк!
Син көләсең, миндә уй да шом.
Нигә Кеше Олы Матурлыкның
бик азына гына хуҗа соң?

Бик азына... Син минеке түгел.
Сау бул!
Каргыш кануннарга яусын!..
Барсы өчен рәхмәт әйтәм бары,
син дә, яме, алгысынмассың!

*Әлмәт*
*1969*

## Бәлки, Син...

Бәлки, Син — минем җырланмас
иң гүзәл җырымдыр?
Бәлки, син — минем чыгалмас
иң данлы юлымдыр?

Бәлки, Син — минем меналмас
иң биек күгемдер?
Бәлки, син — күтәралмас
гомерлек йөгемдер?

Бәлки, Син — минем беркайчан
кул җитмәс кошымдыр?
Бәлки, син — үзем аңламас
бәхетем алкышыдыр?

*Әлмәт*
*1969*

* * *

Сиңа,
Батаган истәлеге итеп.

Адаштык. Төн килә өскә.
Урман — кара, җил — шомлы...
Ни өмет караңгы Җирдә?!
Күк, табышсана юлны!

Күктә дә кара болыт шул,
ул да — йолдызсыз, ятим.
Яңгыры кемгәдер шифа,
тик безгә — каһәргә тиң.

Бар тирә-як шомда, ымда,
нидер сагалый сыман.
Кайдадыр Алмазга охшаш
яшь бала елый сыман.

Ниндидер көч көлә кебек:
«Нишлисез инде, ягез?..»
Куанма: болар сансыз дип,
без дә кемгәдер газиз!

Адаштык шул. Ярый Син бар.
Ярый Син янда гына!
Барабыз икәү — йөз ачык —
билгесез алдагыга.

*Әлмәт*
*23–24 апрель, 1970*

## Бу сөю

Бу сөю — диңгез икән дә,
иксез дә чиксез икән!
Туйганчы талгып йөзәргә
гомер җиткесез икән...

Бу сөю — тормыш, яшәүнең
тылсымлы иле икән.
Кешедә гомер картаймас
җанның яшьлеге икән.

Бу сөю — бөек мәгънә —
бәхетнең үзе икән.
Аңа таба онытылып
гел чап, оч һәм йөз икән.

*Әлмәт*
*23 май, 1970*

* * *

Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда...
Шундый тансык бөек тилерүләр
кануннардан каткан дөньяда!

Бәрәкәтсез гомер, аһ, сүтелә!
Вакыт белән дуэль. Ни чара?
Бу таңнарны күбрәк күргән саен,
күңелне ник моң һәм шом сара?

Янарга да, батарга да риза
эштә, өйдә, идеалларда...
Барыбер килә,
күзләр аша килә олыгаю,
күзләр аша, — авыр аларга...

...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Йә, тагын соң ни бар дөньяда?..

*Әлмәт*
*20 март, 1971*

* * *

Кояш булган күзләреңнән
нур алган бу дөнья –
керфекләр күләгәсенә
яңа сызыклар уя...

Нур юлы булган сызыклар
үзләре дә нурга тулсын.
Үткән язларыңны белмим,
килерләре матур булсын!

*Казан*
*18 апрель, 1971*

* * *

Сагыш газапка әйләнгәч,
күз яше — кара канга,
син әллә каргый башладың
мин сине яратканга?

Акыллы бул… Кисмә өметне!
Бәгырьдән ал пычак очын!
Мин әзер мең кат янарга
бер бәхетле чак өчен.

*Әлмәт*
*26 апрель, 1971*

* * *

Су читендә, таң тугач,
талга кунган сандугач.
Суга төшкән ак болыт —
күренә мендәр булып.
Тибрәнер шул сандугач,
талы бик зифа булгач,
җанына шифа булгач —
талга кунып канат кагу
бәхетле бер ял булгач!
Әй, өздерә сандугач,
әй, тибрәнә сандугач!

Шул сандугач искә төште
куенында төн кунгач...

*Әлмәт*
*26 апрель, 1971*

* * *

Син — бәйлелек, мескенлекнең,
түбәнлекнең дошманы.
Нинди вак җан яулый алсын
Синекедәй хөр җанны!
Көчле рухлы белә булыр —
чын иреклек ни торыр!
Баш имичә, сокланучы
бер кешең бар, бер горур...
Тик ул усал. Усалланган
ятлар көнчелегеннән.
Җиңелсә, ул җиңелер тик
синең кешелегеңнән.

*Әлмәт*
*26–27 апрель, 1971*

* * *

Аның җаны яралы...

Бәргәләнәме, өзгәләнәме —
Син тимә,
ялгыш
кызгана күрмә, яме!
Кем белә: ул батырмы,
әллә бичарамы?..

Мәхәббәттән яраны
бары Вакыт дәвалый.

*Әлмәт*
*27 апрель, 1971*

* * *

Сары ут капкан бу кырда,
көнбагыш арасында —
мин ничектер, ә менә син —
бер зәңгәр ярасыман…
Зәңгәр яулыгың читеннән
ялварды зәңгәр күзләр!
…………………………………
Хәтер әле кайта-кайта
бу мизгелне мең эзләр…
Үбимче сөенечтән
мөлдерәп чыккан күз яшең!
Күктә, Җирдә мең-мең Кояш
ут янсын бер көнләшеп!

Сары ут капкан бу кырда,
көнбагыш арасында,
безгә карап, бәхетсез, дип,
Йә, әйтеп карасыннар!

*Әлмәт*
*28 апрель, 1971*

* * *

Мин синең җаеңа килдем.
Языңа өлгермәдем.
Син булып Син ялкынлангач,
мин нишлим, йә! — дөрләдем!

Моңарчы кем дөрләмәгән!
Утында кем янмаган!
Алар арасында бер мин
илаһи илһамланган!

Котырынып эшлим — язам!
Таша хисем, көчем дә!
Дөрлим, янам — минсез үткән
Синең язлар өчен дә...

*Әлмәт*
*29 апрель, 1971*

* * *

Миннән дә алда тәрәзәңнән
Ай Сиңа кергән икән!
Бүген ялгыз калганыңны
ул каян белгән икән?

Моңарчы ачык пәрдәңне
мин килгәч корма инде!
Буй-сыныңда сынган нурдан
оялып торма инде...

Һәр күзәнәк дәрткә тулган.
Миң очыңа нур кунган.
Матурлыктан кем туйган да,
сөелүдән кем туйган!

Бернигә баш имәс җан да
мәхәббәткә буйсына.
Пәрдәңне теләсә нишләт,
нур сынса да, мин сынмам!

*Әлмәт*
*3 май, 1971*

* * *

Син калган аптырашта.
Мин калган аптырашта.
Уналтыдагы җилкенү
утыздан ашкан башта!

Данларгамы соң бу язны?
Каргаргамы бу таңны?
Яшьлек соңын, картлык башын
бергә китереп бутады...

Шундый халәт — әле акыл
хисне җиңалмаган чак.
Көтелми иңгән бәхеттән
аңга килалмаган чак.

*Әлмәт*
*4 май, 1971*

* * *

Бар нәрсәдә синең төсмер:
Син — үләндә, яңгырда.
Сине күрәм дулкыннарда,
тургайлар тулы кырда.
Син — кәгазьдә, төнбоекта,
керфектән тамган тирдә...
Болытта да чагылышың! —
Йа Хода, бөтен җирдә —
Син,
    Син,
        Син...
Күңелемдә шигырь тажы.
Ачып баксам — анда да Син!
Кайда да син, кайда да син!
...Тик
үзең генә юк янда.

*Әлмәт*
*12 июнь, 1971*

* * *

Мәхәббәт күзсез була, ди,
ярату сүзсез була.
...Безнең мең күзле булды,
гайбәтле, сүзле булды!

Ә барыбер хисләр, уйлар
чиста, пакь, олы булды!
Сөенүләр, сөелүләр,
шатлыклар тулы булды!
Бездән хәтта өлеш чыкты
хөсетле күзләргә дә —
форсат булды рәхәтләнеп
сөйләргә, күзләргә дә...

Мәхәббәт күзле буламы,
буламы күзсез, сүзсез —
монсы бер хәл, ә берзаман
бу таңнар булыр безсез...
Җан өшетерлек бу уй-хис
нинди ят, нинди төссез!

Тизрәк килче Син яныма!..

*Әлмәт*
*12 июнь, 1971*

* * *

Беренче дә, иң соңгы да түгел,
күбәүләрнең монда берсе мин.
Бердәнберең генә булмавыма
ни гаебем? Ни дип көрсеним?..

Әйтмим — үзгәрешләр ясадым дип,
тормышыңа, димим, ямь керттем.
...Тәрәзәңә ябышып канат салган
бер күбәләк алып терелттем.
Гөлләреңне барлап иркәләдем.
Бераз яшәрттем күк, су бөркеп.
Дивардагы яшьлек рәсемеңне
турылап куйдым, тузанын сөртеп.

Бүтән, ахры, берни кылмадым мин,
яхшысыннан, ни яманыннан.
Ә барыбер чиксез бәхетле идем!
Өстен идем — нәфес, мал, даннан.
Син үзең дә якты сагышлы идең.
Разый идең сыман өлешеңнән.
Һәм барсы шул. Тагын ни мөмкин соң
соңлап килгәннәрнең берсеннән...

*Төмән*
*15 июнь, 1971*

* * *

Өзгәләнмим, һич үкенмим,
«гафу итче!» дип үтенмим.
Сөю хакында булса да,
бу җырым сиңа түгел!..

Телә — аңла, телә — карга.
Яманлык кыл, хәтта алда...
Сөю хакында булса да,
бу җырым Сиңа түгел!..

*Төмән*
*16 июнь, 1971*

* * *

Кояш тотылганмы? Көпә-көндез
җиргә иңгән сөрем, кара шом...
Җитәкләнешеп, безнең балалар
йөри анда илереп, адашып.
Сукырлардай ары сугылалар, бире...
Ә күзләре — зәңгәр күк кебек!
Безгә борылып та карамыйлар,
әллә инде өзгәннәр өмет?
Безгә — ак гөл, бәлки, алар өчен —
баш калкыткан кара еландыр?
Сине кочып, бәлки, сабыйларның
шатлыкларын каерам, буамдыр?
Безгә — чиста; алар өчен — пычрак;
безгә якты булган — караңгы.
Бәхеттән кан уйный, шул ук вакыт
тере каным — балам каргаулы...

Үзебезме әллә адаштырдык?
Йөзләрендә нәфрәт, кара моң.
Мин беренче тапкыр — кылганыма
улым күзе аша карадым.

Бәгърем көйде, йөзем агарды...

...Кояш тотылганмы? Көпә-көндез
җиргә иңгән сөрем, кара шом.
Җитәкләнешеп, безнең балалар
йөри кебек каңгырып, адашып.

*Төмән*
*17 июнь, 1971*

* * *

Бар күк булган сабырлыгымны,
бозмам дигән уем-тәүбәмне —
Син килдең дә ваттың, таркаттың, —
бөтенлегем меңгә әйләнде...

Күпләр өчен әле күз үтмәс мин,
күпләргә — таш, калкан әле мин!
Синең алда исә, үзем теләп,
үз-үземне ваткан бәллүр мин.

Ятлар жәлләмәсен. Үзе бәхет
сөю өчен ватылу чәчрәве!
...Ә Син исә, мине янә җыйсаң,
тезең чүгеп җыймассың, яме!

*Төмән*
*19 июнь, 1971*

* * *

Тилерткән, бәхетле иткән,
сөюендә яндырган,
һәр күзәнәкнең куәтен
иҗади кабындырган,
ил алдында кызармаслык
эшләргә рухландырган —
һәр чибәргә сәҗдә кылам!
Мәдхия язам, данлыйм!
Хатын-кызның тик шундыен
чын хатын-кыз дип саныйм.

*Әлмәт*
*23 июнь, 1971*

* * *

Без, бәләкәй чакларда,
сикереп мендек атларга!
*Халык җыры*

Без, бәләкәй чакларда,
менмәсәк тә атларга,
очрашуга чакыра идек
аулаграк чатларга...
Әй, куандык «сөю» сүзе
булган җылы хатларга!

Без бәхетле чакларда
булдык җылы кочакларда.
Көнләшүдән җан дуслар да
әйләнделәр ятларга.

Бәлки, олайган чакларда
килмәс җылы хатлар да...
Ә шулай да ант иттек без
сынатмаска ятларга.
Яшеннәргә тиң яшьлекнең
шанлы исемен акларга —
җан хөрлеген сакларга.

*Мәскәү*
*29 июнь, 1971*

* * *

Бу — сәясәт түгел,
Сөю — бер йөзле.
Бер утта янганның
барын тигезли.

Бу — Хис Иле. Монда
кануннар үзгә.
Монда көчсез — Акыл
көйләгән бизмән.

Монда кызганмыйлар
һәм баш имиләр.
Рөхсәт сорамыйлар,
рәхмәт димиләр.

Гамәлгә кермәгән
дәрәҗә, даннар.
Мәхәббәттә һәркем
үзенчә янган.

Бәхетлеләр алар
сүзсез дә аңлаша.
Яшәүне данлыйлар
җан һәм тән аша.

Бу — үзгә Ил. Монда
ләззәт, хис — өстә.
Юк монда яз-көзләр,
юк иртә-кич тә...

Сөю — хезмәт түгел,
норма, тариф юк.
Уйлап баксаң — ансыз
җирдә Тарих юк.

Бүлеш, әйтче, дисең, —
белмәкче фикерем.
Мин шул аны үзем дә
аз беләм, энем!

Тик сиңа ярамас
минем белгәнем,
һәркем үзе ача
мәхәббәт фәнен.

*Әлмәт*
*июнь, 1971*

* * *

Асылмалы тар күпердән
мин алдан чыктым микән,
Син алдан чыктың микән?
Тау менгәндә үпкәнемне
инде оныттың микән?

Күк — зәп-зәңгәр, ә тирә-юнь
яшь сусыл үлән иде.
Ул елны җәй әллә ничек, —
безнең мәхәббәт шикелле, —
соңгарып килгән иде...

Тау башыннан караганда
Зәй — кара дегет кебек.
Ә безнең күңелләр ак, пакь! —
мәктәпне яңа бетергән
кыз белән егет кебек.

Күңелдә җыр — куанычтан:
«Яшьлек безгә үзе килде,
алмадык ла бурычка!
Гомернең, һай, мәхәббәттән
тилергән чагы кыска!..»

Син уйнаклап таудан төштең,
күктә сайрады тургай.
Асылма күпердән кире
ничек чыктык, хәтерләмим —
без очып чыктык бугай.

*Займище*
*4 июль, 1971*

* * *

Әгәр дә мин хөр, бәйсез бер
табигать улы булсам,
кош-киекләр дусы булып,
ялгыз куышта торсам,
мин Сине җибәрмәс идем
авылына, каласына...
Без куышлы уйнар идек
чәчәкләр арасында.

Мин Сине утыртыр идем
печән төялгән йөккә!
Аллы-гөлле дугадагы
кыңгыраудан биеккә!
Ярым ачык иңнәреңә
ал яулык салыр идем.
Салават күперенәчә
озата барыр идем.

Сиңа юлыңа җитәрлек
дәртле җыр бирер идем.
Чакырсаң, ерак дип тормый
йөгереп килер идем.
Качсаң да Син, югалсаң да,
мин эзләп табыр идем.
Бит очыңдагы миңеңнән
барыбер таныр идем,
риза булсаң, гомерлеккә
яр итеп алыр идем.
Баш астына, мендәр итеп,
чәчәкләр түшәр идек.

Таң алдыннан хәл белергә
йолдызлар төшәр иде.
Шат гомер кичәр идек!
Җаныбыз теләгәннәрнең
барысын эшләр идек!

Әгәр дә мин хөр, бәйсез бер
табигать улы булсам,
киек-кошлар дусы булып,
ялгыз куышта торсам…

*Әлмәт*
*7 июль, 1971*

* * *

> Син, бәлки, кем беләндер
> хәзер Агыйделдәдер...

Көнләшү ирләр эшеме?
Ахры, ул йөрәк эше.
Үз-үземне аңлый алмыйм,
шашынам, әллә нишлим.

Быел, ахры, оныттым мин
хак-хокукларым чиген.
Илнеке — ул синеке, ди,
шәхси минекелегем.

...Гомер кыска. Һәр көн саен
гүзәллек арта тора.
Инде җырга торыр яшьлек
җилкәдән артта тора.
Янда елларыңны турап,
Вакыт — чос балта тора.

Шуңа, ахры, ашкыныла,
шуңа көнләшенелә.
Инде Ходай бу хисләрдән
аера күрмәсен генә.

Килми һич туктыйсы, татлы
янудан, җан атудан:
чөнки ул шашып сөюдән,
чөнки ул яратудан.

*Әлмәт*
*9 июль, 1971*

* * *

Җирдә әллә ниләр бар!
Халыклар бар, илләр бар,
кыялар бар, күлләр бар.
Сызгырсам бер, авазымны
сиңа илтер җилләр бар.

Киекләр бар, кошлар бар,
ызгышлар, сугышлар бар.
Гайбәт атлы дию бар,
хисләрнең иң илаһие —
изге ләззәт! — сөю бар.

Кочкан билдән тартып алып,
кылыч тотар куллар бар.
Сөюне саклый алырлык,
исемен аклый алырлык
йөрәкле ир-уллар бар.

Котсыз бай сарайлар бар.
Эченә бәхет оялаган, —
куыш сыман өйләр бар.
Кызым янымда дип, ялгыз
йоклап яткан әниләр бар...

Җирдә әллә ниләр бар,
Без белмәгән телләр бар,
ишетмәгән көйләр бар.
Тыңламаган авазлар бар,
татымаган назлар бар.

Икебезнең генә дә әле
бер мәгарә серләр бар.
Икәү йөргән үзәннәр бар,
икәү менгән үрләр бар.
Таңга кадәр бергә булып,
чык төшермәгән җирләр бар...

Җирдә әллә ниләр бар!

*Әлмәт*
*9 июль, 1971*

## Уен

Борынгы уен дигәч,
ырымлы уен дигәч,
ләззәтле, тәмле дигәч,
уйнавы ямьле дигәч, —
нигә кермәскә дидем,
уенга барып кердем.
Авыз ачып калмаска,
кешедән калышмаска!

Уенда юк кем генә!
Монда утлар, монда балкыш,
гүя монда көн генә.
Читтән карап торганда,
бәхетле бер гөр генә!

Үзең кергәч, күрәсең,
күргәч, бераз беләсең!
Монда әллә нәрсәләр!
Кайчак хәрәмләшәләр.
Алдаса да, юрамалый
тәмле сүз эндәшәләр.

Монда бар газиз хисләрен
ваклап оттырганнар да.
Бар шомалар. Гомерләрен
уенга корганнар да.

Бар мәгънәне, бар хәйләне
аңлап бетү дә кыен.

Бу — әллә кызык уен,
бу — әллә бозык уен?
Бу әллә нинди уен!

Туктыйм инде, дип уйлыйм.
Үзем уйныйм, үзем туймыйм...
Бүтәннәр юри уйныйлар,
мин юләр чынлап уйныйм,
ихлас ышанып уйныйм.
Барсын беләсе килә.
Кайчак көләсе килә.
Уендашлар шаркылдыйлар,
Миңа күз яше килә...

Бу әллә нинди уен!

*Әлмәт*
*10–11 июль, 1971*

* * *

Ак хыялларга уралып,
гел өскә менгән чакта,
яшьлек бер узар дигән уй
башка килмәгән чакта, —
әй, сабырсыз ашыгылган
тизрәк яшәп калырга!..
Гүя син иң дөрес юлда,
иң кирәкле адымда.

Нигә шулай ашыгылган?
Нигә шулай чабылган?
Язмышмы ул, ялгышмы ул —
бер очраклы табылган?

Баш астына кулың куеп,
кайчак уйлап ятасың.
Көлкеле дә, аяныч та
ул елларның хатасы.
Яшьлек, гомер кыскалыгын
җан хәзер сызып тоя...
Үткән еллармы тыя? —
хәзер инде ашыгылмый...

*Әлмәт*
*18 июль, 1971*

## Җавап

Бәхет күгендә очарга
канатларың ап-актан!
Ходай сине сөйкемле итеп,
горур итеп яраткан.

Төштә түгел, өндә күрдем —
канатларың каралган.
Әллә күкләр курыктымы
җаныңдагы ярадан?

Күпме очып, ник калмадың
бәхетнең мөнбәрендә?
Нигә ялгыз горур башың
ак мамык мендәреңдә?

— Үзем качтым мөнбәреннән.
Булмас һәркем тәхетле.
Үкенмим. Өзә бүтәне —
минсез дә
Син
бәхетле...

*Казан*
*19 июль, 1971*

* * *

Мәхәббәттә күпме яндык!
Барыбер яну аз шикелле.
Гүзәллеккә теләк чиксез,
тик гомер аз — яз шикелле.

Матурлыктан өстен көч юк —
күккә аштыра, тезләндерә,
хәнҗәрлегә гөл алдырта,
бөкрене төзләндерә.

Матурлыкка ирешкән дә
түгел тоташ бәйсез, азат.
Сөелүдән күпме өлеш наз —
шул бәрабәр бурыч-газап.

Матурлыкка юл гел ачык,
күзләргә дә, күңелгә дә.
Мәхәббәт өчен барганнар
гөнаһлы үлемгә дә.

Сөю өчен шәһит киткән
рәхмәттәме, ләгънәттәме?
Бүген үзем берәү өчен
утка керер халәттәмен.

*Әлмәт*
*22 июль, 1971*

* * *

Казынмыйм үткәннәреңдә,
тикшермим бүгенгеңне.
Җаның олы икәнлеген
болай да белдем инде.

Туры очкан горур җанның
булгандыр төрле чагы.
Кемнең юк абынганы да,
кемнең юк егылганы...

Кирәкми кеше сүзләре,
кирәкми дәгъвалар.
Минем үз күзләрем бар,
күңелем бар иң әүвәл.

Синең белән үткән һәр көн
бәхеткә тулы булды.
Тагын бер расладың, рәхмәт,
яшәүнең олылыгын.

*Әлмәт*
*25 июль, 1971*

# Бу дөньяда

Бу дөньяда бик офтанма,
мин барын да истә тот.
Дусларның да дуслары бар,
серләреңне эчтә тот.

Бу дөньяда бер ояга
сыялмаган кош азмы?
Барыбер тартып алалмыйлар
күңелгә тулган язны!

Бу дөньяда әле алда
күп бәхетләр бардыр күк.
Күгең тутырып бер килермен
тоташ ләйсән яңгыр күк.

*Әлмәт*
*25 июль, 1971*

* * *

Юк,
азсынудан түгел —
матурлык күп, мул, —
ә шулай да
моңа кадәр күрелмәгән, тоелмаган
ниндидер бер гүзәллеккә
килә шашып сокланасы!

Юк,
куркынудан түгел
тормыш җилләреннән, тетрәүләрдән, —
ә шулай да
килә ышыкланасы,
сөйгән кочакларда
озаграк онытыласы...

*Әлмәт*
*31 июль, 1971*

* * *

Яр буенда Сиңа диеп
ал гөлләр өзә идем.
Йөгереп килсәм, Син инде
Иделдә йөзә идең...

Ниндидер бер яңа утка
ашкына идең бугай, —
кабаланып ишүләрең
уйлата иде шулай.

Кинәт суны яңгыратты
Үзәк өзгеч тавыш — ай!
.....................................
Юк, каты сүз әйтмим Сиңа,
кул биреп, тартып алам.
Йөзтүбән яткан көймәңне
этеп ярга чыгарам.
Тамчы суын да калдырмый,
түгеп, киптереп бирәм.
Кирәк әйбернең һәммәсен
табып, китереп бирәм.
Аннан китәм,
белмим, ни җавап бирермен
ялварулы сүзеңә.

Чыксаң, дәрьяга чыгарсың
яңадан үзең генә...

Әллә дулкын бәйләнде?
Әллә башың әйләнде?..
Комлы ярда төнгә каршы
калды гөлләр бәйләме...

*Әлмәт*
*июль, 1971*

## Быел җәй, быел җәй...

Быел җәй,
эссе җәй —
җиләкләр көйгән җәй.
Үзем чабып, үзем җыеп,
печәннәр өйгән җәй.

Кошлар иртә тынган җәй.
Кызарып, кара көеп,
кичен Ай тотылган җәй.

Быел җәй,
эссе җәй,
манма тиргә төшергән җәй,
улларыбыз белән уйнап,
бакчада йөргән җәй.
Алмалар койган җәй.
Яшьлекнең кайтмас китүен
җан әрнеп тойган җәй.

Быел җәй,
быел җәй —
чит ярлар сөйгән җәй.
Бәгырьләр көйгән җәй...

*Чуаш Кичүе*
*21 август, 1971*

* * *

Юк, санамыйм Сине йолдыз диеп,
олы талант түгел юлдашың.
Ә шулай да иҗатчылар өчен
булалгансың үзең — җыр башы.

Синең аша күпме шигырь, көйләр
дөньяга чыкты, Кояшка.
Мин үзем дә байтак җырым белән
бурычлымын Сиңа иң башта.

Шуңа Сине һәрчак зур санармын,
бар җанымны Синнән күпсенмәм.
Ә шулай да ул җыр-көйләр Синнән
бәхетлерәк була күрсеннәр.

*Юлсубино (Балтач)*
*21 август, 1971*

## Этюд-рәсем

Баласын яшь ана
йөзәргә өйрәтә.
Үзе яткан чалкан,
баласы — күкрәктә.
Биеккә-биеккә
төбәлгән карашы.
Зәңгәр күк фонында —
Кояшта баласы.
Төтенсез шартлаусыз
аларның арасы.
Шулай күккә багып
килә гел барасы,
барасы...

Яр буе чыр-чуын
ишетми дә ана.
Баласы белән ул
эчкә кереп бара.
Сакланып, шатланып
йөзәргә өйрәтә.
Дулкыннар тибрәтә,
бәгыре — күкрәктә.

*Займище*
*август, 1971*

# Кем шакымас толлар ишеген...

Шакыдылар. Син ачмадың. Китте...
Корт иледәй купты бар шигем.
Ачу тынгач, аек акыл әйтте:
кем шакымас толлар ишеген!

Ни уй белән килеп, кем шакымас —
яхшылардан азмы яманы!
Толлар яше ачылана бара,
матурайган саен заманы...

Ирле хатыннарның кайгылары
хәзер эрер җәйге бер кырау.
Толлар күңеле — тышы мәңге бозлы,
ә эче — гел ут булган утрау.

...Әй ул язгы төнге тамчыларның
котыртып һәм көлеп тамуы!
Урын җәйгән чакта бер мендәрнең
артык булып моңаеп калуы!

Сантый телләр әйтә: толлар бай ул,
алтыннан, ди, ишек төбе дә.
Толлар исә — ана назын биреп,
гөл үстерә тәрәз төбендә...

Ачу — бик тиз. Хөкем итү — җиңел.
Ирлек кирәк дөрес аңларга.
Толлар күңеленә рәнҗү салмас
ялгызлыкны татып караган!

…Хәзер менә кемдер шакып китте.
Ни уй белән килгән ул бәндә?
Икебезнең дә башлар иелгән,
нидер югалткандай идәндә.

*Казан*
*август, 1971*

* * *

Биеккә мендем. Кояшка —
калды шундый якын!
Җиде кат күкнең быел мин
ачтым алты катын!

Берсен әле калдырып тордым
алгы гомергә дип.
Бер бәхетле таңда икәү
ачарбыз бергә дип.

*Әлмәт*
*18 сентябрь, 1971*

* * *

Бәхетле булып, таңгача
йөргән идек икәү без.
Каушырга да өлгермичә,
аерылган икәнбез.

Без яраткан ул ләйсәннәр
кабатланмас микәнни?
Бу йөрәкләр, өзгәләнеп,
кабат янмас микәнни?

Көзге соңгы чәчәкләргә
саксыз кагылма икән.
Үзең теләп бер хушлашкач,
кабат сагынма икән.

*Әлмәт*
*19 сентябрь, 1971*

* * *

Көндезен — кеше күзендә,
төнен — син керфегемдә.
Бергә булган вакытларның
онытмам бөртеген дә.

Синең белән узган гомер
гел тоташ бәйрәм генә.
Алда әле андый бәйрәм
бармы, юкмы — кем белә?

*Әлмәт*
*19 сентябрь, 1971*

* * *

Син — теләп алган сагышым.
Син — теләп алган ярам.
Туеп кем дә китәр, ә Син —
яратып китеп кара!
Үз-үземә каршы килеп,
мин Синнән китеп барам.
Кайтмаска китеп барам,
китеп барам...
Хәлне сорама, теләсәң
үзең мин булып кара!

...Ireннәр кыймылдавына
кешеләр карап кала:
«Үзалдына сөйләнә бу,
исәр, ахры, бичара!..»
Ә мин тәүге очрашуга
рәхмәтләр укып барам.
Рәхмәтләр укып барам.

Ярамы? Ансы — минем эш.
Ул — теләп алган ярам.

*Әлмәт*
*20 сентябрь, 1971*

# Аккошлар

Күзләрдән соң язлар килми, —
алда — салкын ак кышлар.
Китәсез дәмени,
китәсез дәмени,
китәсез дәмени, аккошлар?

Әллә ничек үтте яшьлек,
соң очрашты язмышлар.
Хушлашырга безгә
иртәрәк бит әле,
иртәрәк бит әле, аккошлар!

Бездә әле бу дөньяга
күңел тулы алкышлар.
Китәсез дәмени,
китәсез дәмени,
китәсез дәмени, аккошлар?

*Юлсубино (Балтач)*
*сентябрь, 1971*

* * *

Нинди күзләр! Нинди буй!

Яшь чагында көн дә бәйрәм!
Көн дә уен, көн дә туй!

Ник ди исәп? Ник гамь-уй?
Дөнья бәйрәм! Дөнья туй!

Кара, кара, күрми калма —
нинди күзләр! Нинди буй!

*Әлмәт*
*5 ноябрь, 1971*

* * *

Сөйдем аны.
Шаштым!
Җаным
күкләргә күкрәп менде!
Әйттеләр: бигрәк сүрән,
басынкы бала инде.

Берзаман, «гашыйк икән!» дип,
илгә сүз чыккан иде.
...Ә мин инде ул вакытта
аны оныткан идем.

*Әлмәт*
*6 ноябрь, 1971*

## Сагыш

Мин Сиңа йомшак таң җиле
юллаган идем, —
чәчләреңнән иркәләр дип
уйлаган идем.

Сәфәреңдә илләр кичеп,
тауларда куныл,
ул сиңа ирешкән икән
зилзилә булып.

Мин Сине сагынып бер җыр
чыгарган идем.
Җан дуслар аны яратып
тыңлаган иде.

Җыр сиңа ошар дип йөрдем,
ваемсыз булып;
ә ул Сиңа барып җиткән
авыр сүз булып.

...Хәзер җилләр дә юлламыйм,
чыгармыйм җыр да.
Әгәр теләсәң, җанымны
кил дә бер тыңла.

*Әлмәт*
*ноябрь, 1971*

* * *

Яшьлегеңне, гомереңне
миңа багышладың да,
хәзер инде гел әзер тор
яңа сагышларыңа.

Мине май дип белдең, ахры,
мин бит ноябрь сыман.
Кояшым аз, күгем тулы —
салкын яңгыр да томан.

Мин үзем дә белми торган
бер сәерлектә яшим:
челләләрдә кайчак өшим,
кышларны ярып яшьним.

Үзем дә кайчак төшенмим
күңелемнең хәлләрен:
көтәм җылы ләйсән яңгыр,
чыга зилзиләләре.

Шулай барам мин таңнарга,
шулай чыгам мин язга.
Үземнең наз юк, ә үзем
шашам, туялмыйм назга.

Хисләр үзгә. Мәхәббәтне,
шәхесне аңлау үзгә.
Күпләр кебек гомер итеп,
тыныч яшәү юк безгә!

Мин, ахры, сабыйлыктан —
шигырьдән киталмамдыр.
Сине беркайчан да тулы
бәхетле италмамдыр.

Мин әле Син уйлаганча ук
тугры да түгелмендер;
Син белмәгән яралары
бар бугай күңелемнең.

Яшьлегеңне, гомереңне
миңа багышладың да,
әзер тор кайгыларыңа,
яңа сагышларыңа.

*Әлмәт*
*20–22 декабрь, 1971*

## Тимим күңелемә

Тимим күңелемә, —
өзгәләнсен, янсын!
Кеше кайчак үзен
кичерә дә алсын.
Хисләрем ярсысын,
уйларым ташсын,
зиһенем чуалсын,
җан изрәп талсын...
Тимим күңелемә, —
өзгәләнсен, янсын!
...Ә безнең мәхәббәт,
сагышлы мәхәббәт,
каргышлы мәхәббәт
җыр булып калсын.

Яңа таңнар атсын,
яңа гөлләр үссен.
Бу татлы газаплар
бүтәннәргә күчсен.
Яшь йөрәкләр янсын,
яшь җаннар юансын.
Сөю алар белән
киләчәккә барсын!
Тимим күңелемә, —
өзгәләнсен, янсын...
...Ә безнең мәхәббәт,
тыңдәшсез мәхәббәт,
күз яшьле мәхәббәт
җыр булып калсын!

*Әлмәт — Казан*
*декабрь, 1971*

## Боз өстендә учак ага

Боз өстендә учак ага.
Әй, төнге ялкын!
Икебез ике ярда булгач,
язгы җил дә салкын.

Барыбер рәхәт: сәбәп чыкты
бер кузгалырга,
ике як ярлап булса да
бергә барырга.
Ага боз. Без йөгерәбез,
утка кул сузып.
Син шулчаклы ашыкмачы! —
ни бар утны узып…

Нигә сагышны үрләтү —
сүнгәнен күреп.
Тиздән үзе дә югалыр
борылмага кереп.

Утның соңгы җемелдәвен
күз күрмәсен лә!
Бу бит безнең яшьлек китә
ут рәвешендә.

Боз өстендә учак ага.
Әй, төнге ялкын!..

*Әлмәт*
*декабрь, 1971*

## Бер хатирә

Без Болгарда төн үткәрдек.
Йолдызлар якын иде;
көймәгә түшәлгән печән
хуш исле, салкын иде.

Сихри төнге авазлар,
ахры, камыштан иде.
Без ул чак — яңа табышкан,
яңа кавышкан идек.

Яшь идек. Һәр таң безгә
көч алып килә иде.
Көлә идек! Безгә кушылып
дөнья да көлә иде!

Таң алдыннан су коендык
аксыл томан эчендә.
(Миннән башка, ак тәнеңне
күрмәде бер кеше дә…)

Сине тибрәткән дулкын да
миңа бик якын иде.
Яр буенда безнең учак
Һаман ялкынлый иде.

*Әлмәт*
*1971–1972*

* * *

«Ни кылам?» дип, башкалардан
ник әле сорап торам!
Син бар чакта мин бит фәкать
зураям һәм яхшырам!

Нигә күңел баш бирә әле
кануннар тезгененә?
Хөкемче бер — без тудырган
шул гүзәл мизгел генә!

*Әлмәт*
*1971*

* * *

Синең өчен җан атмасам,
саргаймас, көймәс идем.
Бүтәннәрдә булса күңлем,
«бәгырем!» димәс идем.

Чарам булса, горур йөрткән
башымны имәс идем.
...Бергә булсак, Сине, бәлки,
бу кадәр сөймәс идем.

*Әлмәт*
*25–26 гыйнвар, 1972*

## Яз – 72

Бу — минем яз түгел.
Бу яз — ят җыр кебек.
Керергә куркыныч
миналы кыр кебек...

Ләйсәннәр, бөреләр,
бу җил... бар да иске!
Мәхәббәтен җуйган
Һәммә кеше мескен.

Ни мәгънә Кояштан,
язында җан туңса...
Берни дә булмас күк
хәтта Син онтылсаң!

Син үзең дә мине
сагынма, юксынма.
Кызыксыз, буп-буш мин, —
таланган йорт сыман.

Елыйсы урында
мәгънәсез көләм мин.
Үземне дә сөймим,
Сине дә теләмим.

*Әлмәт*
*23–24 март, 1972*

* * *

Бөтен күкләрне чыңлатып,
тургай сайрый иртәдән.
Беренче чыккан чирәмгә
яңагың куй, иркәләп!

Мине үртәп, көнләштереп,
җил керә кочагыңа.
Көйгән бәрәңге исе килә
кемнеңдер учагыннан.

Пышылдап кына әйтерлек
сүзең-серең бар сыман.
Ишетергә теләгән күк
шыпырт ага кар суы.

Ишеттеңме, күк күкрәде
күксел урман өстендә.
Бу язгы назлы уяну
бар көчтән дә өстен лә!

Беренче чыккан чирәмгә
яңагың куй, курыкма!
Әгәр рәхәтлектән арсаң,
күкрәгемдә, кил, йокла!

Син төш күрсәң, без торырбыз
тургайлар белән сакта.
Тургай язга дан җырласа,
мин исә — Синең хакта.

*Әлмәт*
*23 апрель, 1972*

* * *

Син дә бөек идең ул мизгелдә,
Һәйкәл иңсәсендә торганда.
Ә ул төнне бездән бәхетлерәк
тагын кем булды икән дөньяда?

Казан күге — тоташ күбәләк кар,
урамнары — тыныч, тын иде!
Кушылулар хыял гына булса,
сөешүләр безнең чын иде.

Күз алдында бөтен торышларың,
Көлүләрең, елмаюларың...
Бәхет өчен туган хатын-кызның
теләкләрен тойдым мин барын.

Син дә бөек идең ул мизгелдә
гади кеше, шат бер җан булып.
Мин дә әзер идем бөтерелергә
керфегеңдә эрер кар булып.

Кая ашыктык без?
Ник ул төнне озынайтмадык?
Бәхеткәме тиз кул болгадык?
Тукай һәйкәленең итәгендә
ник соң бик аз янды ал яулык?..

*Әлмәт*
*апрель — август, 1972*

* * *

Синең горур башка
нинди язмыш язган...
Каян соры сагыш
шушы яшькелт язда?

Дөнья балкытырлык
нурлы, ачык йөзең;
шатлыкларны күпләп
сыйдыра алыр күзең;
бәхет кунар өчен
ике нәфис иңең;
җил йөрешен тояр
сыгылмалы билең;
назга яратылган
бөтен җирең, тәнең;
сабыйны ышыкларлык
тулы күкрәгең;
ирекне аңларлык
илсөяр йөрәгең.

Синең ятим башка
нинди язмыш язган? —
Күзләреңдә хәвеф
шушы иртә язда...

Карап тора язга
ике дымлы күзең.
Әллә безне жәлли,
әллә инде үзен...

*Әлмәт*
*май, 1972*

* * *

Әйтәсең: «Минем йөрәк, — дип, —
кайгылар каберлеге...»
Санамыйм андый йөрәкне
дөньяга кадерлегә.

Уйлап баксаң, кемнең юк ул
сагышы, хәсрәте...
Ә кирәкме бар кайгыңны
дөньяга чәчрәтү?!

Яшеңне йот! Елмай! Хәтта
эчтән бетсәң дә көеп.
Әйтсен кеше: «Йөрәге аның —
чәчәк бәйләме!» — диеп.

*Әлмәт*
*июль, 1972*

* * *

Белмим, кайчан күргәнсеңдер
яңа Айны ул якта.
Айны күргәч, мин янәдән
уйландым Синең хакта.

Уйладым үткән турында,
уйладым бүгенгене:
тамыр җибәргән икәнсең,
булып күңелем гөле.

Белмим, бу Ай нинди сынау
алып киләдер безгә.
Хыялдагы бәхет кошы
кунармы иңебезгә?..

*Әлмәт*
*июль, 1972*

* * *

Бай көз яхшы, тик шулай да
ярлы яз күркәмрәк.
Яз көне хаста җанның да
күңеле бүтәнрәк.
Әй, ул беренче чирәмнең
яшеле күренүе!
Шактый күшеккән күңелдә
өметләр терелүе!
Ни хозурлык — тамчыларның
Кояшта көлүләре!
Әй, кызларның язгы кичтә
тәүге җилкенүләре!
Көз гел бөтен, бай булса да,
җилбәзәк яз дәртлерәк.
Язын — бүтәнчә ашкыну,
язын — бүтәнчә йөрәк.
Мин һәр яздан үзенә бер
яңа наз һәм ямь көтәм.
Көзге таңнарда, уянып,
яз дип эмсенеп китәм.
Ишетелеп куя кебек
кайткан кошлар авазы.
Куркам тормышта җуюдан
мәхәббәт белән язны.

*Әлмәт*
*август, 1972*

## Әй, мәхәббәт!

Әй, мәхәббәт! Ләззәтләрнең
иң зуры, иң татлысы.
Шатлыкларның җиргә түгел,
күккә сыймас чаклысы.

Әй, мәхәббәт! Язлар кебек
кабатланганым минем.
Инде мең кабат янып та,
кабат янганым минем.

Әй, мәхәббәт! Рухландыргыч
илһамым чыганагы.
Синдә сихри биеклек —
илаһи чагы җанның.

Синдә ачыла җирдә яшәп
җыйган бар яхшылыгым.
Сөйгән чакта бөек була,
Табигать, һәрбер улың.

Әй, мәхәббәт, төрле афәттән
йолып алучы багым.
Ичмаса, синдә ярадан
төзәлә ала җаным.

Синдә юыла күңелнең
бар фани ваклыклары.
Язгы күкрәү кебек күкри
яшәүнең шатлыклары.

Әй, мәхәббәт! Яшәвемә
өмет-хыял бирүчем.
Дөньяда бәхетле итеп,
Кеше итеп сиздерүчем.

Тормыш, теләсәң җәза бир —
мин риза барысына.
Уттан алып сал суга!
Тик мәхәббәттән аерма
бу гөнаһлы ярсуны.

*Әлмәт*
*август, 1972*

* * *

Могҗизага яшьрәк чакта ышан,
гөл асылын җәен өз икән.
Язгы эзләр белән килгән идем, —
сезнең урамда да көз икән...

Бер вакыты җиткәч, кай җирдә дә
пәрәвез җепләрен җил өзә.
Әй авыр, кайтмаска киткәнгә —
«Озак йөрмә, тиз кайт!» — дип кул изәү...

*Казан*
*сентябрь, 1972*

## Мин диңгезгә таба китәм, дидең...

«Мин диңгезгә таба китәм!» — дидең,
гөрләвекләр буйлап йөгердең.
Нәфис иңнәреңне миңа кадәр
нинди җилләр кочып өлгерде...

«Мин диңгезгә таба китәм!» — дидең,
гөрләвекләр буйлап йөгердең.
Ул еллардан бирле күргәнсеңдер
байтак матурлыгын бу Җирнең.

«Мин диңгезгә таба китәм!» — дидең,
гөрләвекләр буйлап йөгердең.
Нигә дип соң әле кире кайттың... —
чәчәк чагы үткәч гомернең?

Син диңгезгә каршы киткән чакта,
озатып калган идем берүзем.
Яши торгач, һәркем бу дөньяда
таба икән үзенең диңгезен.

Тик шулай да килә Синең белән
гөрләвекләр буйлап чабасы;
Үткәннәргә кайтып, Син эзләгән
шул диңгезне килә табасы.

*Казан*
*сентябрь, 1972*

* * *

Чабылгач та, таң атканда
чыклар белән кем көлә?

...Хәер, без үлән генә,
җирдә бер келәм генә!..

Кояшка дип, күккә багып
үскән идек гел үргә.
Яшәргәнне күрсәләр дә,
корган чакта кем күрә?

Хәер, без үлән генә,
җирдә бер келәм генә!..

*Әлмәт*
*30 сентябрь, 1972*

## Ә шулай да...

Бергә булган ул елларга
Синдә каргыш, кинә…
Тик шулай да кавыштырган
апрельгә тимә!

Әйдә, мине из, өзгәлә,
җаны нечкә димә.
Тик шулай да Сиңа язган
җырларыма тимә!

*Казан*
*7 декабрь, 1972*

# Кызыл алма

Бу иреннәр сөю сүзе әйтте,
һәм шулар ук мине каргады.
Без, ахры, күтәралмадык
икәү өзгән кызыл алманы...

Беребез дә иелим диялмады.
Гел өстәнме өзеп күнеккән?
Син, имеш, мәңгегә алиһә,
мин, имеш, гел егет — сөлектәй...

Мин кузгалгач, җирдән күтәреп
ни уйлап аткансың артымнан?
...Син хәзер тоташ боз булгансың,
мин исә әйләндем ялкынга.

*Казан*
*20 декабрь, 1972*

## Күңелемдә сурәтең

*(Зыятайдан)*

Бар нәрсә үзгәрә...
Вакытның кодрәте!
Күңелдә шул килеш
Синең яшь сурәтең.

Безгә дә килде бу
картлык чалымнары.
Иреннәрнең алы —
хыялларда бары.

Гомер-җил Сиңа да
беләм, әй, кагылган!
Еллар Матурлыкны
Синнән кире алган.

Елның кайсы — күзләр
явын алып киткән...
Кайсы — ак йөзеңә
сырлар салып киткән.

Кайсы ел — калдырган
чәчеңдә ак чалым.
Кайсы ел — урлаган
иреннәрең балын.

Инде дивардагы
рәсмең дә тонык.
Ә күңелдәгесе —
яшь, һаман шул ук!

Элек Сине күрер
өчен ата иде ал таң.
...Хәзер хәтта ялгыш
очрашудан куркам.

Чынлык — күңелдәге
Сине сызар төсле.
Яшьлек рәсемеңнең
төсен бозар төсле.

*Казан*
*1972*

## *Үләннәр*

Без берни дә күрмәдек!
Килдегез, басып тордыгыз, —
без сагайдык, без тындык.
Без берни дә күрмәдек!

Иелдегез, утырдыгыз, —
без сытылдык, без сындык.
Без берни дә күрмәдек!
Без бары үлән генә.
Җирдә бер келәм генә!

Ай-яй авыр үзегез! —
без изелдек, без иңдек.
Без берни дә күрмәдек!
Ай-яй каты тезегез! —
без тетелдек, без иңдек.
Без берни дә күрмәдек!

Хәлсез, гамьсез икегез
тыныч кына киттегез.
Берәү дә күрмәс, диден.

Берәү дә белмәс, диден.
Ә без бит барсын күрдек!

*Казан*
*1972*

* * *

Илһам биреп, җыр тудырткан
сөйкемле хатын-кызлар,
сезне илаһига санап,
баш иям алдыгызда.

...Ә синең алда имим —
син мине сөйгән өчен!
Сиңа дип язган җырымны
«Иң гүзәл!» — дигән өчен!

Бәлки, ияр идем. Куркам,
калган чагында ялгыз,
миннән отып, горур башың
иеп куярсың ялгыш...

*Әлмәт*
*1 гыйнвар, 1973*

# «ГОМЕР ТУЕ» ДӘФТӘРЕННӘН

*Тилерткән, бәхетле иткән,*
*сөюендә яндырган,*
*һәр күзәнәкнең куәтен*
*иҗади кабындырган,*
*Ил алдында кызармаслык*
*эшләргә рухландырган —*
*һәр сынуга сәҗдә кылам!*

## Язгы кичтә көзге бер уй

Сагышлы үткәннәр,
билгесез киләчәк —
барсы да күзеңдә.

Минем өчен ят сызыклар —
җыерчыклар —
юк йөзеңдә.
(Дөресрәге,
минем өчен алар юк, дип,
алдап киләм үз-үземә.)

Ә шулай да
хәзер ешрак,
көн күзендә түгел,
эңгер-меңгер вакытта,
йә тонык утта
багасың көзгегә...

Мин ул чак
(сискәндерермен күк)
төбәлмәскә тырышам йөзеңә.
Карап торам берәр әйбергә,
йә тәрәзәдәге гөлгә,
йә, булмаса, матур тезеңә.

Язгы шәфәкъ,
моңсу йөз көзгедә.

Көз өйдә.

*Казан*
*гыйнвар, 1974*

# Синең өчен яшим

Җырлар җырлап күңел юатам.
Калган кебек булам бушанып.
Көнне төнгә ялгап озатам,
яңа туар таңга ышанып.

К у ш ы м т а:

Синең өчен яшим, Синең өчен янам,
Синең күзләр белән күрәм дөньяны.
Сагышымның, хисләремнең юк чик-яры,
гашыйк булган кеше аңлар минем җанны.

Белмим алда ниләр көтәсен,
сагыш баскач, нихәл итәсең?
Карап калыйм күзем тулганчы,
вакыт җиткәч, тотмам, китәрсең.

К у ш ы м т а:

Синең өчен яшим, Синең өчен янам,
Синең күзләр белән күрәм дөньяны.
Сагышымның, хисләремнең юк чик-яры,
гашыйк булган кеше аңлар минем җанны.

*Казан*
*февраль, 1974*

## Актриса монологыннан

Кайчак язмыш, тотып якадан,
уттан алып сала суларга.
Сәхнәләрдә яшәп, ә тормышта
туры килә күпме уйнарга!

Елар чакта кайчак елмаясың, —
ни сурәткә керми бу йөзләр!
Мөмкин түгел икән бәхетеңне
теш күрсәтеп кенә тигезләү.

Гримны да салмый ашыгасың,
ханжа уйлый: аны кем көтә?!
Суык ишегеңне ачып кергәч,
юылмаган идән, кер көтә...

...Үткән бәхетләрдән хатлар калган,
поезд билетлары, йөзекләр.
Киләчәктә нәрсә? Ялгыз почмак,
песи балалары, нык бикләр...

Яшьлекне без чәчүен юмарт чәчтек, —
кем уйлаган ниләр урасын?
Гөлләр түгел, күз яшь белән икән
сүнүләрнең премьерасы...

Алкышларда баш июне гел-гел
талант өчен бүләк дигәнбез.
Иелә-иелә шулай, ахры, бераз
дөньяга да башны игәнбез...

Халык күз алдында янып та соң,
тарих, кайтып, без дип, ни әйтә?
Кемнәр генә калган көндәгеңнең
көне белән үлгән сәнгатьтә?

Сәхнәләрдә нәкъ чын шикелле итеп
күпме үлдек, күпме терелдек!
Кешеләргә җирдә яшәр өчен
күпме куәт, көч һәм рух бирдек!
Үзебезгә
яшәү өчен ничек көч табарга
кыска гына чын бер гомерлек?

*Михайловское — Казан*
*июнь, 1974*

* * *

Талаштык. Сәгать югалттык.
Соңыннан эзләп таптык.
Ансын — таптык, ә бәхетне
табалмаслык югалттык.

Әй, Вакыт, кайтмас Вакыт!
Тилереп йөргән Вакыт...
Сәгать — төзек, без — ватык.
Хәл шундыйрак вакыт.

*Займище*
*4 август, 1974*

## Безнең байлык

Алтыннар, көмешләр, гәүһәрләр...
Күзләрен яндырган кемнәрнең!
Мин исә хәтергә энҗе итеп
тезәмен бәхетле көннәрне.
Бар алар, бар алар — бернигә
алышмас бәхетле ак көннәр!
Картлыкта дисбе итеп хәтердән
аларны тартсам да үкенмәм.

*Займище*
*август, 1974*

* * *

Күк — зәңгәр чатыр иде дә,
Җир — дулкын-түшәк иде...

Өстебезгә тургай егылгач,
нәрсәләргә икән юрадың?
Арышларны кочып еладың!..
Сөенечтән булгач, тыймадым.

Сүз куештык кабат килергә.
Зәңгәр чәчәк калды озатып.
........................................
Сискәндереп җанны, оялтып,
беркөн хәтер куйды кузгатып.

Килдем ялгыз.
Кыр буш.
Кая арыш?!
Камылына кадәр якканнар!
Син килгәнсең беркөн,
ә ул җиргә
яткан булган инде ап-ак кар...

*Казан*
*сентябрь, 1974*

## Яз башы

Тагын озынайды көннәр!
Озынайды маңгайдагы эзләр,
кар сулары...
Бергә булган вакытларны искә төшереп,
болдырлы йортлар,
вокзал баскычлары,
манаралар,
күпер-ярлар
озаграк тора башлады,
Кояш астында
күзне күбрәк сагышлатып...

*Казан*
*2 март, 1975*

* * *

Күпме уйлар чыгалмыйча калды!

Яманлыкның күзен алырдай,
егылганны торгызырдай,
җан хөрлеген уятырдай
күпме сүзләр буылып калды
иреннәрнең эчке ягында!..

Бу иреннәр — гүя җәллад,
гүя — деспот, буып торучы,
гүя — төрмә стенасы,
җил үтмәслек бер вал.
Иреннәрнең эчке ягында
хөр фикерләр каберлеге...

...Син үбәсең шашып
(бер илаһи ләззәт тоеп),
дөньяга чыгарга дип,
иреннәргә кадәр
алгысынып килеп җиткән
хөр уйларны, фикерләрне
сыта-сыта,
изә-изә...

*Казан*
*10 май, 1975*

# Займище

Уң якта — Иделнең салкын сулавы.
Сул якта — урманның шомлы шавы.
Баш өстемдә — тау-тау ямьсез соры болытлар аунавы.
Күңелемдә — бушлык.
Бүлмәмдәге кәгазь өстендә — кипкән күбәләк.

Кинәт —
поезд тавышы!
Төнне ярып,
рельсларны нурга манып,
алтын алма булып,
тәгәри,
        килә бәхет!

Уң якта — Иделнең җылы сулавы.
Сул якта — урманның назлы шавы.
Өстә-биектә — йомшак, күркәм болытлар тавы.
Көз.
Муллык.
Төн.
Син.
Рәхәтлек.
Бәхет.

*Займище*
*23 август, 1975*

## *Ул еллардан якты булып хәтерендә...*

Мин китергән гөлләр янган учакта!..
Ул чакта
алар өчен табылмаган бер почмак та —
Синең кочакта.
Ләззәтле һәм дәртле,
                    яшь, кайнар кочакта.
Һәр якта
гел чәчкә ул чакта!
Ул чакта
    һәр якта...

...Хәзер җилләр сөйли шул хакта:
салкын, имеш,
һәм дә буш Синең кочак та...
Калган ди ул еллардан якты булып хәтеремдә
фәкать мин китергән гөлләр генә!

*Казан*
*сентябрь, 1975*

## Диңгез ярында

Меңәрләгән монда чибәр тәти ташлар!
Бик күп җыйдым истәлеккә дип.

Үзем җыям иелеп,
ә күз алдымда —
без бәхетле бергә чакта,
Синең минем учыма салган
гап-гади бер
Кама яры чуерташы...

*Куктубә*
*29 сентябрь, 1975*

# Менә тагын...
## яки
# онытылмас мизгел бәхет

Һаман күңелдә,
күңелдә һаман
таныш түгел берәүнең йөзе.

Аэропортта,
самолетка утырып, күк катына менәр алдыннан,
бәхетле бер якынлык тоеп,
телəп,
яратып,
озак итеп бер карап калган иде ул!..

Рәхәтләнеп,
изерәп,
ләззәтләнеп,
апрель кояшындагы кар кебек,
эреп тордым мин дә
ул карашта.

...Менә тагын,
күпме ел үткәч,
Бөгелмәдән ерак-еракта,
таулы-ташлы диңгез ярында
тагын бер йөз.
Инде бүтән йөз,
әмма шул ук күзләр,
нәкъ шул ук караш!
Нинди якынлык!

...Исемеңне дә Синең сорамадым,
дулкын ерып үтеп барышлый,
«рәхмәт» дидем күңелемнән.
Син дә,
бәхетле бер каушау белән,
сүзсез генә миңа баш кактың...

*Куктубә*
*5 октябрь, 1975*

## Син хәтергә килгән минутлар...

Зәмһәрир кышкы суыкта,
юлчы булып үтеп барышлый,
боз челтәрле тәрәзә аша,
шау чәчәкле яран гөл күреп,
сөенеп елмайган чагы күк
гомеремнең…

*Казан*
*август, 1976*

* * *

Күзләрендә һәрбер хатын-кызның,
һәр ханымның
(нинди генә яшьтә булса да)
тартып торган үзгә очкын-нур бар.

Бу тылсымлы чаткы,
бу сөйкемле балкыш
хыялларда күкрәп үскән чакта күпме булып,
хәзерге көн күпме калгандыр?

…Кайсысының күңел нуры
салават күпередәй булып та,
күзләрендә хәзер
чак беленер бер төсе калган.
Кайсысының бераз күбрәк…

Монсы бер хәл,
килешерлек бер фаҗига.
Икенчесе — иң авыры —
таныш түгел ятлар күреп тә,
якыныңның, җан теләгән кешеләрнең,
таң йолдызы кебек аз гомерле
шул нурны да шәйләмәве…

*Казан*
*август, 1976*

* * *

«Кадерсезем минем, кадерсезем!»
Уйнап кына әйттең,
яратып.

Никтер шундук күз алдыма килде
мең-мең еллар буе шомарып,
дулкын кагып, комга чыккан саф гәрәбә.
Ята сары кояш —
җемелди!

«Кадерсезем!..»

Әллә инде
безнең язмышларда чарланып,
фаҗигаләр белән тулышкан —
барыбызга да кулай ята торган —
гасырлардан безгә мирасмы бу сүз?

Күктән иңгән вәхи кебек,
һаман, һаман
иңрәп тора колак төбендә,
баштан сөеп әйткән сүзең:
«Кадерсезем минем!
Кадерсезем!..»

*Казан*
*2 сентябрь, 1976*

## Бәхетле бер язның кичендә

Борынгы Казанны буйладык.
Хисләндек. Сөйләштек. Серләштек...
Бер тынып, капылттан икебез
таш сарай йортларга эндәштек:
«Без — кунак күбәләк, ә бит сез —
мәңгелек!..» Ахыры, көнләштек.

Ә кайткач кадими бүлмәгә,
ләззәттә бер яндык, бер талдык...
...Тәрәздән күренә диварлар,
манара утыра кызарып...
Мең яшәп, бер мизгел бәхет тә
тоймаган Таш илен кызгандык.

*1971–1976*

## Кашларың карасына ла...

Карасалар карасыннар
кашларың карасына.
Ят күз укларын үткәрмә
керфекләр арасына.

Кашларың карасына ла,
гөл куйдым арасына.
Тик Синең карашың дәва
йөрәгем ярасына.

*Казан*
*9 гыйнвар, 1977*

## Сездә рәхәт, сездә кыен миңа...

Сездә рәхәт!
Сездә гөлләр бүтән.
Сездә кояш үзгә карый күк.
Сезнең сәгатьләр дә гомерләрнең
тик бәхетле чагын саный күк.
Сездә ишетелгән һәр аваз да
кабатланмас гүзәл көй сыман.
Сездә бөтен тараф нурга тулган.
Сездә, ахры, һәр як кыйбла.
Сездә рәхәт!
Үзгә дөнья!..

Сездә кыен.
Сездә читен миңа.
Сездә бар төшемне ут ала.
Сездә син кагылган бөтен нәрсә —
тәрәзәләр, диварлар яна!
Кашагалар, китаплар яна...
Карашыңнан дөрләп мин янам!

Ике арада тагын кем яна?..
Йа Алла!

Сездә рәхәт,
Сездә кыен миңа...

*Казан*
*гыйнвар, 1977*

* * *

Очрашканга күпме генә!
Инде йөз ел белешкән күк!
Синең белән бар үткәнне
гел икәүләп бүлешкән күк.

Каян килгән тәңгәллек бу! —
сулышта да, адымда да.
Синең уең миннән үтә,
минем каным Синдә ага.

Синең шатлык — минем шатлык,
минем көйләр — Синең көең...
Минем белән табышканчы,
кем идең дә кайда идең?
Кайда идең?..
.......................................
Без әллә булганбыз микән
бер үләннең яфраклары?
Кеше булып очрашыр өчен
аерылганбызмы аннары?

...Менә тагын аерылабыз.
Юлы кая бу көннәрнең?..
Син дә берни әйталмыйсың,
тик дерелди иреннәрең...

*Казан*
*февраль, 1977*

## Нәфес салып

Гөл чәчкәсе куйган идем
бер яшь сылу күкрәгенә.

Ә ул — чукмар булып төшкән
Синең йөрәгеңә...
Ишеттерделәр.

*Казан*
*27 март, 1977*

* * *

«Ун гомер аз, бар ләззәтен
тоярга бу тәннең, бу кочакның!
Мең кочкан, йөз үпкән, шулай да
гел яңа, гел үзгә, гел татлы!..»

...Кайчан дип тә әйталмыйм хәзер
бу сүзләр яңгыраган ул чакны!..

*Казан*
*27 март, 1977*

## Син киткәч

Каплады күңелемне яралы болытлар.
Ява оеп.
Ява коеп...

Ишегалдындагы әнисләргә явар иде... —
яңгыр түгел,
кан ява шул!..
Тоташ кан ява...

*Займище*
*1 июнь, 1977*

## Утрау

Ул кояшлы утрауны Синең өчен эзләп таптым.
Торсын, дидем, бер
таҗы булып табигатьнең
кешеләрсез яшел дөнья уртасында!
Яшәсен бер, дидем, онытылып,
җил, дулкыннар белән берлектә!

Синең өчен иде утрау!
Синең өчен иде Вакыт!
Синең өчен идем... мин!

...Хәзер утрау дигәч, искә төшә —
палатка янындагы гөлҗимешләр,
йокы аралаш ишетелгән пароход тавышлары,
шыбыр-шыбыр яуган төнге яңгыр...
Искә төшә —
яртысы да укылмаган калын китап,
Кама ярындагы керәшә оялары...
ә Син,
ә Син — юк...

*Займище*
*11 июнь, 1977*

## Бакча. Төнге учак. Июнь

Утырабыз. Өчәү: учак, уй да мин.
Төнге тынлык.
Бөек берлек.
Идиллия.
Рәхәт.

...Чү! тагын кем анда?
Өч-дүрт адым якында гына
алсу шартлау булып мәк ачылды!

...Әллә Син дә инде
утырасың кайдадыр еракта,
ялгыз ут ягып,
мине сагынып?..
Ялкыныңмы минем янга төште,
мәк чәчәге булып, кызарып?..

*Займище*
*17 июнь, 1977*

# Тагын шул аланда

Басып торам
үткән ел без икәү бергә
кочак-кочак
ромашкалар җыйган аланда.

Бу юлы ялгыз.

Быел үләннәр тагын да шәбрәк!
Чәчәкләр тагын да мулрак!
Аланлык — кояшлырак!

Үздем бер ромашка.
Бүтән өзалмадым.
Күңел тулды. Күз томанланды...

...Ялгыз күке кычкырды агач башыннан
ике тапкыр...

*Казан*
*20 июнь, 1977*

## Тагын мин соңардым...

Мин беренче чәчәкләрне эзлим.
*С.Хәким*

Беренчеләр! Фәкать беренчеләр!
Беренчеләр кала дөньяда!

Булалмадым бугай гел беренче
эштә, йөгерештә, көрәштә...
Бер юаныч: Син беренче идең минем!
Горурланып йөрдем гомрем буе.

...Мине ташлап киттең дөньядан.
Тагын миннән алдан.
Беренче булып...

*Казан*
*9 июль, 1977*

* * *

Очты, китте Сөю!..
Ак күгәрчен булып очты!

Калды Бурыч —
кургаш кебек авыр
кара каурый.

*Займище*
*22 июль, 1977*

* * *

Гашыйк бер пар үтте янәшәмнән.
Туктап-туктап шашып үбешәләр!..

Юк, көнләшмим кеше бәхетенә.
Минем дә булды былбыллы чаклар!
Шат авазым күмде күкрәүләрне,
офыкларгача янды учаклар!

Бәлки, ул чаклар туры килгәннәрдер
кара көннәренә кемнәрнеңдер?..
Мин, сөюдән исереп, бу дөньяны
гел ал да гөл диеп йөргәнмендер.

...Менә бүген миңа килеп тиде
кара кайгының канлы канаты.
Янам эчтән, үксим... әллә нишлим —
шушы була микән инде җан ату?

...Алар бара. Көлә, шаяралар!
Шулай кирәк — иңдә бәхет барда!
Озаграк торсын сездә бәхет кошы,
миңа кунган чакка караганда!

*Казан*
*31 август, 1977*

# Безме соң бу?
## яки
## хушлашкач янә бер очрашу

Хыялланып, балкып-янып сөйләр сүз юк.
Элеккечә очып түгел,
шуышып кына чыга сүзләр.
Утырулар шул ук,
урындыклар шул ук...
сөйләшүләр бөтенләй бүтән!

Һава хәлләреннән зарланулар,
эчә торган чәйнең мәтрүшкәсен мактау,
әдәп өчен «хәлең ничек?» диеп сорашулар,
уртак танышларны искә төшерү,
һәм тагын чәй,
һава хәлләре...

...Кисәк-кисәк икебезнең дә искә төшә
шашкан чаклар (сизәм): яхшысы да, яманы да...

Тик аларны искә төшерүне
белгертәсе килми бер-беребезгә.

Күзләр генә ара-тирә,
онытылып,
очкынланып янып ала
элеккечә!..

*Куктубә*
*13 октябрь, 1977*

## Экстаз

Мин сөйдем шундый ярны!
Оныттым мин елларны!
Кемнәр анда тәхеттә?
Мин коендым бәхеттә!

Мин сөйдем шундый ярны!
Оныттым мин дөньяны!
Айныдым яныып беткәч,
Аны да бәхетле иткәч...

Мин сөйдем шундый ярны!
Сөйләргә телем ярлы...

*Казан*
*4 ноябрь, 1977*

# Тагын бер кат искә төшерү

Якынлаштым, тартылдым.
Хыялландым, омтылдым.
Уйда гына очрашсам да,
ләззәтләндем, онытылдым.

Уй бүлештем, серем чиштем,
эшемдә киңәшләштем.
Сәфәремдә юлдаш иттем,
төшләремдә эндәштем.

Тарып рәхәт газапларга,
Мәҗнүннәрчә яраттым.
Чак кына төссезләнсә дә,
хыялымда яңарттым.

...Ул нишләде? Белалмадым...
Язмыш безне кушалмады.
............................................
Барыбер бәхил багалмама!

*Казан*
*23 ноябрь, 1977*

## Зур урам

Гашыйкларга
бөтен Җир-шар — бер зур урам!
Безнекенең исеме дә иде —

Зур урам!

...Ун елдан соң
шул урамда басып торам.
Бәләкәй бу урамга
безнең зур мәхәббәт
ничек сыйган?

*Казан*
*11 декабрь, 1977*

* * *

Мәхәббәтме?
Әйе, мәхәббәт бу!

Хыянәтме?
Аңа хыянәт...
Хыянәттән китим дигән идем,
«Сау бул!» — диде миңа Мәхәббәт.

*Казан*
*12 декабрь, 1977*

## Яшьлек бүреге

Ах!
Татлы иреннәрдән баш әйләнеп,
тәгәрәде бүрек ак карга!..

Исемдә:
төшмәсә дә, толымнарың буйлап
шуды шәльяулыгың Синең дә!..

Шуды...
Шуды еллар,
    яшьлек,
        сау чаклар...

...Басып торам хәзер
ул елларның күләгәседәй,
суык яңгыр астында
бүрексез, яланбаш...

*Казан*
*25 декабрь, 1977*

## Мәхәббәт

Күпме чәрдәкләнде йөрәк
татлы яралардан!
Җәрәхәтләнүен телим —
Һаман,
һаман...

*Казан*
*27 декабрь, 1977*

# Рәсем

Зәңгәр күктә карлыгач
ясады рәсемеңне!
Мин күңелемә күчергәнче,
ак болыт көнләшеп,
каплап та өлгерде…

*Казан*
*5 гыйнвар, 1978*

## Кил!

«Кайчан да булса,
кайда да булса...» түгел, —
Син хәзер кил!
Күрешер җирне үзең беләсең...

Кил Син йөгереп!
Кил Син җилдәй очып!
Бөтен ялгышларың,
авыр язмышларың,
кара каргышларың белән кил!
Килсен әйдә, чегән шәле кебек сөйрәлеп,
минсез үткән ерак елларың!
Теләсәләр, килсен ияреп
авыруларың,
рецепт-даруларың,
тузган күлмәкләрең,
ачуларың...

Кил! Бик озак көттем Сине!
Тик соңарма бу юл,
Соңарма!..

*Казан*
*5 гыйнвар, 1978*

* * *

Яратты! Аңламады...

Ярату — иңгән бәхет ул!
Күктәнме? Каян? Белмим...
Яраткан өчен кемгә дә —
хак та, рәхмәт тә тими.

Ярату өстенә — аңласаң,
тойсаң ярың җан тибешен —
шул чакта мең рәхмәтләрлек,
табынырлык зур кеше Син!

Яраттым! Аңламадым...

*Казан*
*14 гыйнвар, 1978*

## Яшьлек дәфтәрендә – саф сүзләр

Аерылсак,
сагынган чакларда карар өчен
билге иткән булганбыз бер йолдыз.
Ул — күзгедәй —
бер-беребезнең карашларын
нуры аша җиткерергә тиеш.

Укыдым да яшьлек дәфтәреннән
бу сүзләрне,
чыктым атылып,
багар өчен күк гөмбәзенә.
Кайсы йолдыз соң ул? Кайсы?

Адашты күзләрем...

*Казан*
*11 февраль, 1978*

# *Ул*

Бигрәк саф! Бигрәк ак! Бигрәк пакь!
Яман уйлар аңа яттыр...

Күләгәсе әгәр булса,
Җирдә түгел, ул — күктәге ак болыттыр!

Җанына ачкыч —
йолдыз эчендәдер!

Ә ул йолдыз үзе —
мин белмәгән бер
бәхетле кешедәдер...

*Казан*
*18 февраль, 1978*

## Имеш, мин дә яр сөйдем!..

Мин дәшкәч, сүз катмады.
Үзе... килеп күреште.
        Дәртләндем дә ярсыдым!
        Имеш, мин дә яр сөйдем!..
Минем белән сер бүлеште.
Бүтән белән үбеште...
        Кызыштым да ярсыдым!
        Имеш, мин дә яр сөйдем!..
«Гыйшык тоталар икән!» — дип,
таныш-белеш сөйләнде!
        Үчектем дә ярсыдым!
        Имеш, мин дә яр сөйдем!..
...Бер көн мин дә көйләндем.
Бүтән кызга өйләндем.
        Үкседем дә ярсыдым!
        Имеш, мин дә яр сөйдем!..

*Казан*
*22 апрель, 1978*

## Өшү

Бакчаларда ярыла пешкән кавын.
Кош әлсерәп тора куакта.
Кем ышаныр: «Бозлар кебек булып,
җаным өши», — дисәм бу чакта?
Хыянәт!
    Хыянәт!
        Хыянәт!
«Кемең соң ул? — дисең, — ярмы, дусмы?»
Сиңа ансы нигә? Сорама!

...Тормыш бара. Әнә поезд үтә.
Гөлләр үсә. Әнә су ага...
Бер бәндәсе бүген күшеккән, дип,
ничек сүз әйтәсең дөньяга!

...Бакчаларда ярыла пешкән кавын!
Кемдер җыяр кичкә мул табын.

*Казан*
*24 май, 1978*

## Ни оттың?

Мәхәббәттә хәйләләдең.
Җырларыңда алдаштың.
Хыялларың — оныттың...

Тормышыңны уен итеп,
ни тоттың да, ни оттың?

Бәхетсезлегең оттың!

*Займище*
*19 июль, 1978*

* * *

Сөенеп яшим шуңарга:
балачактан хыялымда
йөрткән кешем — Син барга!

...Очраша алмасак юлларда —
күрешербез җырларда.

*Казан*
*19 июль, 1978*

## Гомер – дулкын

Дулкын арты дулкын килә.
Минем гомрем кайсысы?
Әллә Синең кулда инде
әҗәлемнең кайчысы?..

...Акчарлаклар безнең өстә
кычкыра, шаша, көлә!
...Синең гомер дулкыны да
ярга бәрелеп килә...

*Пицунда*
*1 октябрь, 1978*

* * *

Күпме матур яфрак агачта!

Күшеккән кошны ышыклаган
яфраклар ямьлерәк!

Күпме чибәр хатын дөньяда!
Бала үстереп сулышкан
хатын-кыз чибәррәк!..

*Түбән Кама*
*8 декабрь, 1978*

* * *

Май уртасы — җәй башы.
Аерчалы тал башы.
Диваналарга әйләнә
гашыйк булган яр башы!

Өмет тулы ай башы.
Ник җирдә яшен ташы?
Күпне күргән уенчаклар
ашыйлар асыл башны...

*Казан*
*16 декабрь, 1978*

* * *

Чәчәккә кунды бал корты
бал өчен.
Чибәрне сөйде яшь егет
дан өчен.

Дошманына бал кортының
ук хәтәр!
Юхалыкка эремә, егет,
шулкадәр!

...Үлән арасында үле
корт ята.
Башын игән ирне тик җил
юата...

*Казан*
*16 декабрь, 1978*

# Өфе вакыты

Өфедә вакыт исәбе безнекеннән
ике сәгатькә алда йөри.

Үз вакытыңча
самолетта
уникедә очып киттең Агыйделдән.
Безнеңчә нәкъ уникедә
син Иделдә идең инде.

Ике сәгать буе БӘХЕТЕМ минем,
Вакыт исәбенә «кермичә»,
тибрәнеп торды күк катында,
тургай кебек,
мине тәкатьсез көттереп...

*Казан*
*6 февраль, 1979*

# Яшьлегендә чибәр булган бер чал әби сүзләре

«Кем белән каралдың —
шуның белән агар!»

*Әнисенең әйткән сүзе*

— Башта ни карадың?
— Күзенә карадым!
Зәп-зәңгәр күзенә!..
Күзендә чагылган
үземә карадым!
Аннан соң... изерәп,
җәйге төн күгенең
йөзенә карадым...

Әрләмә, каргама,
хәлемә кер, әни!
Мин теләп алдым бит
бәхетле ярамны!
Ышанасыңдыр бит —
мин фәкать агардым!
Күңелем агарды!
Уйларым агарды!
Сөюдән кешеләр
чистара бит бары!
Тик аннан соң гына,
ятларның сүзеннән
йөзләрем каралды...
..............................
Әнием, рәнҗемә!
Мин тагын агардым.

Йөзләрем агарды.
Чәчләрем агарды...
Кабере генә аның
(Син белгән егетнең!)
тора әле каралып...
Бураннар керүгә,
ул да, әни, агарыр,
агарыр...

*Казан*
*14 апрель, 1979*

## Язгы сагыш

Төш авышкач — ташу ишәя.
Кичкә кергәч — сагыш көчәя.
Төн тыңладым гөрләвек шавын...

Таңда сиздем җанның бушавын —
ычкындырды Хәсрәт тышавын —
төштә Сине күрдем мин тагын!

*Казан*
*25 апрель, 1979*

* * *

Зәңгәр давыл — диңгез-ярда.
Алсу дәһшәт — янгыннарда.
Яшел ташкын — урманнарда.
Ап-ак мәхшәр — бураннарда...

Берәм-берәм һәммәсен дә
күргән, тойган бар иде лә!
Менә хәзер барсы бергә
тоташ кайный күңелемдә!

Өзгәләнү-януларның —
ташкыны да, мәхшәре дә,
дәһшәте дә, давылы да...
сагынуларның-сагышларның —
яшеле дә, алсуы да...
һәммәсе бер җанымда!
............................................
Ябышып җилләр ялына,
барыр идем лә ярыма!

Еллар куе төтен булып,
күзләремә сарыла!..

*Казан*
*8 май, 1979*

# Фейерверк

Ромашка таҗларын җыйдым да учыма,
чөйдем! —
чалкан ятып күргән күгеңә!

Әй, кояшлар яуды өстеңә!!!

Берсе ачык күкрәгеңә килеп кунды.

Мин озак итеп карап тордым
ул сөйкемле кояш-чәчәккә.

Күзләремдә — рәхәт иркә төс.
Колакларда — бәхетле чың:
ишеттем мин Синең аша
бу җәйнең иң назлы сүзләрен!

«Беркайчан
        минем болай
                бәхетле
                        булганым
                                юк иде!..»

*Казан*
*13 июнь, 1979*

# Бер җәйге кич хатирәсе

«Бәхетем!» дип, миңа капланып,
күкрәгемне тутырып еладың.

Балконлы йортлар артыннан — каяндыр
безнең халәтләргә иш булып,
тальян гармун шыңшып торды
балачактан газиз бер көйне.

Үз ялкынын һәркем үзе йотып,
әле яңа гына табыша алган
ике ятим туган шикелле,
сүзсез-нисез, сарылышып бер-беребезгә,
утырдык без ут та алмыйча.

...Елады да гармун елады.

Керфекләрне керфек иркәләде.
Сәгатьләргә күз салырга курыктык без.

...Гармун тынды бермәл.
Дөнья шым калды.

...Безне такси озатып йөрде берәм-берәм
моңсу, җылы җәйге төндә
яралы лабиринт урамнар буенча.

*Казан*
*16 июнь, 1979*

## Кышкы Займищега янә килгәч, күңелемә кунган бер сагыш

Кызыл миләшләрне сыкы сарган.
Кара миләшләргә бәс кунган.
...Чагылып ала ап-ак чәчәкләре —
яздан калган хәтер-очкында.

Күңелемдә тагын бер төс-сурәт
миләшләрне аралый һаман:
...Син ул язда миңа килгән идең
кара итәк, кызыл кофтадан!

Бергәлектән күңел шашкан иде!
Дөньям калган иде агарып!..
...Торам ялгыз басып Аккар илдә.
Күңелем — буш. Уем — караңгы...

*Казан*
*25 июнь, 1979*

## Бер уйласаң: еллар ул – мизгел...

Миңа — вагон тамбурына карап —
юл читеннән
яулык болгап калды бер сылу!

Гүя ул — Син.

Аерма шул:
күз карашын аның татыдым бер мизгел.
Синең исә —
кан тибешен тойдым бераз озаграк —
        унбиш еллап.

Үтте-китте
        җил уңайга
                унбиш
                        кул болгау...

*Сараево*
*16 июль, 1979*

## Әдрән диңгез. Дулкын. Сихсез төн

Җылы дулкыннары килеп кагыла.
Иркәли дә бугай, ник тоймыйм?
Муеннарга килеп сарыла, —
назламакчы бугай, бирелмим...

Төнге дулкын сау кешене,
серле ярның гыйшкы кебек,
шаштырырга тиештер ләса!
Яндырырга!
        Өшетергә!
                Кирәк икән —
                        үксетергә!..

...Таулар арасында бер ут кына,
нидер әйтмәк булып, үз итеп,
талпынып-талпынып ала җемелдәп...

*Бечиче*
*20 июль, 1979*

## Авылда сине сагыну

Сукмагым каршыннан очты бер кошчык…
Ул — синең сәламең түгелме?

Тулган Ай янында бер нәни болыт…
Ул — Синең көләгәң түгелме?

…Яңгыр булып аксам толымыңнан —
ни диярсең минем күңелне?

*Юлсубино (Балтач)*
*4 август, 1979*

# *Минем беләм...*

Андыйларны-мондыйларны инде байтак күргән бар, дип,
Син уйладың бугай мине, бер гадәти җаный яр, дип.

...Еллар үтеп, шактый хәлләр кичте башың минем белән!
Биргән ашың, аткан ташың — онытмадым! — минем белән...
Хәзер инде бик яхшы итеп беләсең Син, мин дә беләм:
ул гомерләр — терсәк кыска! — кайтарылмый берни белән!

Хәзер — элек булганнарны искә алган күк минем аша,
килерләрен бәһаләрсең чагыштырып минем белән.

*Казан*
*15 август, 1979*

## Өгәу

Йоклый алмыйм. Беләм: тагын кемдер уяу, —
«тота» мине үз дулкынында.
Әсир итеп тота. Ычкындырмый. Әйтерсең лә
мин бер хәнҗәр аның кынында.

Кем ул? Онытылган ярмы? Бер көндәшме?
Үч итепме, сөепме саклый?
Нинди язмыш белән, ни ниятләр корып,
газапланып, мине газаплый?

Йоклый алмыйм. Гипноз? Телепатияме?
Әйталмыйм шул анык берни дә.
Беләм шунсын:
мин яраткан кешем бу сәгатьтә
башын салып йоклый чит илдә...

*Казан*
*6 сентябрь, 1979*

# Тау башында Синең тәрәзәң

Синең сынны миннән яшереп —
җәен өер кошлар оча;
көзен яфраклар аралый, —
сары-кызгылт челтәр ясап;
яңгыр каплап, толымын төшерә;
кышын, котырып, буран томалый…

Язын —
дөнья аяз чагында да,
күзләрдәге сагышлы дым
томанлата
        Синең
                тәрәзәңне…

*Куктубә*
*29 сентябрь, 1979*

* * *

Күңлеңә Сагыш атлы кош очырдым.

Минем йөрәк тибешенчә
каксын, дидем, канатларын!

...Күзләреңнән яшьләр бәреп чыкты.

Һәм мин тәгәрәдем
йөзең буйлап,
тамчы булып.

*Куктубә*
*30 сентябрь, 1979*

# Көтелмәгән бер мизгел шатлык

Диңгез буенда мин Сине көтәм.
Телеграмм көтәм, хат көтәм...
Читкә киткәч кенә беленә икән
бар газабы сагыш-өметнең.

Яттан беләм расписаниеләрне,
самолетлар килер минутны.
Почтальоннар белән дуслаштым мин,
куя күрмәсеннәр онытып...

...Бүген иртән яр буенда йөрим,
бер җаныма урын тапмыйча.
Чү! Бу соң нинди таныш чалым?
Баш очымда нинди кош оча?

Сыерчык бит! Безнең сыерчык бит!
Безнең яктан килгән җан бит ул!
Туган якның алсу таңнарына
канатлары тигән җан бит бу!

Мин бик озак аңа карап тордым.
Татлы дым сарганчы күземне.
Ә ул очты ары. Ясап күктә
силуэтын Синең йөзеңнең.

*Кукчубә*
*5 октябрь, 1979*

* * *

«Бу очрашу — татлы әкият!
Мең дә бер кичә! — дисең. —
Юк, мең дә бер кичә түгел,
бердәнбер кичә!» — дисең.
...Китәсемне искә төшереп:
«Сәгать соң ничә?» — дисең.

Аз шул, аз шул әкияти
бу бердәнбер кич кенә!
Ул бит бары — куктән иңеп,
Син кергән бер төш кенә...

*Куктубә*
*9 октябрь, 1979*

# «Алтын капка»*

— Син «Алтын капка»ны йөзеп чыкканда нинди теләк әйттең?
— Алдагы гомердә бөтен-бөтен капкаларны да икәү бергә үтсәк икән! — дидем. — Ә син?
— Әйтмим... Минем өчен бергә яшәр еллар әйтсен!

Мин тартмадым аңа киндер.
Якмадым буяулар да.
Ә сурәтеңне ясадым
«Алтын капка»лы ярга!

Акчарлакның канатлары
минем пумалам иде!
Ә төсләрне — дулкыннардан,
Кояштан алган идем!

Шундый сурәт килеп чыкты —
үзең белмисең генә!
...Җилләрдән көнләп, тизрәк
күчердем күңелемә.

Ул сурәт калды анда да,
нурлы итеп кара гына!
Күрә алыр шул аны тик
сөюдә янган гына!

*Кукту́бә*
*10 октябрь, 1979*

*«А л т ы н к а п к а» — Кырым яры буендагы мәшһүр кыя исеме.

# «Изге тау»* башында исемең

Тау башында ташлар тезеп,
яздым мин исемеңне.
Изге тауга менгән кеше
исемеңне белсен! дидем.

Кошлар күреп укысыннар,
алар Күк телен белә!
Җилләр килеп сыйпап үтсен,
минем наз белән генә!

Көмеш чыклар кунсын аңа,
шатлык яшьләре булып.
Яшен-таш төшсә дә ярый,
яшьлек яшьнәве булып.

Кар бөртекләре сарылсын,
яңгыр толымы төшсен...
Яннарында чирәм шытсын,
хуш-исле гөлләр үссен.

...Изге тауда — ап-ак ташлар,
Ташларда — Синең исем.
Кемдер өчен гади исем,
ә миңа — изге исем!

*Куктубә*
*14 октябрь, 1979*

*«Изге тау» — Кырымдагы Карадаг массивындагы тау исеме.

# Март

Карлар эри тышта... Бетә, китә аклык...
Бүлмәңдәге синең туй күлмәгең — ул да —
эреп бетәр күк...
һәм... мин калырмын кебек
шәрә, ялангач.

*Казан*
*8 февраль, 1980*

# Кышкы урманда

Без — гөнаһлылар...
Култыклашып рәттән атлыйбыз. Икәү. Рәхәт.
Безнең чаңгылардан кала — гамьсез дүрт эз.

...Ә бер эзнең ерак очында
минем улым
яланаяк басып тора күк.

*Казан*
*19 февраль, 1980*

* * *

Элек әйттем: «Нигә, — дидем, —
башта Сине күрмәдем...»

Аннан ниләр күрмәдем!

...Бу дөньяда күпне белдем.
Кадереңне белмәдем!

*Казан*
*10 март, 1980*

* * *

Ч-га

Хатлар белән яшим. Гомерем минем —
конвертларда, штемпельләрдә...
Ашкынуны әйтер сүзләр көчсез,
хат килерен сизгән көннәрдә!

Эшкә барам. Кичен кайтам. Ансы —
хат көткәндә үткән бер ара.
Яшәү өчен түгел, көтү өчен
туганмынмы якты дөньяга?

Ә алышмыйм барыбер язмышымны
кемнәрнеңдер «чын» яшәвенә,
яшьлек идеаллары хисабына
баеп, симереп, шәбәюенә.

Мин үземчә рухи әзерләнәм
хыялдагы чынга, олыга.
Уйныйм дөньяда, йә өзелер,
йә бәхетле итәр бер кылда.

*Юлсубино (Балтач)*
*29 март, 1980*

* * *

Синең белән үткән гомер гүя —
таң алдыннан чыкта үткән эз.

...Күтәрелде Кояш.
Исте җилләр.
Һәм... юк без!..

*Пицунда*
*31 июль, 1980*

## Язгы болында. Без икәү

Өстебездән алтын яңгыр явып үтте.
Шат көлүең, көмеш аваз булып,
яңгырады тургайлар катында.

Иңнәремә назлы кагылган
нәфис кулың күләгәсе булып,
офыкта балкыды
салават күпере.

*Казан*
*26 сентябрь, 1980*

* * *

Кош очты, каурый калды.
Якыным мәхрүм калды...

Күңелемдә газиз бер чак —
без очрашкан яз калды.
Санаулы көн аз калды.
Кулда өзек саз калды...

*Казан*
*22 октябрь, 1980*

# Килә бергә уянасы...

Кемнең бар даннар аласы,
кемнең кала саласы!
Кемнең кеше көнләшерлек
маллар җыеп каласы...

Минем дә бар күңелемдә
өметләрнең яңасы —
килә Синең белән бергә
бәхеттән уянасы!

*Казан*
*12 апрель, 1981*

## Яраттым!

Мин түгелме, зифа каеннарны,
яшен эчә-эчә яраткан!
Мин түгелме, ярны — җелегемә
үтеп төшкән өчен яраткан!
Мин түгелме, ярдәм кулым сузгач,
күпме заттан җанны кыйнаткан!
Мин түгелме, күпме алданып,
ялган матурлыкка җан аткан!..

Тик үкенмим: һәрнәрсәне ихлас,
ышанып һәм чынлап яраттым!

*Казан*
*16 август, 1981*

## Әйткән ди бер ристан ирекктә бер кызга...

Безме! Без менә дигән яшәрбез!
Шундый матур булыр тормышыбыз!
Гел кулга-кул тотынып барырбыз!
Хыялларны эшкә ашырырбыз!

Күп итеп балалар үстерербез!
Гөрләп торыр безнең түр башыбыз!
Үзебезнең телдә алар белән
гел бәхет җырлары җырлашырбыз!..

Әйткән ди бер куян юлдашына:
«Тире базарында очрашырбыз...»

*Казан*
*23 август, 1981*

## Татлы рәхәттәге бер халәт

Мәхәббәттән тән кызышкан!
Кайный кан көче!
Шаштыра җиңәргә теләп,
бушану хисе.

Хәтергә килде бер сурәт:
урман, җәй исе...
Кәрәздән бал суырттылар —
купты корт күче!

*Казан*
*1 сентябрь, 1981*

* * *

Гомер буе җандаш эзләдем мин.
Азмы яныл чапканым булды!
Җандашлар, дип, күпме кандашларга
нурым түгеп бакканым булды!
Хәер... кайчак җандашларымны да
төшләремдә тапканым булды!..

*Казан*
*6 март, 1982*

# Үкену дә, әзрәк өмет тә...

Кирәк чакта ишетә алмадым —
назлы теләк: «Әче! Ачы!» —
...Шулай да көмеш яшьлектә
татлы кисте алтын кайчы!

Бакыраер картлыгыма
калыр, ахры, тимер кайчы...

Кисәр әле тутыкканчы!

*Казан*
*20 июнь, 1982*

# Чал акчарлагым минем!

*(Кама өстендә язылган шигырь)*

Кара көмешем минем!
Тере көмешем минем!
Гомер буе сагынырга
тигән өлешем минем!

Чал акчарлагым минем!

Дулкының булдым да... —
кунмадың!
Камышың булдым! Әй... —
тормадың!

Чал акчарлагым минем!

Иркәләр җил булдым... —
очмадың!
Җемелдәр чык булдым... —
йотмадың!

Чал акчарлагым минем!

Кадерен белмәдек
яшәүнең!
Минем бит күземдә —
ул — Синең яшьләрең...

Чал акчарлагым минем!
Чал акчарлагым минем!..

*Пермь*
*24 июнь, 1982*

# Килмәде яр...

Яр буена килмәде яр...

Ярылды урталай бар дөньям.
Ике якка кисте күкне реактив очкыч.
Гомер аерылды икегә:
Синең белән үткән өлеше,
һәм билгесез алгы көннәре...

Ә Казансу ага, Вакыт кебек,
гел бер җайга, ваемсыз гына.
Ике якка
        калып бара
                ике яры...

*Казан*
*7 август, 1982*

# Иясез шатлык

Уйный-оча күбәләкләр
Җанлы чәчәкләрмени!
Урманнарга, болыннарга
Шатлык чәчкәннәрмени!

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

Һәр көнне җиңү итәргә
кеше көч каян алсын?
Әй килә гомер кичәрлек
кемгәдер таянасы!

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

Күбәләк кунган чәчәкләр
матур да, горурлар да.
Кемгәдер кирәк булуың —
бәхет бит ул дөньяда!

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

*Наласа*
*23 ноябрь, 1982*

* * *

Үзеңә өметләнәмме?
Җиткән миңа күләгәң дә!
Кояш нурыннан ни? — китап
арасында сулган гөлгә!..

Мин Синнән ваз кичә аламмы?
Бу хәл булмас үлгәндә дә!
Фәкать Синең белән тулы
күзәнәкләр шушы тәндә!

Башта әйткән сүзләремнән
тәүбә!
Тәүбә!
Тәүбә!..

*Казан*
*11 декабрь, 1982*

* * *

Син миңа рәхмәт тә әйтмә...
Шулай ук каргама да!
Хәлне — кыен, Сиңа түгел,
үземә аңларга да!

Нишлисең, давылга эләгеп,
кораб юлдан тайпылгач!
Җил белән очраклы ярга
чыгарылып атылгач...

Син — утрау. Талгын ныклык,
Синдә игеннәр үсә!
Миңа айкалырга язган
дулкынга күчә-күчә...

*Казан*
*12 декабрь, 1982*

* * *

«Ничекләр киләсе булдың
өмет тә итмәгәндә?
Килдең менә үрелергә
инде кул җитмәгәндә...

Син! диеп янган идем бер
яшьлектә, көтмәгәндә...
Шуннан соң егерме еллап
әйтерсең үтмәгән дә!
...Ничекләр киләсе булдың
өмет тә итмәгәндә!»

Ничекләр китәсе булыр! —
яшьләрем кипмәгән лә...

*Казан*
*19 декабрь, 1982*

* * *

Тәрәз ачып, бер чибәр кыз
толымын тарап тора.

Зәңгәр күктә ак бер болыт
тукталып карап тора.

Толымнарын сүтмәк булып,
шук җилләр исеп тора.
Җил тегермәне аларның
канатын кисеп тора.

*Казан*
*апрель, 1983*

# Парлы ямьыз

Читләрдән караучыга без —
туйдагы пар ат кебек!
Ә эчләрдә яра саркый
чәерле нарат кебек...

Әйтәләрдер: «Бәхетлеләр!
Шат йөзләренә кара!»
...Диңгездә ялгызак калгач,
күздән тозлы яшь тама.

*Юрмала*
*24 май, 1983*

## Әгәр миңа ышанмасаң...

Әгәр миңа ышанмасаң…
«Ул яратамы мине?» дип,
җилләрдән сорап кара!
Алар да, минем шикелле,
«Шуны да белмисеңмени?» дип,
чәчеңнән тарап торыр.

Әгәр миңа ышанмасаң,
«Ул миңа тугрымы?» дип,
күкләрдән сорап кара!
Болытлар, минем шикелле,
«Шуңа шикләнәсеңме?» дип,
мөлдерәп карап торыр.

Әгәр миңа ышанмасаң,
шул ук сорауны биреп,
үзеңнән сорап кара!
Үзең мин булып кара!
…Күңелең тулы яшь булып та,
көлеп, елмаеп кара!

*Казан*
*12 сентябрь, 1983*

## Әй, сылу! Әй, җанаш!..

Әй, сылу!

Яшьлеген бик тиз җуйса да,
адәм дәрт хисен җуймас!

Әй, җанаш!

Куеның ачмый, җан тоймас!
Без кавышмый көн тумас!

*Казан*
*13 гыйнвар, 1984*

* * *

Һаваларда туктап калды
кошлар очкан төшеннән.
Дулкыннар сәҗдәләр кылды
сеңеп комнар эченә.
Агачлар иелеп карый
ияреп җил көченә.
Тәкатьсездән тәгәрәшеп,
ярдан балчык ишелә...

...Шәфәкъ чакта ак комлыкта
яшь бер сылу чишенә!

*Чистай*
*17 гыйнвар, 1984*

# Сау бул, тирәк!

Әй, син тирәк!

Син шаһиты —
безнең мәхәббәтнең,
безнең януларның,
безнең вәгъдәләрнең,
безнең күз яшьләрнең,
безнең ялгышларның!..
Хушлашкан чагында
бер фатихаң кирәк!
Яхшы сүзең кирәк!

Тирәк дәшмәде.
Чайкалды гына.
Иңнәрдән сөеп,
айкалды гына.

Әй, син тирәк!

Син — бердәнбер безнең
эч серләрне белгән,
безнең илаһи
минутларны күргән...
Синең тамырларга
күз яшьләре сеңгән.
Син бит шуңа күрә
безгә кадерле дә!
Син үз гомереңдә
серләренә шаһит
бик күп буыннарның
безгә кадәрле дә.

Без китәбез инде…
Әйтче безгә бер
үз сүзеңне, тирәк!
Тынычлансын йөрәк!

Тирәк дәшмәде.
Чайкалды гына.
Иңнәрдән сөеп,
айкалды гына…

…Без кузгалдык моңсу.
Артта калды тирәк.
Шул яктан җил белән
бер көй килде кинәт:
«Бу дөньяда
сөешкәннәр күп!
Кавышкан сирәк!
Кавышкан сирәк!»

Әй, тирәк!..

*Казан*
*6 февраль, 1984*

## ...Ул – Син!

Утларда янам, утларда!..
Яндыручысы, ул — Син!
Янып бетмәс өчен, Ходай
җанга сабырлык бирсен!

Рәхәттән шашам, рәхәттән!..
Шаштыручысы, ул — Син!
Очып китмәс өчен, Ходай
әзрәк авырлык бирсен!

*Казан*
*3 октябрь, 1984*

## Исеңдәме?

Р-га

Урман авызыннан чыктык та без
(каршыбызда — кичке шәһәр),
гөнаһлы адымнар белән
(урлап алган бәхет хәвефле),
онытылып, хәлсез сарышып
(гомер юлы шәфәкъка якын),
Кояш баешына ашыктык
(тәрәзәдән көтә балалар)...

...Көтмәгәндә, калку юл өстендә
керпе очрап безне туктатты
(ник дип чыккан кичке яланга?).
Тора керпе калкулыкта,
тере йомгак булып офыкта
(төнге якны җансыз димә син!).
Без торабыз
торараштай, икәү бер булып
(олыгайгач, сабый чак тарта)...
Тора керпе алсу фонда
(безне аңлый, әллә битәрли?).
Безнең соры кояш түгелме ул
(күктәгесе кереп югалган)?
Шул сурәттә микән әллә
безгә иңгән энәле язмыш
(үткән белән һаман тартыша җан)?
Бераз торгач тәгәрәде керпе
түбән таба тузанлы юлдан
(таң сызылыр тарафка таба).

...Кинәт миңа борылып карадың да
(Сиңа ул кич ничә яшь иде?),
озын керфек очларыннан
(элеккечә кайнар, үткерләр!)
тамды җиргә
ал-
    су
        чык-
            лар...

*Казан – Куктүбә*
*1979 – 1984*

# Сихә

Йоклаганда елмаясың —
күрәсең, бәхетлесең!
Нигә бәхетле булмаска? —
куйнында сөйгән кешең!

Сау тәнендә — яшәү дәрте,
күңелең — аклык кына!
Үзең теләп сайлап алган
хезмәтең — шатлык кына!

Нигә бәхетле булмаска? —
алма күк балаң янда!..
Мондый түгәрәк бәхеткә
кызыгыр аллалар да!

*Казан*
*30 гыйнвар, 1985*

# Карама!

Синең керфек — сиксән бөртек!
Һәммәсеннән гөл тама!
Күз алмаларым эри бит,
карама миңа таба!

Минем сөю — яшен тию!
Куен ачсам — кан яна!
Бәгырькәең көяр, кызый,
карама миңа таба!

*Казан*
*8 август, 1985*

* * *

Бу төшләрне генә язсаң да! —
Мәхәббәт поэмасы!

...Кайчак аңлашмыйбыз икән —
үтә ул — кайгырмачы!
Язмыш безне өнебездән —
Сөюдән аермасын!

*Казан*
*10 ноябрь, 1985*

# Ялгыша, дип уйла мине...

Керфекләрең яшь күренә,
күзләрең инде уңган...
Керфек-канат җилпенсә дә,
күңелең кошы туңган...

Үткән гомер элмәкләре —
муендагы сырларың.
Моңлырак чыга шул инде
шаян дигән җырларың...

Үзең сер бирмисең әле —
дәртле уйлар уеңда.
Әйдә уйла, ялгыш, диеп,
минем фикер турында.

*Уржум*
*21 гыйнвар, 1986*

## Яшьлегемнең көмеш бер киче

Көмеш ай! Көмеш дөнья!
Көмеш шәмнәр рәт-рәт!
Күңелгә аклык иңдерер
кабатланмас сурәт!

Бу тылсымны сөйләү кыен —
аны күрү кирәк!
Табигатьнең андый чагы
буладыр бик сирәк!

Һәрбер тараф гел көмештән:
көмеш — үлән-тирәк...
Көмеш — төнге кош авазы,
көмеш — пешкән җиләк!

Бу манзара үзе генә дә
чиктән ашкан иде!
Матурлыктан исәрләнеп,
ярым шашкан идем...

Өстәвенә Син үзең дә
гел ап-актан идең.
Мине үртәп ак дөньяга
кереп качкан идең.

Яктырткыч бөҗәкләргә мин:
«Табышыгыз!» — дидем.
Илаһи бәхет көтүдән
мин сабырсыз идем.

Бермәл үзең килеп чыктың
каен арасыннан —
урманнарда яши торган
пәри кызы сыман.

Күпме йолдыз безне күзләп,
чекерәеп янды.
Ике күзең — ике ут-йолдыз
зиһенемне алды.

Ничәү соң ай? Күктә — берәү,
күпмесе йөрәктә!
Тагын... якты ике ак ай —
синең күкрәкләр!..

Бу аклыктан күңел күзең
чагылу да булыр.
Бу вакытта бөеклек тә,
абыну да булыр...

Йолдызларың безгә ышанып,
ай оеп йоклады.
Һәр күзәнәктә кабынды
сәгадәт утлары...

Булган алар гомеремнең
алтын минутлары!

...Көмеш ай! Көмеш дөнья!
Ак каеннар рәт-рәт!
Искә төшә дә ул чаклар,
шундый татлы — рәхәт!
Яшьлекнең шул киче өчен,
Язмыш, сиңа рәхмәт!

*Чегет (Кабарда-Балкария)*
*14 февраль, 1986*

## Үземне юатам...

Зәмһәрир кыш көнне чәчкәгә кунам дип, исәр кош
бәрелде тәрәзгә, имгәтте канатын.

Мин дә шул кош кебек, кул җитмәс матурга
җан атып, күпме кат җанымны канаттым...
Шулай да үземне юатам: гүзәл хис — ярату!

*Казан*
*15 ноябрь, 1986*

# Язгы кар суларында

Икәү янәшә атлыйбыз, —
кулларың кулларымда.
Без басмалар салмадыкмы
язгы кар суларында!

Безнең таныш кошлар бардыр
торналар чылбырында.
Елмаюың челтерәп тора
язгы кар суларында.

Тал бөреләрен иркәләп,
язгы күкләрне күзлә.
Зәңгәрлектә ак болытлар
бәхет телиләр безгә.

Гомер искә төшерер әле
салкын көзләр барын да...
Йөзләребез чагылып калсын
язгы кар суларында!

*Күктүбә*
*26 апрель, 1987*

## Алтын капка! Алтын капка!..

Алтын капка! Алтын капка!
Алтын кайчы булып,
алтын кайчы булып
кистең бәгъремне!

Алтын ярым! Алтын ярым!
Үтте бергә азы,
азы үтте бергә
яшьлек гомеремнең!

Алтын капка! Алтын капка!
Күпләр килгән сиңа,
бездәй күпләр килгән
сөю кичүенә.

Алтын ярым! Алтын ярым!
Бәхет — бергә чакны,
бер җан булган чакны
искә төшерүе дә!

...Еллап түләнгән шул
барсы өчен дә
гомер исәбеннән!
Гомер исәбеннән...

*Куктубә*
*1 май, 1987*

* * *

«Бу минем хактамы?» дип сораган
бер ханым турында түгел бу юллар.

Сине күрә алмаган һәр көн —
май аенда
яфрак яра алмаган шәрә агач.

...Һәм мин —
бер томаны шул көннәрнең —
шыр ялангач!

*Казан*
*март, 1988*

## Очраштык кеше туенда...

Гомер эзе — маңгаеңда...
Еллар эзе — муеныңда...

Сискәнеп киттең шикелле —
ишеткәч кеше туенда
икебез белгән бер җырны:
«...Синең белән даным чыкты,
җаным чыксын куеныңда!»

Борылып миңа карадың, —
мин идем үз уемда.
...Уеным да, чыным да,
«әкиятем дә, җырым да!»

*Казан*
*июнь, 1988*

## Көньяктагы рәсемең

Утырасың диңгез буенда
тезләреңне кочаклап.
Дулкыннар көенә, яраткан
шигъри юллар кабатлап.
Чәчләреңне кояш ягына
иркәләп җил тараткан...

...Бәлки, шушы күренеш өчен
Тәңре Сине яраткан?

*Куктубә*
*апрель, 1989*

* * *

Дүрт кылым бар иде Сазымда,
Берсе сүзем иде — аңламадылар.
Берсе көем иде — тыңламадылар.
Берсе күзем иде — карамадылар...
Тик бер кылым калды хәзер —
ул — Син!

Туры карый алырсыңмы?
Тыңлый-тыңлый арырсыңмы?
Җанны аңлап карыйсыңмы?

Хак Тәгалә белә микән?..

*Казан*
*24 октябрь, 1990*

## Борчылма!

Караңгы төннәрдә,
шомлы җил шавыннан
сискәнеп уянсаң,
кадерле кешең бар —
сыену табырлык,
юата алырлык
кадерле кешең бар —
борчылма!

Кайгылар ишәйгән
борчулы көннәрдә,
күңел тулышып
сыгылып төшкәндә,
тураеп торырга
таяныр кешең бар —
борчылма!

Акылың җуярлык
шатлыклар килгәндә,
Җир хисен югалтып,
Күккә ашам дигәндә,
кочагыннан чыгармас
ышаныр кешең бар —
борчылма!

*Казан*
*1990*

# «КӨЗГЕ КУКРӘУ» ДӘФТӘРЕННӘН

*Көзге соңгы чәчәкләргә*
*саксыз кагылма икән!*
*Үзең теләп бер хушлашкач,*
*кабат сагынма икән!..*

# Сорау

Уянгач та бер хушаваз:
гөл... гөл... гөл... гөл... —
күңелемә сарыла гел!

Син кем миңа? Чын исемең ничек?
Син дип! —
үлеп терелимме яңадан?
(Миңа бик кирәкме яңа дан?)

Мин җавап көткән арада,
исте назлы саба җиле
бөтен тәнемне,
бөтен җанымны,
бөтен гомеремне аралап.
Бөтен үткәнемне яралап...

*Казан*
*3 декабрь, 1991*

* * *

…гә

Бер-беребезгә артык якынлашмыйк!
(Ерагая башларбыз дип куркам!)
Хыял күкләренә менеп шашмыйк!
Син дә тукта!
Мин дә…
Тамчы күз яшь куйсын нокта.

Калыйк без Яшәү Картасында
сагынышлар көтәр якынлыкта,
гомер буе теләр ераклыкта!..

*Казан*
*9 декабрь, 1991*

* * *

Элеп киптер мине кер итеп.
Яфрак булып калыйм имиеңдә.
Тәмле төшең булып уятыйм.
Өмет булып куныйм иңеңә!

Мин барсына риза.
Кеше булып калсам,
япь-яшь җаның аша,
янә күрсәм
хыялый таң —
Яшьлек чагымны.

Ә Син әзерме соң,
яшел тирәк килеш
зәмһәрир кыш урталарында
яланаяк басып торырга?

*Казан*
*28 декабрь, 1991*

* * *

Язмышымда упкынмы син?
Әллә төп терәк?
Ирексездән тамыр җәйдең
җанда Гөлтирәк!

Болай да ярсулы йөрәк —
булды куш йөрәк.
Сине кисеп ташлыйм дисәң —
кушкылыч кирәк!

Теләсәм, андый кылычны,
бәлки, табармын...
Тик аны үз күкрәгемә
ничек кадармын?

*Конья (Төркия)*
*июль, 1992*

# Сау чакта, яки «шул» хакта

Җелеге суырылган Дәү Сөяк. Исеме дә бар: Р-л.
Бөтен күзәнәкләргә сүнгән йолдызлар тулган.
Күзләрдә генә икесе пыскып азаплана.
Йөрәк тибә бугай. Балык саңагыдай —
бер кабарып алакүкрәк, бер иңә.
Аяклар камыр. Куллар эленеп тора (чөйдәге чыбыркы
сабыдай).
Бишмәт эләктерелгән бер төймәгә генә. Теләк тә,
хәл дә юк...

...Өйалды ишеге төбендә саубуллаштык инде,
бер ун тапкыр сарылып, кысышып бихисап...
Келәне күтәреп ачасы гына бар.
Ә ул һаман,
торса да читтәрәк, кулларын кушырып,
магнит сыман, җибәрмәскә тартып тора!

...Ниһаять, мин тышта!
Таң беленеп килә.
Морҗа төтеннәре шәйләнә.
«Шамук мәчесе»дәй кайтып киләм.
Коры салкынлыктан кар шыгырдый.
Шыгыр...
шыгыр...
шыгыр...
Калтыранып, өшеп атлыйм;
өстәвенә җил дә үрти күк:
«Берәр шигырь тумадымы, иптәш Шагыйрь?»

Ә кар һаман
шыгыр...
шыгыр...
шыгыр...

Ә шулай да
Яшәү шәп бит,
анасын саткыры!

*Казан*
*8 декабрь, 1992*

* * *

Озак эзләдемме мин Сине?
Әллә тиз таптым?..
Егермеләп еллар үткәч —
Инде очраттым...

Синең, яшьнәп, Дөньяга
килешең иде.
Минем, арып, Язмыш белән
килешү иде...

Син парлы була торып та,
канатсыз идең.
Мин җайдак була торып та,
...атсыз идем...

Дәрт очкыны чәчрәгәч
Синең йөрәктән,
яшьлек таңы янә туды
минем күкрәктә!

Җандашлыктан, игезәкләрдәй,
охшаш ук булдык.
Бар вөҗүд бергә кушылгач,
тоташ ут булдык.

Ходай үзе өсти мәллә
хисне, теләкне?
Икебез бер, тәнебез
бер — куш йөрәкле!

Аякларың — «алтын кайчы!»
Кисә дә тора!..
Бәгъреңдәге татлы «шартлау»
ыңгыраштыра!..

Озак эзләдемме мин Сине?
Әллә тиз таптым?
Шунысын беләм: мин кич таптым.
Кичегеп таптым...

«Аралар юк, без — тиңнәр!» — дип,
рәхмәт, юаттың.
Мин дә, ахры, бәгъреңдә
нидер уяттым.

«Сөю — сәгадәт» дигәне
шушыдыр инде.
Син — Мәхәббәтемнең соңы —
«хушы»дыр инде.

Әйттең ничә, күземә карап,
айлы төннәрдә:
«Әйе, абыем! Бу хәлемдә
калам кемнәргә?..»
Үз соравым — башым ята
синең иңнәрдә.

Нидер әйтмәкчемен, булмый
аңлатып кына!
...Күрәсең, җавапны әйтер
тик Вакыт кына.

*Казан*
*1992*

* * *

Соравыма бик еш, тапкыр итеп,
шигырем белән җавап әйтәсең.

Мөлдерәп карап, «әй, абыем!» дип,
әллә нишләтәсең!

Бер гаепсез килеш оялам мин
ул җыр-шигырьләрнең
Синең өчен булмаганы өчен.
Соңлабрак тумаганым өчен…

*Казан*
*14 февраль, 1993*

# Ул камышлар...

Камышлыкта танышмадык,
Без — шигырьдә кавыштык.

Ул камышлар серлелеген
аңлар өчен яшь шул Син!
Гомерләрнең аермасын
тамырлары яшерсен.

Ул камышлар әйләндеме?
Безнең башмы әйләнде?
Күзеңдәге очкыныңнан
күңелемә нур иңде.

Ул камышлар колагыңа
миннән нинди сер әйтте?
Тәнеңнең калтыраулары
акылымны исәрәйтте...

Ул камышлар өскә ава —
билне ныграк кыссана!
Тәннәр ялкын. Тирә-юньдә
тоташ яшел ут яна...
.........................................
Ул камышлар сызлангандыр
сынганда, сыгылганда...
Кыяклар кисә бәгырьне
ө-з-е-л-е-п с-а-г-ы-н-г-а-н-д-а!!!

*Казан*
*27 август, 1993*

* * *

Тапканга артык сөенмим.
Соңрак күбрәк югалтам...
Ни бәрабәргә икән, дим,
Сине бүләк итте таң?

Якты чакта көне буе
Сине уйлап егет мин.
Төнен «тота», сискәндереп,
Картлык дигән рэкетмен.

*Казан*
*13 сентябрь, 1993*

* * *

Качар җир — убежищелар
нәрсәгә ди миңа?
Иң хәвефсез урын — ул бит
Синең куенында!

Күкрәгеңә терәлеп бер
йоклап киткәнмен дә,
төш күрдем: имеш, бер тиен
зур бер куш имәндә
нигъмәт җыяр куыш тапкан,
өй булыр дип кышкы.

...Ә төптән кисеп яталар:
чыж-чыж кипә пычкы!

*Казан*
*14–17 сентябрь, 1993*

* * *

Галәмдәш —
замандаш —
илдәш —
милләттәш —
кардәш —
кандаш —
җандаш…

Нәрсә әйтим?
Рәхмәт! диям Сиңа —
Төнге яңгыр шавын тыңлап, изерәп
упкындагы чыра яктысына
дүрт күз белән
карый алгач!

*Казан*
*1989–1993*

# Көзге күкрәү

«Мин Синең тормышыңа соңга калыбрак, гомереңнең көзенә табарак килеп кердем...»

*Хатыңнан юллар*

Әйтәләрме: «Сине яраттым!» — дип?
Сөйлиләрме: «Сине сөйде!» — дип?
Син горурлан! Сөйсәм-сөймәсәм дә,
тормышыма инде кердең бит!

Тавышыңнан — балачакта калган
бер кадерле өнне шәйләдем.
Күз карашың Кояш булып торгач,
мин Йолдызга, ахры, әйләндем.

*Казан*
*1992—1993*

# Җуймагыз мәхәббәтне!

*(Җыр)*

Алуын алдым
гөлләрнең алын,
туйганчы карармын, дип.
Көтмәгән идем
сөю утында
тагын бер янармын, дип.
Җирдә ямьнәр арттымы,
җанда гамьнәр арттымы
минем бу
соңарып
шашудан?
Ә синең күңел каткан,
яшь килеш төрле яктан
очраклы
җилләргә
ачылган…

Үкенү дә юк,
үтенү дә юк,
җанда бушлык та аклык.
Күңелләр бизгәч,
ахырны сизгәч,
аерылышу да шатлык!..
Җирдә ямьнәр арттымы,
җанда гамьнәр арттымы
минем бу
соңарып
шашудан?

Күкләр күкрәде аңлап,
гөлләр тетрәнде аңлап
        әрнүле
                күңелем
                        ярсудан.
Гомерләр үтә,
уйлап кич-иртә
кайтам яшьлек таңына.
Ялгышларым да,
сагышларым да
кабат килә аңыма!
        Тере күбәләк кенә,
        тәүге мәхәббәт кенә
                күңелдә,
                        җилпенә,
                                кагына.
Бул икән нык һәм көчле
Таһир-Зөһрәләр төсле
        беренче
                мәхәббәт
                        сагында.

*Казан*
*май, 1994*

# Яшьлек дәфтәрендә бер рәсем

…Ак кәгазьнең уртасында
офыктан калыккан болытлар.

Ул чакта ук — ясагач та —
бу болытлар сурәтендә
берәр чалым шәйләдем микән?

Еллар үткәч,
ничектер бер күз төшкән иде
әлеге шул таныш кәгазьгә.
Бакчы, бакчы! — болытларда
Синең профиль икән бит!

Менә бүген, чал чигәмне тотып,
янә актардым шул дәфтәрне.
Әлеге рәсем —
коеп куйган Синең силуэт!

…Дулкынланып
күрсәткән идем
Сине белгән танышыма:
«Эскерткә охшаш
әллә нинди шәүләләр…» — ди.

*Казан*
*1990 – 1994*

* * *

Сезнең урам аша үттем бүген.
Тәрәзәңдә калды күзләрем...
Керфекләрем йомып нидер әйттем,
хәзер хәтерләмим сүзләрен.

Шактый ара бардым белешмичә,
хатирәләр алды бөтереп.
Ул елларның асыл бөеклеген
мөмкин түгел аңлап бетерү.

Булган Яшьлек, булган чын Ярату
һәм Яңару булган һәрдаим.
Нәселемнең ни догасы өчен
бүләк иткән Сине Ходаем!

Кеше гомеренең буладыр ул
Бәхет тажы иңгән бер чагы!
Әйтүчеләр булды: «Боларның бу —
сүнү белмәс Сөю учагы!»

...Хатирәләр, татлы хатирәләр
керфекләргә дымны тарата.
Казан нинди мәрхәмәтле булган
бу йорт аша безгә карата!

...Калтыранып куйдым. Әйтерсең лә
кышка кердем җәйге киемнән.
Кире килгән чакта караңгы иде,
мин таксида кайттым өемә.

...Төн уртасы. Йоклый алмыйм,
мең-мең сорау биреп үземә.
Сиңа хәзер, бәлки, Ай карыйдыр
тәрәзәңдә калган күземнән...

*Казан*
*1990 – 1994*

## Триумф яки күренеш

Ятактагы бу ак җәймә,
без төйнәлеп әүмәкләшкәч,
нишләгән соң?

Пешекләгән карта сыман җыерылган.
Янып тамган тир-тамчылар парланып тора.
Тез башлары төйгән урын —
бомба төшеп убылган күк чокырайган...
Җиңүемә әзерләгән ак әләмең — шушы җәймәң.
Мунчаладай җәйрәп ята. Бөек сурәт!

...Ай янында нәни ак болыт
тәрәзәдән күреп манзараны,
соклануын (көнләшүен?) җилдән әйттерде:
«Җирдә тормыш-хәят бар шул ул!»

*Казан*
*июль—декабрь, 1994*

* * *

Париж түгел, Пар-Иш!
Безнең атамабыз!
Иш-Пар булып яратканнар
безне Ата-Анабыз.
...Шуңа да Ир белән Хатын
диеп аталабыз!

*Казан*
*15 гыйнвар, 1995*

## Син әлегә яшьрәк бит!..

Көзге кара төндә тамды күз яшем.
Нидән тамды?
(Ак кәгазьдә йолдыз чагылды)
Искә алдыммы —
Вакыт — бәләк-чукмар булып
тетеп, сытып киткән Гомерне?

Язгы алсу таңда тамды күз яшең.
Нидән?

*Гиссен (Германия)*
*10 апрель, 1995*

## Сискәну

— Икебезгә бер очтан кистереп алдым.
— Бергә күммәсләр шул.

*Фараз-диалог*

«Мәңгегә бергәбез!..» диеп,
кәфенлек бүләк иттең.
«Мәрмәр!» дип йөргән йөрәкне
бу гамәлең көл итте.
Вөҗүдне өнсез итте.

Ир булыйм дип, җавап итеп,
Сиңа гөл бүләк иттем.
...Соң эшем: ләхет катында
яңа чәчәкләр көтү.

*Казан*
*28 апрель, 1995*

* * *

Күзләре — диңгез!
Чәчләре — кылган!
Курай эчендә —
нечкә елан!

...Түз, Шагыйрь!
Елмай!

*Казан*
*7 август, 1995*

# «Җәй-96»дан бер сурәт

*«Аккош күле» циклыннан*

Урман эчендәге сихри күлдә
йөзә елан.
Йөзә сылу кыз.

Карап торам яр өстеннән.

Сыгылмалы боргаланып «шуышалар»...
Әкияти грация!

Күрде дә кызый тузбашны (аера!),
янәшәләп йөзде бераз,
аннан... аны куып, өркетеп,
кысырыклап алып чыкты комлы ярга.
Табып алды шундук тал чыбык.

Әй уйната
чыбык белән әле билен,
әле сары башын күтәрә,
әле чөеп ата...

Елан да шул: «Мин барыбер сыгылмалырак!
Уралуым, сарылуым күпкә өстен!» — дигән сыман
һич бирешми... әле бөгәрләнә бөҗра булып,
дугаланып сыртын күтәрә,
сары таҗлы башын чөеп, ыслап ала...

Әкиятләр искә төшә.
«Кайсы елан? Кайсы аждаһа?

Кайсы юха? Кайсы Сылу Кыз?..»

Бөек фантазия! Чын уен!

Читтән генә карап торам.
Тамашага керә алмаган
бер ят кеше — мокыт бер ир-ат.

*Балык Бистәсе*
*24 август, 1996*

* * *

«Шәүләңне булса да күрием!» дип,
табыныплар йөргән бер бәндә,
әйтте салды «вон моннан!» дип,
бусагасын атлап кергәндә.
Кискән мәчет манарасыдай,
ишелепләр төштем шул мәлдә!
Гарьлегемнән көйдем, шушы йортның
нигезләрен салышып йөргәнгә...

Аптырагач, «ярый!.. яхшы...» дидем.
Аңлый алмау, бәлки, шәп тә дер...
Күзләреңне... бер төзәткән идем,
Күңелеңә — көчем җитмәстер...

*Казан*
*15 гыйнвар, 1997*

## Көньякның бер гүзәленә

«Хәзер — матур. Тиздән гүзәл булыр!
Ярда — чәчәк, тауда — кар исе!
Яз гөлләрен икәү бергә-бергә
җыяр идек!.. Бездә кал!» дисең.

Бездә Кырымнан да яхшырак! дип,
әйтә алмыйм сиңа, Гөлчәчәк...
Беләм: беркөн сәлви күләгәсе
ак юл булып төшкә керәчәк.

Күк Түбәләр Иле ят итмәде,
үз улыдай горур көн кичтем.
Маңгаемнан сөеп дулкын юды,
күз яше чыкса, сөртеп җил исте.

«Ни җан белән китеп барасың син,
мин һәм миндаль чәчәк атканда?..»
...Сиңа түгел,
Аны сагыныр өчен
килдем бит мин Диңгез ярына.

*Күктүбә — Казан*
*1977 – 1997*

## Нур

Кеше кулыннан, соранып,
алмадым бер чеметем.
Сызылып аткан таң нурында –
киләчәккә өметем.

Йөрткәч шул нурны үзеңдә,
күңлең кояшлы була.
Нәфрәтем йоклый песидәй,
җанга тынычлык тула.

Таң иңдергән нур-яктыдан
алам илһам, иманны.
Төнен Ярым куенына
алып керәм мин аны.

*Казан*
*27–28 октябрь, 1997*

* * *

Әллә бар да, әллә юк та Син.
Вакыт түмгәгендә аяк бөкләп,
матур гына оеп йокла Син!

Хәер…
җан иңдергән Тәңре белә
кемнең,
        кайчан,
                ничек,
                        кайда
                                туктасын.

Минем өчен хәзер
әллә бар да, әллә юк та Син.

*Казан*
*12 ноябрь, 1997*

* * *

Г.И.-гә

Урал шаһинәсе булып Син үткәндә,
ярты Казан калды иелеп!..
Син турайткач, «князь-шагыйрь!» булып,
мин дә йөрдем: «Күрегез!» — диеп.

Бар күзәнәк шау иҗатта иде —
көч һәм назның тулышкан чагы!
Һәр тарафтан кемнәр караса да,
күренә иде Сөю учагы!

Төшләремдә итәгеңә тектем
дөньядагы байтак гөлләрне...
Әйттеләр дә бугай: бу егетнең
Күк Капусы ачкан көннәре!

Алтын кылчык булып кадалганмын
бәгыренә, бәлки, кемнәрнең?
...Бер үкенеч: ул чак бу бәхетнең
кабат кайтмаслыгын белмәдем.

Башкорт иле — Баймакларга баргач,
гөл исемең искә төште гел.
Көзге яфрактан Сиңа атлыйм.
Монсы чынлык. Монсы төш түгел...

*Казан*
*18 февраль, 1998*

* * *

Күпме булды гомеремдә
ул күчмә утраулар!
Һәркайсы җан экранында
материктай торалар…

Робинзон ук булмасам да,
уй-гамәл зурдан иде!
Һәрберсендә ыру-нәсел дип,
йорт-кура корган идем.

Казан асулы учакта
төтен дә тәмле иде!
Наз тулы ятак янында
чәчәк бәйләме иде!

Куларбалар әмәлләдем
балалар тибрәтергә.
Китап сүзләре чыгардым
гыйлемгә өйрәтергә.

…Җилдән микән, илдән микән,
миннәнме — нидән икән? —
Тора-тора утрауларым
ярдан аерылып китә…

Пристаньдагы матрос кебек,
ыргак-баулар беркетәм.
Кушмакчы булып: «Китсен!» — дип,
күкрәгем белән этәм!

Аерылып китә утрау!
Шәп күренеш! Трагикомик
илаһи бер тамаша.
Офыклар — төсле музыка,
көлү катыш яшь аша.

Бар ул андый утраулар
Аккошта, Кабанда да...
Әйтмибез генә, бар алар
Һәрберебезнең җанда.

*Комкой (Төркия)*
*22 июль, 1998*

## Шәлең түгәрәк түгел...

Шәлең түгәрәк бүген!
Күңел күбәләк бүген!
Илһам килгән көн бүген!
Бергә булган көн бүген!
Дөнья аяз бүген!
Һәр күзәнәк наз бүген!

Син сәждәдә, мин сәждәдә!
Әй Ходай, биргәннәрең!
Дога итеп пышылдыйсың:
«Мәхәббәт пәйгамбәрем!»

Юктыр! Юктыр... Ул — Син! Ул — Син! —
Алиһәнең нәкъ үзе!
Гап-гади җир баласы мин,
бүген Синең — Нәүмизең!

Күңел күбәләк бүген!
Дөнья түгәрәк бүген!
Бәхет-тәхет биек булгач,
Күк тә тәбәнәк бүген!

...Нигә кинәт тынып калдың?
Уең — күктән югары!
Боланныкыдай күзләрдә
каян дым болытлары?
Нәрсәне исеңә төшереп,
кемнедер онытмавың?

...Төшме? Өнме? Бу челләдә
каян килә кар исе?
Кайдадыр сабый тавышы,
килә барып карыйсы...

*Комкой (Төркия)*
*24 июль, 1998*

## Кичеп чыкмады...

Төнге бураннарда, чаңгы тагып,
бозлар аша тартып карадым.
Урау юллар аша,
төрле-төрле машинада кичтермәкче булдым.
Сөйрәдем буксирдай,
йөзә-йөзә колач салып...

Һич булмагач,
турылатып күпер салдырдым.
Кызыктырмак булып,
каршы якта сарайлар кордым...

Иске нигезеннән яңа йортка
күченмәгән Ия шикелле,
калды Сөю Иске Шәһәрдә –
Казансуны кичеп чыкмады!..

...Әллә Үзе көчсез булды?
Әллә без юньсез булдык...

*Казан*
*25 апрель, 1999*

## Быел җәй... яки моңсу кабатлану

Быел җәй, быел җәй —
эссе җәй,
хәлсез җәй,
мәнсез җәй...

Бәгырьләр көйгән җәй.
Тәкъдирем хәсрәтне
эскертләп өйгән җәй.

Бакчамда әрнешеп,
җиләкләр көйгән җәй.
Кочагым түреннән
Бәхетем киткән җәй.

Күңелең бозына
иреннәр тигән җәй.
Гоп-горур маңгаем
идәнгә тигән җәй.

Сау-имин картлыкка
өметләр иткән җәй.
Үзем дә белмичә
үземчә
көткән җәй,
көткән җәй...

*Казан*
*7 август, 1999*

* * *

Авырыйсыңмы — димәк, гөнаһың бар.
Җәза итеп Тәңре җибәргән.
«Череп кат!» диюче үзе корыша,
үз каргышын алып бер бәндә.

Өч чукынып, бер бисмилла әйтеп,
ике зина кылып, бер намаз.
Ике Дөньялыкның бер чите дә
андый җанга җәннәт булалмас.

*Казан*
*18 август, 1999*

* * *

*«Аккош куле» циклыннан*

Тәрәзәдә Синеңме сулышың?
Күбәләк икән...

Тәрәзәдә Синекеме кулың?
Яфрак икән...

Саңгырау итәр яшен орды!
Бу — тәгаен Син!

Имән төбендәге көлдә
шыткан бер гөл.
Монсы... ахры, мин.

*Казан*
*3 октябрь, 1999*

* * *

Н-гә

Затлы.
Татлы.
Атлы.
Хаклы.

Усаллыгы?
Минеке чаклы.
Тырышлыгы-үҗәтлеге
кырык сигез катлы!

...Өреп терелтә ала
арыган учакны.

Эңгер-меңгер язмышыма
Ходай биргән Якты!
Югалтсаң, тагын йөрерсең —
«улмы, минме хаклы?»

Орлыктан кибәкне аермый
күпме гомер акты...

*Аккош куле*
*30 апрель, 2000*

# Эх!

*Фольклорга ияреп*

И иш булды, иш булды...
Иш булмады, биш булды!
Комнан аркан ишә дигәч,
кызыккан гына эш булды...

*(Дәүәнием җырыннан)*

Кама суы зур дәрья,
диңгез чамалары бар.
Төннәр буе йокламыйсың,
йөрәк яраларың бар?
Әй, егетем, баш сау булсын! —
ярның яңалары бар!

Кем тапкан, кем югалткан:
кем качкан да, кем капкан!..
Эх, милай!
Сайлаганым булып чыкты
урам авыз, җил капка...
Урам авыз, җил капка!

Безнең тауларның башында
бөркет түгел, әрләндер.
Тишек эшләпә кигәнмен,
шуңа башым әйләнде...
Көтүче чыбыркысына
абынганга гарьләндем!

Кем тапкан, кем югалткан!
Кем качкан да, кем капкан!..
Эх, милай!
Сайлаганым булып чыкты
урам авыз, җил капка…
Урам авыз, җил капка!

*Аккош куле*
*июль, 2000*

* * *

Беренче саф хисне
булмас та яңартып,
шулай да мендәрне
иплә әле кабартып!

Әйдә, кемдер йөрсен
гайбәтләр таратып…
Саулыкта сөелү —
байлыктан мең артык!

Тырышсаң буладыр
караны агартып.
Кояшны, Сөюне
булмый ул каралтып!

*Казан*
*20 февраль, 2001*

# Кирәкмидә, Ходаем!..

Иҗатым бар, балаларым үсә!..
Бәйрәм түгелмени бу тормыш!
Бәхет түгелмени бу яшәү!

Җуймадым әле —
Аш тәмен,
Эш тәмен,
Тән тәмен!

Яшим тоеп
Дөньяның
күп гамен,
күп ямен...

Өстәвенә яна
Каләмем!

Кирәкми
Язмышның
бүтәне!

*Казан*
*8 февраль, 2002*

# Чибәрләр ярышында

Мисс!
Алиһә!
Браво!
Афәрин!..

Яралганнармыни чәчәктән!
Нинди грация! Нинди тән!
Оешып беткәннәр бит ундүрттә!
Пешеп җиткәннәр бит унбиштә!..

(Селәгәйләреңне эчкә йот!
Бөкрелегеңне туры тот!..
Алтын кашыгың юк йотарлык!
Дәрманың юк дәртең тотарлык...)

Яшьлек! Яшьлек!
Гомер язы — бәрхет яшеллек!

Шоуга гына түгел, сугышка да
бик тә хаҗәт икән яшь җаннар
(Ядрә бигрәк сизгер яшь канга!)...
Табутларга тамган яшь кайнар...

...Кем сискәнеп тора «Подъем!»га.
Кем таҗ кия Тәхет-подиумда.

*Казан*
*2002*

* * *

Ирлек чыкты бәреп тирләрдә!
Гөлләр шытты баскан җирләрдә!
        Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?!

Җиһан кичкән сабыр Ирне дә
Тал чыбыгы кебек идердең...
        Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?

Хатирәләр — ялкын, без — күмер...
Яшәр өчен аз шул бер гомер!..
        Син, Мәхәббәт, мине нишләттең..?

*Казан*
*2002*

# «КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР» ДӘФТӘРЕННӘН

ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

*(1961 – 2003)*

Гомер буе җандаш эзләдем мин.
Язмы язып чапканым булды!
Җандашлар дип, күпме кондашларга
нурым түгеп бакканым булды!
Хәер... кайчак җандашларымны да
төшләремдә тапканым булды...

## Бәлки...

«Хәзер — сулган. Элек күрсәң,
имәнеп торыр идең!»
Мин ул чакта аны, бәлки,
Сөймәгән булыр идем!

# Бергә чакта

Очрашкач — сүз онтыла.
Аерылышкач — килә сүз.
Бергә чакта тын тору да,
сүздән артык күрәсең.

* * *

Янган еллар, янган еллар,
утларда янган еллар...

Корыч канатмыни бу мускуллар!
Офыклар чигенә бүгенгә!
...Ә сагынам — авыру, хәлсез килеш
очкан чакны синең күгеңдә.

## Ә ник тамды...

Әйттең: «Рәхмәт! Нинди хозур!
Нинди бәхет бу яшәү!»
...Ә ник тамды балдагыңа
ике бөртек күз яше?

## Яме!

Нык тораммы, чайкаламмы,
Күккә ашаммы, аваммы… —
Хурлыгымның ахыры бул,
зурлыгымның дәвамы!

* * *

Күммәсәм дә,
Бәхетемне куйдым киртәләп...

Яшәргә соң...
Ә үләргә әле иртәрәк.

* * *

Икәү бер сулышны бүлербез дип,
кавышкан иделәр бер таңда!

...Судта сулышлары кабып (бер булып!..),
бер бүлмәле фатир бүләләр...

## Борчылма!

Син — тормыштан сугышып алган
илаһи минутларым!
Кайгырма — начар уйламам,
борчылма — онытмамын!

## *Киткәч беләсең...*

Болытның куәтен күрәсең
явып үткәч.
Бәхетнең кадерен беләсең
ул... киткәч.

## Белсәм дә...

Син биргән бөек мизгелләр!
Кабатлыйм исемеңне —
Мизгел өчен гомрем белән
белсәм дә түлисемне...

## Бер сыныйм...

Йә, бер бизән, ясан, ки затлысын!
Күрсеннәр синең гүзәллекне!
Сыныйм: шул матурлыкны йөртергә
син ныкмы, түзәрлекме?

## Рәхмәт!

«Иң матур кыз! Иң сөйкемле!»
Нинди матур ялган!
Ул ялганга рәхмәт. Мине
бәхетле итә алган.

## Кыенрак...

Кыен бәхет кошын тоту,
оя кору.
Кыенрак — тоткач, коргач,
саклап тору.

## Сиңа

Син Алмазга кара, күзләренә,
мине сагынганда.
Күңлең керсез булса, күралырсың, —
чагылырмын анда.

## Йокы алмаган төннәрдә

Ак Кремль диварына
ант итеп язган сүзләргә —
без уйган исемнәргә
яңгыр гел бәреп ява күк...

## Төнге Иделдә син йөзгәндә

Кара суда
яңа ак дулкын!
Көнләштереп мине
маяклармы ешрак җемелди?

## Күк

Күк — зәңгәр сандыгым минем.
Бик күп серләрем — шунда!

Ачам кайчак. Ачкычы аның —
сөйгәнем куенында!..

* * *

Анда туташларда ымлар,
Күз кысулар бар иде!..

*Дәрдемәнд*

Әйтә иде «гусар!» диеп кызлар-дуслар!
Уч төбемдә сайрый иде асыл кошлар!
Таңнар ата иде Алар кочагында!
Назлый иде Гөлләр шәфәкъ-кич чагында!..

* * *

Җелеккә үтте уйнакчан ярлар!
Шуңа якын булдылармы?..

Кемнәр бәгърен көйдерер икән
уйнап язган бу җырларым?

* * *

Өстән торып карыйм: син бит әле бөре!
Ә мин инде күптән яфрак!

...Беркөн аста көтеп каршылармын:
икебезгә дә мендәр — туфрак.

## Күзләрең

«Эзләдем. Таптым. Югалттым.
Бүтән табылачак түгел...»

Карадым да күзләреңә —
яшьләрем тыялмадым...

Күп хәсрәтләр сыйды аларга,
бер бәхет сыялмады!

* * *

Җан тынлыгын бозып дау булдым.
Үзәннәрдә торып тау булдым.

...Килде көн: Син яннан үткәндә —
иелеп калыр өчен тал булдым!

## Кемгә икән сиңа картлык үрмәкүч сурәтендә...

Э. ханымга

Күз төпләреңә сарган да
нечкә үргән җәтмәләрен,
ята үзе җәйрәп кул арканда
тамырларың буйлап таралып...

* * *

Син юк чакта уянасы килми!
Һич керәсе килми чынлыкка...

Син бар чакта, вакыт йокыга әрәм.
Гүзәл төш тә чыга гел юкка!

## Вакыт үткәч, иясе киткәч...

Әй, килә соң тапкыр сүзләр бәхәс тынгач!..
Кайчак ачыграк күренә дөнья — күзне йомгач...
Күпме сөю уты каба яшьлек үткәч!..
Күпме даннар йөри артта иясе киткәч!..

## Ачыну

Шыр яланда ничек күшекмисең —
өстән явып торгач кар-яңгыр.

...Эчләренә шәмнәр куйыймммыни —
күңелләре булгач караңгы!

## Синә!

Артыңда — салават күпере.
Гомерең — көянтә...
Егыла калсаң —
кем күтәрә? Ә?

* * *

Мин Ирекне тойдым, татыдым тәмен.
Татыган саен... сусадым гына!

Баер дип күңелем, коендым Сөюдә —
бушандым гына...

## Шаяру

Гашыйк Гарип... Гашыйк Гөмәр...
Гашыйклары белән данлы ил!
Шул гашыйклар арасына
сыймас дисез мәллә бер Равил!..

## Уяну

Сихри төндә йөрдек икәү ак атларда!
Ал офыкта җуйдым сине таң атканда!..

...Ярым айнып төштән, чыксам өйалдына —
тышта суык яңгыр ява талгын гына.

## Апрель

Егет шундый кочты каенны!
Кәүсәсеннән мөлдерәп яшьме чыкты?..
...Судан кайтучы кызга ул
бер гүзәл сүз әйтәчәк!

## Ачуланц, имеш...

Беткәнмени сиңа
алтын комлы диңгез ярлары,
паркларда якты сукмаклар... —
керфек очларымда йөрмәсәң!..

## Үчак яки охшату

Утынны мул салган саен —
төтен ялкынны буа!

...Гаҗәпләнмәдем моңа —
Мәхәббәтем иш шуңа.

## Кайда да...

Эльбруска, Витошага, Чатырдагка
менеп кычкырдым.
Кайтаваз булып һәрчакта
Синең аваз ишетелде.

## Гашыйклар

Бәхеттә янган икәү!

Утыралар яшел чирәмдә,
бөтен дөньяга нур чәчеп,
Кояш күләгәсе астында.

## Егылып айнылач кигән уй

Тайгалады минем йөрәк тә
шома күзләрдә.
...Күпме акыллы баш ярыла
матур тезләрдә!..

* * *

Белми генә күпләр:
без бит — Сак-Сок!..

Әкияттә түгел, чында булгач,
Тик исемнәр генә бүтәнчә.

## Төнге самолеттан Казан өстендә

Утлар гирляндасы бер дәрья!
Иллюминаторга ябышып,
чын-чынлыклап эзлим
Синең тәрәздәге шәм яктысын…

## Китәр алдыннан

Кочагыңда килеш
инде сагына да башладым!
Алда — юллар,
биткә бәрер бозлы яңгырлар...

* * *

Аполлинердан

Борча-көя, дуслар, сөяркәләр
мәрхәмәтсез: безне — сөяләр.
Сөяләрме, димәк, тешли алар,
башың ашый... Сак бул, ир адәм!

# Елмаюың...

М-гә

Гомер буе серле елмайдың син…
Булдым, димим, моңа гел риза.

Кемдер, бәлки, аңлый алыр булган
минем Мона Лизам!

* * *

Мин сагынып килдем.
Ул киенеп чыгып китте.

...Өзгәләнеп ул кайтканда,
мин еракта идем инде.

## *Искә төште үткән язда әйткән сүзең...*

Тик бер кылда сызылып үткән кебек,
үтәр уйнап, үтәр бу яз да!

Әгәр җаның бәхет тойган булса —
шатлык моңы калдырыр беразга...

## Сагыныр дип уйласаң да...

Җан ярсуын басмас сыман
Иделдәге сулар да!
...Сагыныр дип уйласаң да,
ялыныр дип уйлама.

## Шөһрәтсез юл

Көликме без, елыйкмы, —
Ни дип әйтик бу эшкә?
Шөһрәтсез юл үттек икәү:
Сөюдән — үкенечкә.

## Бер чәчәктә ике балкыш

Кавышусыз мәхәббәттән
берәү җыр калдырмакчы.
Берәү — Кояшка үч итеп,
дөньяны яндырмакчы.

## *Кайчак килә...*

Кайчак җир сөрүче буласы килә.
Кайчак галәм белән юанасы —
йолдызчы галим булып. Кайчак килә —
гомерлек ярың булып уянасы...

## Ирдәүкә

Каты, кырыс бу, дим, кайчак Сине,
хисләрендә эри белми!
...Йомшак булсаң, Син ялгыздан дөнья
нәрсә ясар иде, белмим...

## Төш кенә...

Зур кануннар, сөйгән ярлар, уенчыклар,
режиссерлар бар да искерә...
Торган саен матурая бара
балачакта күргән төш кенә.

## Сина

Гомрем буе Сине сөйдем.
Гомрем буе ят булдың!..

Таң иде... Бәхетле йөземә
Син булып беренче нур кунды.

Ә кичен — ал шәфәкъ нурында
яралы киек күк хур булдым.

## Бер җавапка дүрт сорау

Очкан килеш калырмы кош күк йөзендә?
Гел торырмы буй җиткән кыз ата нигезендә?
Менә алырмы һәр теләгән — шәп ияргә?
Бер гомер җитәрме Сине сөяргә?

## Миңа никтер...

Бар да китә, бар да үтә икән!
Хәер, кемгә тансык бу сүз-үгет!
...Ярына ашыккан һәр егет хәзер
миңа никтер әкрен атлый кебек.

## Кызыл гөл итеп

Барханнарда йөрдем — көймәдем.
Өшемәдем бозлар илендә.
Чөнки Сине кызыл гөл итеп,
үзем белән йөрттем күңелдә.

## Парсыз таҗ чәчәге

Сирень чәчәге таҗының
таптың да бишлесен,
капылт әйттең: «Мин юк чакта
ялгызың нишлисең?»

## Көту

Менә хәзер
телефон шылтырар да,
сөенечтән
елмаю кунаклар йөземә!

## Бер банкетта

Бар сөйләнгән «кызыл» тостлардан
мәгънәлерәк иде ал шәраб.
Тагын истә калган бер сылуның
күзләрендә күргән ишарә...

## Карадагта кызыл җыйганда

Безнең якның чияләре кебек,
якут җимеш сарган ботакны!

Ул кушбөртек каян килгән дисәм, —
Синең иреннәрең икән!

## Сагындыра...

Диңгез шавына кушылган
назлы авазлар!..
Сине уйлап, таулар менгән
хыяллы язлар!..

## Куктубә комлыгында

Һәр дулкынның үз исеме бардыр кебек.
Ә бу дулкын — Синең исемдәдер!

...Дулкынныкы кебек ак яллы атта
Сине урлап очтым төшемдә бер!..

## Сагыну

Бер-ике юл ямансу шигырь...
Хатирә — ул татлы көннәрдән!
..........................................................
Шәфәкъләрдә алсу болыт булып
тибрәнә Синең күләгәң!..

## Язгы халәт

Күктә күренеп алды сөйгәнемнең зәңгәр яулыгы!
Килеп китте җилдә җир җиләге исе!
…Үзләренә бакмасам да, шәүләләреннән күренә
яшь җаннарның наз теләгән дәртле көче.

* * *

Сөю безне көчле итә.
Ә шикләр — җанны тетә...
Ваклыклар килеп өстәлсә,
кеше... бетә!

## Мин ашыкмыйм

Рәнҗеттең син бүген, бик рәнҗеттең...
Тик ашыкмыйм хөкем итәргә.
Яхшы чакларыңны уйлар өчен,
гомер бар бит әле иртәгә.

## Бер...

Башың биш булса да,
Яулыгың бер.

Нәфсең ун булса да,
саулыгың бер.

## Үткәнгә бер борылып карау

Язмыш булды микән? Ялгышмы?
Синҗа бәйле байтак яшь гомер.
...Ул елларга хәзер ни дип карыйм?
Каш җыерып куйсам — син кичер.

## Юлда

Артта — яндырылган күперләр.
Былбыллы назлы таңнар!

Алда — билгесезлек рәшәсе.
Һәм... сынаулы Синең күзләр.

## *Халәт*

Агыйделнең аръягында ак болыт тора.
Яңа ярлар иске ярны оныттыра.

Берен назлап, күккә чөйсәң,
берсе — җирдә таптала...

Бер күздә — нур, берсендә — яшь:
җанда утлы гөл яна!..

* * *

Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга
җитә сирәге!

Матурлар күп... Ә күңелгә
Син иң кирәге!

* * *

Иркен идек — тар калдык.
Күмәк идек — таркалдык.
...Бер көн килде — таң калдык! —
парлы-парлы так калдык.

## Үл төнәр исткэлеге

Син чәпәгән черки эзе —
рамлары сурәт!
Мәхәббәтнең сукырлыгына
тагын бер гыйбрәт.

* * *

Якыным да Син минем!
Ерагым да Син минем!
Зинданыңнан чыгар юлга —
чырагым да Син минем!

# Эчтәлек

Янә Мәхәбәтнамә ........ 5

## ҮСМЕРЧАК ДӘФТӘРЕННӘН

Онытылмас бер кыш бураны ........ 13
«Аста — дулкын, өстә — Кояш!..» ........ 14
«Ай вакланган дулкыннарда...» ........ 15
«Аһ, кулларың, — дидең, — нинди кайнар!..» ........ 16
«Кер чайкыйлар кызлар...» ........ 18
Яшьлек дәфтәреннән моңсу юллар ........ 19
Иңемә кулларың орынгач ........ 20
Кит! ........ 22
«Ашыгыч ярдәм» машинасы бездән киткәч...» 23
«Сине күптән күргәнем юк...» ........ 25
Күзләр ........ 26
Рәсем ........ 27
«Ал поездлар юллыйм мин сиңа...» ........ 28
«Күз кичәге, караш бүтән...» ........ 29
«Мин сине ничек яраттым!..» ........ 30
«Кыз бала йөгереп үткән...» ........ 31
«Үпкәлим...» ........ 32
«Матурлар күп...» ........ 34

## СОЛДАТ ДӘФТӘРЕННӘН

«Ярлар күчәр, дулкын бәрсә...» .................... 37
Әйтте кыз казарма янында... ........................ 37
«Син — гүя бер күчмә шәһәр...» .................... 38
«Телем оер...» ............................................ 39
«Җир җимермәк идек!..» ................................ 40
«Булчы, зинһар, зәңгәре син...» ..................... 41
«Күкне иңдереп...» ...................................... 42
«Көн шыксыз, дип карадым...» ....................... 43
«Мәңгегә яратам, димим...» ........................... 44
«Шулай туры килә...» ................................... 45
«Кемгә хаҗәт шатлык-кайгың!..» .................... 46
«Куркытмый мине...» ..................................... 47
«Диңгездә ай юлы...» ................................... 48
«Яктыга төшә күз, акка...» ............................ 49
«Бераз үзгә, бераз бүтән...» .......................... 50
«Гөлем идең, яктым...» ................................. 52
Ул көннәрне инде даулап булмый... ................. 53
«Сөю көчле иманнан!..» ................................. 54
«Яздым мәхәббәт турында...» .......................... 55
«Минеке түгел сылулыгың...» ......................... 56
«Мин, ахры, изгеләштерәм...» ......................... 57
«Төн бастырып куйдымы сине...» .................... 58
«Без, ахры, гыйбадәт кылдык...» ..................... 59
«Нигә чыктың?..» ......................................... 61
«Чакырдың да...» ......................................... 62
«Күргән һәр сылуга мин гашыйк...» ................. 64

## ӘЛМӘТ ДӘФТӘРЕННӘН

«Ярсыгансың, янгынсың...» ........ 67
«Үсә алган һәрбер нәрсә...» ........ 68
«Булдыраалмыйм! Хуш!» — диде ул...» ........ 69
«Сафлыкка өйрәнәм Сездән...» ........ 70
«Зинһар, кит!» — дисең...» ........ 71
Очрашкач ........ 72
«Мин ашыккан, син соңарган...» ........ 73
Этюд. Идиллия ........ 74
«Күктә — яшен!..» ........ 76
«Хиссият илендә икәү...» ........ 77
«Артык бернәрсә дә өмет итмим...» ........ 78
Бәлки, Син... ........ 79
«Адаштык. Төн килә өскә...» ........ 80
Бу сөю ........ 81
«Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык...» ........ 82
«Кояш булган күзләреңнән...» ........ 83
«Сагыш газапка әйләнгәч...» ........ 84
«Су читендә, таң тугач...» ........ 85
«Син — бәйлелек, мескенлекнең...» ........ 86
«Аның җаны яралы...» ........ 87
«Сары ут капкан бу кырда...» ........ 88
«Мин синең җәеңә килдем...» ........ 89
«Миннән дә алдан тәрәзәңнән...» ........ 90
«Син калган аптыраште...» ........ 91
«Бар нәрсәдә синең төсмер...» ........ 92
«Мәхәббәт күзсез була, ди...» ........ 93
«Беренче дә, иң соңгы да түгел...» ........ 94
«Өзгәләнмим, һич үкенмим...» ........ 95

«Кояш тотылганмы? Көпә-көндез...» .............. 96
«Бар күк булган сабырлыгымны...» .............. 97
«Тилерткән, бәхетле иткән...» .................... 98
«Без бәләкәй чакларда...» ........................ 99
«Бу — сәясәт түгел...» ............................ 100
«Асылмалы тар күпердән...» ....................... 102
«Әгәр дә мин хөр, бәйсез бер...» .................. 103
«Көнләшү ирләр эшеме?..» ........................ 105
«Җирдә әллә ниләр бар!..» ......................... 106
Уен ..................................................... 108
«Ак хыялларга уралып...» .......................... 110
Җавап ................................................... 111
«Мәхәббәттә күпме яндык!..» ...................... 112
«Казынмыйм үткәннәреңдә...» ...................... 113
Бу дөньяда ............................................ 114
«Юк, азсынудан түгел...» ........................... 115
«Яр буенда Сиңа диеп...» .......................... 116
Быел җәй, быел җәй... ............................. 118
«Юк, санамыйм сине йолдыз диеп...» .............. 119
Этюд-рәсем ............................................ 120
Кем шакымас толлар ишеген... ..................... 121
«Биеккә мендем. Кояшка...» ........................ 123
«Бәхетле булып, таңгача...» ....................... 124
«Көндезен — кеше күзендә...» ..................... 125
«Син — теләп алган сагышым...» ................... 126
Аккошлар ............................................. 127
«Нинди күзләр! Нинди буй!..» ..................... 128
«Сөйдем аны...» ...................................... 129
Сагыш .................................................. 130
«Яшьлегеңне, гомереңне...» ........................ 131

Тимим күңелемә ................................. 133
Боз өстендә учак ага ................................. 134
Бер хатирә ................................. 135
«Ни кылам?» дип, башкалардан...» ................................. 136
«Синең өчен җан атмасам...» ................................. 136
Яз — 72 ................................. 137
«Бөтен күкләрне чыңлатып...» ................................. 138
«Син дә бөек идең ул мизгелдә...» ................................. 139
«Синең горур башка...» ................................. 140
«Әйтәсең: «Минем йөрәк», — дип...» ................................. 141
«Белмим, кайчан күргәнсеңдер...» ................................. 142
«Бай көз яхшы, тик шулай да...» ................................. 143
Әй, мәхәббәт! ................................. 144
«Могҗизага яшьрәк чакта ышан...» ................................. 146
Мин диңгезгә таба китәм, дидең... ................................. 147
«Чабылгач та, таң атканда...» ................................. 148
Ә шулай да... ................................. 149
Кызыл алма ................................. 150
Күңелемдә сурәтең ................................. 151
Үләннәр ................................. 153
«Илһам биреп, җыр тудырткан...» ................................. 154

## «ГОМЕР ТУЕ» ДӘФТӘРЕННӘН

Язгы кичтә көзге бер уй ................................. 157
Синең өчен яшим ................................. 158
Актриса монологыннан ................................. 159
«Талаштык. Сәгать югалттык...» ................................. 161
Безнең байлык ................................. 162

«Өстебезгә тургай егылгач...» ........................ 163
Яз башы ........................................................ 164
«Күпме уйлар чыгалмыйча калды!..» ............... 165
Займище ........................................................ 166
Ул еллардан якты булып хәтереңдә... ............ 167
Диңгез ярында ................................................ 168
Менә тагын... яки онытылмас мизгел бәхет ...... 169
Син хәтергә килгән минутлар... ..................... 171
«Күзләрендә һәрбер хатын-кызның...» ........... 172
«Кадерсезем минем, кадерсезем!..» ................ 173
Бәхетле бер язның кичендә ............................ 174
Кашларың карасына ла... ............................... 175
Сездә рәхәт, сездә кыен миңа... ..................... 176
«Очрашканга күпме генә!..» ........................... 177
Нәфес салып ................................................... 178
«Ун гомер аз, бар ләззәтен...» ........................ 179
Син киткәч ..................................................... 180
Утрау ............................................................. 181
Бакча. Төнге учак. Июнь ................................ 182
Тагын шул аланда ........................................... 183
Тагын мин соңардым... .................................. 184
«Очты, китте сөю!..» ...................................... 185
«Гашыйк бер пар үтте янәшәмнән...» .............. 186
Безме соң бу? яки хушлашкач янә бер очрашу 187
Экстаз ............................................................ 188
Тагын бер кат искә төшерү ............................. 189
Зур Урам ........................................................ 190
«Мәхәббәтме?..» ............................................ 191
Яшьлек бүреге ............................................... 192
Мәхәббәт ........................................................ 193

Рәсем ........ 194
Кил! ........ 195
«Яратты! Аңламады...» ........ 196
Яшьлек дәфтәрендә — саф сүзләр ........ 197
Ул ........ 198
Имеш, мин дә яр сөйдем!.. ........ 199
Өшү ........ 200
Ни оттың? ........ 201
«Сөенеп яшим шуңарга...» ........ 202
Гомер — дулкын ........ 203
«Күпме матур яфрак агачта!..» ........ 204
«Май уртасы — җәй башы...» ........ 205
«Чәчәккә кунды бал корты...» ........ 206
Өфе вакыты ........ 207
Яшьлегендә чибәр булган бер чал әби сүзләре ... 208
Язгы сагыш ........ 210
«Зәңгәр давыл — диңгез-ярда...» ........ 211
Фейерверк ........ 212
Бер җәйге кич хатирәсе ........ 213
Кышкы Займищега янә килгәч... ........ 214
Бер уйласаң: еллар ул — мизгел... ........ 215
Әдрән диңгез. Дулкын. Синсез төн ........ 216
Авылда сине сагыну ........ 217
Минем белән... ........ 218
Өчәү ........ 219
Тау башында Синең тәрәзәң ........ 220
«Күңелеңә сагыш атлы кош очырдым...» ........ 221
Көтелмәгән бер мизгел шатлык ........ 222
«Бу очрашу — татлы әкият!..» ........ 223
«Алтын капка» ........ 224

«Изге тау» башында исемең ........................ 225
Март ................................................ 226
Кышкы урманда ...................................... 227
«Элек әйттем: «Нигә, — дидем...» .................. 228
«Хатлар белән яшим. Гомерем минем...» .......... 229
«Синең белән үткән гомер гүя...» .................. 230
Язгы болында. Без икәү ............................. 231
«Кош очты, каурый калды...» ........................ 232
Килә бергә уянасы... ................................ 233
Яраттым! ............................................. 234
Әйткән ди бер ристан иректә бер кызга... ....... 235
Татлы рәхәттәге бер халәт ........................... 236
«Гомер буе җандаш эзләдем мин...» ............... 237
Үкенү дә, әзрәк өмет тә... .......................... 238
Чал акчарлагым минем! ............................. 239
Килмәде яр... ........................................ 240
Иясез шатлык ........................................ 241
«Үзеңә өметләнәмме?..» ............................ 242
«Син миңа рәхмәт тә әйтмә...» ..................... 243
«Ничекләр киләсе булдың...» ...................... 244
«Тәрәз ачып, бер чибәр кыз...» .................... 245
Парлы ялгыз ......................................... 246
Әгәр миңа ышанмасаң... ............................. 247
Әй, сылу! Әй, җанаш!.. ............................. 248
«Һаваларда туктап калды...» ....................... 249
Сау бул, тирәк! ...................................... 250
...Ул — Син! ......................................... 252
Исеңдәме? ........................................... 253
Сиңа ................................................. 255
Карама! .............................................. 256

«Бу төшләрне генә язсаң да...» ..................... 257
Ялгыша, дип уйла мине... ............................. 258
Яшьлегемнең көмеш бер киче ....................... 259
Үземне юатам... ........................................... 261
Язгы кар суларында ..................................... 262
Алтын капка! Алтын капка!.. ........................ 263
«Сине күрә алмаган һәр көн...» ..................... 264
Очраштык кеше туенда... ............................. 265
Көньяктагы рәсемең ..................................... 266
«Дүрт кылы бар иде Сазымда...» .................. 267
Борчылма! .................................................... 268

## «КӨЗГЕ КҮКРӘҮ» ДӘФТӘРЕННӘН

Сорау ........................................................... 271
«Бер-беребезгә артык якынлашмыйк!..» .......... 272
«Элеп киптер мине кер итеп...» ..................... 273
«Язмышымда упкынмы син?..» ...................... 274
Сау чакта, яки «шул» хакта .......................... 275
«Озак эзләдемме мин Сине?..» ...................... 277
«Соравыма бик еш, тапкыр итеп...» ................ 279
Ул камышлар... ............................................ 280
«Тапканга артык сөенмим...» ........................ 281
«Качар җир — убежищелар...» ...................... 282
«Нәрсә әйтим?..» ......................................... 283
Көзге күкрәү ................................................ 284
Җуймагыз мәхәббәтне! ................................. 285
Яшьлек дәфтәрендә бер рәсем ....................... 287

«Сезнең урам аша үттем бүген...» .................. 288
Триумф яки күренеш ........................................ 290
«Париж түгел, Пар-Иш!..» ............................... 291
Син әлегә яшьрәк бит!.. ................................... 292
Сискәнү ........................................................... 293
«Күзләре — диңгез!..» .................................... 294
«Җәй — 96» дан бер сурәт ................................ 295
«Шәүләңне булса да күрием!» дип...» .............. 297
Көньякның бер гүзәленә ................................... 298
Нур ................................................................... 299
«Әллә бар да, әллә юк та Син...» ...................... 300
«Урал шаһинәсе булып Син үткәндә...» .......... 301
«Күпме булды гомеремдә...» ............................ 302
Шәлең түгәрәк түгел... ..................................... 304
Кичеп чыкмады... ............................................. 306
Быел җәй... яки моңсу кабатлану .................... 307
«Авырыйсыңмы — димәк, гөнаһың бар...» ........ 308
«Тәрәзәдә Синеңме сулышың?..» ...................... 309
«Затлы...» ......................................................... 310
Эх! .................................................................... 311
«Беренче саф хисне...» .................................... 313
Күпсенмә, Ходаем! ............................................ 314
Чибәрләр ярышында ......................................... 315
«Ирлек чыкты бәреп тирләрдә!..» ..................... 316

## «КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР» ДӘФТӘРЕННӘН

Дүртьюллыклар.............................................. 319

Литературно-художественное издание

**РАВИЛЬ ФАЙЗУЛЛИН**

(Файзуллин Равиль Абдрахманович)

*Книга любви*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *Ю.А.Щетинкина*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 17.09.2003. Форматы 70×108 $^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 17,5+форз.0,18. Шартлы буяу-оттиск 18,50.
Нәшер-хисап табагы 8,20+форз.0,29. Тиражы 3000. Заказ Я-614.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/

**http://tatkniga.ru  E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.